А. Г. ЯХИН

Әдәбият

2

Икенче кисәк

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
2

А. Г. Яхин

Әдәбият

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
2 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә

ИКЕНЧЕ КИСӘК

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан рөхсәт ителгән

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 373.167.1:821.512.145*02
ББК 84(2Рос=Тат)я71
Я89

Рәссамнары:
Рәисә Сәйфуллина, Алексей Мамаев

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Шартлы билгеләр:

?! — сораулар һәм биремнәр;

— иҗади эш.

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Дүртьеллык башл. татар. мәкт. 2 нче с-фы өчен д-лек : Ике кисәктә. Икенче кисәк / А. Г. Яхин.— Казан : Мәгариф, 2009.— 159 б.
ISBN 978-5-7761-1966-8

ISBN 978-5-7761-1966-8

© «Мәгариф» нәшрияты, 2009
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2009

Беренче ярты елда өйрәнгәннәрне искә төшерик.

КӘРЛӘ МУК.

Безнең шәһәрдә Мук исемле тәбәнәк бер карт яши. Муены нечкә, башы бүтән кешеләрнекеннән шактый зур. Мук зур йортта ялгыз яши. Ашын үзе пешерә, керләрен дә үзе юа. Күп вакытын ул өендә үткәрә. Урамга айның беренче көнендә нибары бер генә мәртәбә чыгып керә.

Без, малайлар, аны үртәргә яратабыз. Ул урамга чыккан көн безнең өчен чын бәйрәмгә әйләнә. Менә ул ишеген әкрен генә ача. Иң элек ишектән зур чалма уралган башы күренә. Башына озын киң чалбарлы гәүдәсе ияРә. Киң каешына озын хәнҗәр кыстырылган. Хәнҗәре шундый озын — ул Мукка кыстырылганмы, Мук хәнҗәргәме, белмәссең.

Без аны шатланып, чыр-чу килеп каршы алабыз. Сәлам бирәбез. Мук безнең белән күрешә.

Ләкин еш кына рәнҗетәбез дә. Оят булса да әйтим: мин башкалардан да артыграк кыланам. Мин аның чапан итәгенә басарга яратам. Бу эш миңа бик кызык булып тоела. Беркөнне озын

кәвеше артына бастым. Мескен Мук егылды һәм аягына баса алмыйча шактый ятты. Торгач, әкрен генә атлап, безнең өйгә кереп китте. Котым очты. Менә хәзер әти кирәкне бирә инде дип, бик озак өйгә керергә куркып йөрдем. Тамак ачкач кына кайтып күрендем.

— Син Кәрлә Мукны кыерсытасың дип ишеттем. Моның өчен үз өлешеңне алырга тиеш,— диде әти, кырыс кына. Өлешемне ул шунда ук бирде. Урындыкка утыра алмыйча шактый йөрдем. Аннары болай диде: «Ә хәзер игътибар белән тыңла. Кәрлә Мук язмышы турында сөйлим. Бәлки, шуннан соң аны рәнҗетергә оялырсың».

Әти миңа менә ни сөйләде.

Мук синең кебек чакта әтисе белән генә яши. Әтисе үлгәч, туганнары аны өйдән куып чыгаралар.

— Син артык тәбәнәк, безгә бер файдаң да тиярлек түгел. Бар, дөнья гиз. Бәлки, бәхетеңне шунда табарсың,— диләр.

Мук, башына чалма урынына сөлге урап, хәнҗәрен биленә тага да чыгып китә.

Өч көн юлда булып, дүртенчесендә бер шәһәргә килеп керә. Ул шәһәрнең урамнары киң, йортлары матур икән. Өч көн буена тамагына бер бөртек ризык капмаган. Мук бер йортның ишеген кагып карый, икенчесенекен — ачучы булмый. Ачлыктан тәмам аяктан егылырлык хәлгә килә. Шулай егылам-егылам дип бара торгач, ачык ишек күрә. Ишектән песиләр, этләр кергәнен күргәч, аларга иярә.

— Син кем? Нигә кердең? Мин бит песиләр белән этләрне генә чакырып ашатам,— дип каршы ала аны хуҗа карчык.

Мук үзенең язмышын түкми-чәчми сөйләп бирә. Ятим бала булуын, туганнарының куып чыгаруын, күптәннән бирле ач йөрүен әйтә.

— Ярый. Әйдә, монда кал. Эшең кыен булмас, өстең-башың бөтен булыр, ач йөрмәссең,— ди хуҗа карчык.

Мук шунда ук риза була. Хуҗа әбинең биш песие, дүрт эте бар икән. Малай аларны өч тапкыр ашата, песиләрнең йоннарын тарый, кичен йомшак ястыкка яткырып йоклата.

Өс бөтен, тамак тук, эш күп түгел. Ләкин торабара песиләр, этләр тормышны туйдыра башлый. Җитмәсә, хуҗа хатын песиләре ваткан савытсабаларын да малайга ягып, аны гел ачуланып тора. Хезмәте өчен акча да түләми.

Мук бу йорттан китәргә карар кыла. Ләкин хезмәт хакын ничек тә булса алырга кирәк бит инде.

Хуҗа әби йортында бер бикле бүлмә бар икән. «Әллә минем хезмәт хакын хуҗа шунда яшерде микән?» — дип уйлый Кәрлә.

Ә беркөнне иртән әби каядыр чыгып китә. Этләрнең берсе — Мукны аеруча якын күргәне — аңа бикле бүлмәгә керү юлын күрсәтә. Эт артыннан барып, бүлмә эченә кергәч, Кәрлә шакката: монда затлы киемнәр, әйберләр шыплап тутырылган. Ләкин Мукның күзе почмактагы зур ямьсез башмакка төшә. Аягындагы башмаклары тузып, ертылып беткән. Кәрлә, искеләрен салып, шул башмакларны кия. Башмаклар янында арыслан башлы кул таягы тора. Монда аның барыбер кирәге юк дип, Мук анысын да эләктерә.

Йорттан чыга да Мук кырга таба чаба. Чабачаба аргач, ял итәргә ниятли. Шунда гына аңлап ала — ул туктый алмый икән. Егылып та карый, борылып та — файдасы тими. Аяклары алга таба сөйри дә сөйри. Ниһаять, аны өзлексез алга таба этүченең башмаклар булуын белә. Чаба-чаба, тәмам хәлдән тая. Нишләргә дә белмичә, атка кычкыргандай, «Тр-р-р! Тукта!» — дип кычкыра.

Башмаклар кинәт туктап калалар. Кәрлә шунда ук җиргә ава. Ава да, йокыга да китә. Карчык булмәсенә керергә ярдәм иткән Эт аның төшенә керә.

— Мук дускай, башмакларың хикмәтле синең. Сул аягың үкчәсендә өч тапкыр әйләнсәң, алар сине җаның теләгән җиргә илтеп куячаклар. Ә таягыңны җиргә ике тапкыр төртсәң, ул сиңа хәзинә табарга ярдәм итәчәк,— ди Эт.

Мук, йокысыннан уяну белән, сул аягының үкчәсендә өч тапкыр әйләнә дә башмакларына:

— Мине якындагы шәһәргә илтегез,— дип боера. Сүзләрен әйтеп бетерүгә, күккә күтәрелә. Күзен ачып йомарга да өлгерми, базар уртасына очып төшә.

Менә ул базар уртасында басып тора. Тамагы ач, бер тиен акчасы юк. Нишләргә? «Тукта әле, йөгерешсәк, мине берәү дә уза алмый бит. Димәк, йомышчы булып эшли алам»,— дип уйлап ала.

Шулай дип уйлый да, сораша-сораша, патша сараена килә. Эшкә ялланырга килдем, ди. Сакчы коллар хуҗаларын чакырып чыгаралар.

— Хуҗа әфәнде, мин сезнең иң оста йөгерешчегезне дә уза алам. Патшага йомышчы кирәк түгелме? Бик тырышып эшләр идем,— ди Кәрлә.

— Үзең кәрлә, аякларың чыбык юанлыгы гына. Сиңамы соң безнең йөгерешчене узу! — дип көлә коллар хуҗасы.

— Әйдәгез соң, узыштырыгыз, кем узганын күрерсез, — ди Мук.

Коллар хуҗасы эче катып көлә. Аның бу кәмитне патшага да күрсәтәсе килә. Мукка көтәргә куша да патша янына китә.

Патша, чыбык аяклы Кәрлә турында ишеткәч, ярыш оештырырга боера. Ярышны болында үткәрегез. Тамаша күрергә бөтен шәһәр халкын чакырыгыз. Көлеп күңел ачсыннар, дип боера.

Ярыш үткәрү вакыты җиткәч, патша үз урынына килеп утыра. Мук мәйдан уртасына чыгып баскач, җыелган халык та эче катып көлә. Киң балаклы ыштан кигән, чамадан тыш озын башмакларын сөйрәп йөрүче Кәрлә — карар күзгә дә үзе бер кәмит бит.

Патша сараеның иң оста йөгерешчесен ярты юлда калдырып килгәч, тамашачылар беравыздан:

— Яшәсен җиңүче Кәрлә Мук! — дип кычкыралар. Туктаусыз кул чабалар. Кәрлә патшага да ошый.

— Бик оста чабасың икән. Беренче йомышчым булып хезмәт итәрсең,— ди патша Кәрләгә.

Мукның шатлыгы эченә сыймый. Патша йомышларын ул тиз һәм җиренә җиткереп башкара. Ләкин сарайдагы хезмәтчеләр патша мәхәббәтен яулаган Муктан көнләшәләр. Ничек кенә булса да, аны патшага начар итеп күрсәтәселәре килә.

Бу хәлгә Мук бик борчыла. Көнчеләр белән дуслашырга чара эзли башлый.

«Бәлки, патшага хәзинә табып бирсәм, ачулары басылыр»,— дип уйлый Кәрлә Мук.

Бервакыт базарда йөргәндә, яшерелгән хәзинә барлыгын ишетә. Дошман гаскәрләре шәһәргә һөҗүм иткәч, карт патша бөтен байлыгын яшереп куйган, имеш. Кәрлә малайга шул гына кирәк тә. Арыслан башлы таягын ала да көннәр буе хәзинә эзли. Таягын җиргә төртә-төртә, патша сарае мәйданын тикшереп чыга. Бөтенләй көтмәгәндә, кулындагы таяк дерелди башлый. Җиргә өч тапкыр бәреп ала. Булды бу, ди Мук. Урам себерүчедән көрәк сорап ала. Ә караңгы төшкәч, билгеләгән урынына килеп, җир казырга керешә. Күп тә казымый — чокырдан эче тулы алтын чүлмәк килеп чыга.

Авыр чүлмәкне кечкенә Мук күтәрә алмый. Шуңа күрә алтынны, кесәсенә сыйган хәтле тутыргач, кайтып, мендәре астына яшерә.

Икенче көнне очраган бер кешегә алтын өләшеп йөри. Шулай итсә, патша сараендагы хезмәтчеләр көнләшмәсләр дип уйлый. Ләкин ялгыша. Бу хәлне күреп, хезмәтчеләр тагын да катырак көнләшәләр:

— Йомышчы Мук патшаның алтынын урлаган,— дип хәбәр тарататалар. Хәбәр патшага да барып ирешә. Казнадан алтын урлаган өчен, патша Кәрләне, богаулап, төрмәгә ябарга куша.

Икенче көнне Мукны җәзаларга тиеш булалар. Башын кисәргә килгән җәлладка Кәрлә сүз ката.

Туктап тор, алтынны ничек табуым турында чын дөресен сөйләп бирәм, ди. Ләкин серен патшаның үзенә генә ачам дип кисәтә. Патша янына кергәч, шарт куя. Мине азат итсәң генә, серне ачам, ди. Патша риза була. Кәрлә патшага башмакларының һәм кулындагы таягының хикмәтле булуын сөйли.

Патша ышанырга да, ышанмаска да белми. Башмаклар хикмәтен үзе сынамакчы була. Башмакларны аягына элүе була, акылдан шашкандай, чабып китүе була. Чабуын чаба, ләкин туктый алмый. Агач ботакларына, куакларга ябышып карый — файдасы тими. Ә Мук явыз патшадан үч алуына шатланып, читтә елмаеп тора.

Патша, чаба-чаба, хәлдән таеп егыла. Башмакларын сала да Мукка ташлана. Ачуыннан шартлар хәлгә җитә. Таягы белән башмагын алып кала да Мукны шәһәрдән кудырта. Әйләнеп кайтсаң, шунда ук башыңны кистерәм, дип яный.

Мук, елый-елый, шәһәрдән чыгып, урманга керә. Тамагы ачкач, агачтан берничә кара җимеш өзеп ашый. Буага килеп, су эчмәкче булып иелсә, ни күзе белән күрсен — аның башы ат башы хәтле булып зурайган, колаклары ишәк колаклары кебек үскән, борыны озынайган.

Ләкин Мук еламый. Шул кирәк сиңа. Кулыңдагы бәхетеңне үзең ычкындырдың дип, үзен үзе тирги. Тамагы ачкач, кабат агач җимешләрен ашый. Шуннан соң колакларын тотып караса — исе китә:

колаклары үз хәлләренә кайтканнар. Мук шатлыгыннан буага чаба. Суга карагач, шатлыгыннан кычкырып җибәрә. Суда аңа элекке Мук елмаеп торуын күрә.

Кәрлә серне бик тиз белеп ала: агачларның берсендә колак үстерә торган, икенчесендә колакларны үз хәленә кайтара торган җимешләр үсә икән, ди.

Менә ул агачларның икесеннән дә күтәрә алган хәтле җимеш җыя. Аннары, ашыга-ашыга, шәһәргә китә. Монда ул киемнәрен алыштыра. Беренче агач җимешләрен кәрзингә сала һәм патша сарае янына барып утыра. Күп тә үтми, патша пешекчесе сатучылардан азык-төлек алырга чыга. Мук янына җиткәч, кәрзиндәге эре кара җиләкләр күреп шатлана. Яз көне җиләк-җимеш өлгермәгән вакыт була. Пешекче җиләкне кәрзине белән сатып ала. Патшага иртәнге аш янына әлеге җиләкләрне дә куя. Пешкән җиләк күреп, патша да шатлана. Җиләкне туганнарына һәм вәзирләренә дә бүлеп бирә.

Үз өлешен тәмләп ашый башлау белән, улы:

— Әти, әти, колакларыңа ни булды? — дип кычкырып җибәрә.

Патша колакларын тотып карый. Куркуыннан аны очкылык тота башлый. Колаклары бик ямьсез булып үскәннәр. Борыны иягенә асылынып төшкән. Тиздән бүтәннәргә дә ишәк колаклары үсеп чыга.

Патшаның иң оста табиблары җыелып дәвалап карыйлар. Булдыра алмыйлар.

Чират миңа җитте, дип шатлана Мук. Менә ул. Җиләк саткан акчасына озын кара чапан алып кайта. Башына очлы калфак кия. Иягенә ак сакал ябыштыра да, икенче агачтан җыйган җимешләрен кәрзингә салып, патша янына керә.

— Мин сезне бу бәладән коткара алам,— ди. Патша улына ике-өч җиләк каптыруы була, колаклары шунда ук үз хәлләренә кайталар.

Бар да, «мине дәвала», «мине дәвала» дип, Мукка ташланалар. Патша аны хәзинәләр бүлмәсенә алып керә.

— Мондагы җиһазлар арасыннан җаның теләгәнен сайлап ал, тик мине бу коточкыч чирдән генә дәвалый күр,— дип ялына.

Мук почмакта үзенең башмакларын һәм таягын күреп ала. Арлы-бирле йөргән булып, патшага сиздермичә генә, башмакларын кия, таягын үрелеп ала да сакалын йолкып ата. Йомышчысын танып, патша һуштан язар хәлгә җитә.

— Мәрхәмәтсез, усал патша! Минем тырыш хезмәтемне син шулай бәяләдеңме? Гомерең буе озын колагың, хәшәрәт борының белән йөр. Көзгегә караган саен, Кәрлә Мукны исеңә төшер! — ди.

Сул үкчәсендә өч тапкыр әйләнә дә Мук, патша ни дә булса әйтергә өлгергәнче, күздән югала.

Шул вакыттан бирле Кәрлә Мук безнең шәһәрдә яши. Әнә күпме интеккән, күпме кичергән ул.

Тыштан көлке булып күренсә дә, аны хөрмәт итәргә кирәк.

Әти миңа менә шундый гыйбрәтле хикәя сөйләде. Мин ул хикәяне урам малайларына сөйләдем. Шуннан соң Кәрләдән берәү дә көлмәде. Киресенчә, без аны барыбыз да хөрмәт иттек. Башны түбән иеп исәнләшә торган булдык.

Вильгельм Гауф.

?! **1.** Әкияттә бер вакыйга эченә тагын бер вакыйга кергән. Шул вакыйгаларга исем бирегез.

2. Беренче вакыйганы кыскартып әйтик: Яманлык эшләгән балалар җәза алалар. Алар нинди начарлык эшлиләр? Нинди җәза алалар?

3. Икенче вакыйганы да шул рәвешле кыскартып сөйләгез.

4. Рәнҗетелгән Мукка автор нинди ярдәмнәр күрсәтә?

5. Мукны рәнҗеткән балалар соңыннан аны үртәми башлыйлар. Алар шәфкатьле балалармы?

Өлешләр арасындагы бәйләнеш.

Бәйләнеш төрләрен өйрәнүне дәвам итәбез. Каршылык кебек үк күп очрый торган бәйләнешләрнең берсе — охшашлык.

Охшашлык.

Охшашлык каршылыкның киресе булса да, алар әдәби әсәрдә бертуганнар булып яшиләр. Каршылык, тырыша-тырыша, дусларны аерды. Ул хәтта, сүзләр эченә кереп, сүзләрне дә каршы якларга аерып ташлады. Ләкин аның нияте гел яхшылыкта: ялгышучыларны төзәтүдә, яманлык эшләүчеләрне тәүбә иттерүдә, матурлыкны күрә белергә өйрәтүдә булуын күрдек.

Сүзләр охшашлыгын өйрәндек бит инде, диярсез. Ләкин әдәби әсәр предметларны да, күренешләрне дә, вакыйгаларны да охшатырга ярата. Охшата да: «Минә монысы — кояш, ул — әсәрнең бер өлеше, ә минә монысы — лампочка. Ул кояшка бөтенләй охшамаган кебек. Ләкин шулай булса да алар охшаганнар — икесе дә яктырталар»,— ди.

Авторлар да охшашлыкны бик яраталар, чөнки охшашлык биек белән тәбәнәкне дә, кара белән акны да, усал белән юашны да бер-берсенә охшата ала. Менә шундый хикмәтле көчкә ия ул охшашлык.

- Кечкенә генә эт өрми дә, җибәрми дә. (*Йозак.*)
- Аягы бар, кулы юк,
  Аркасы бар, түше юк. (*Урындык.*)
- Үзе ага, яры юк.
  Барып җиткән җире юк. (*Болыт.*)

?! Табышмакларның икенче өлешен табыгыз. Өлешләрнең охшашлыгын күрсәтегез.

КОШЛАР КИЛӘ.

Китте узып кышкы көннәр;
Җитте дип апрель тагын,
Кошлар килә, кошлар килә,
Ачып яз капкаларын.

Чишмәләрнең уянуы
Шуны ук хәбәр итә.
Җыры белән тургайларның
Башлана һәрбер иртә.

Кошларның бар канатлары,
Очарга туган алар.
Ачып язның капкаларын,
Никадәр диңгез-таулар

Кичеп безгә килә алар
Бик ерак-еракларадан.
Аларның да кыюлары
Юл ярып кайта алдан.

Кошлар алар кошлар инде,
Гыйбрәте нидә моның?
Тормышта да
Тик кыюлар
Кыенын сайлый юлның.

Гали Хуҗи.

?! **1.** Катнашучылар икәү. Ни өчен икәү?
2. Аларны автор охшаткан. Ничек охшаткан?

ТАБЫШМАК-ШИГЫРЬ.

Нәкъ турист шикелле,
Кайда да йөри ул:
Юлбарыс шикелле,
Тайгада йөри ул.

Нәкъ юлчы шикелле,
Юлда да йөри ул.
Кырмыска шикелле,
Кулда да йөри ул.

Трамвайга утырып,
Калада йөри ул.
Җәйраннар шикелле,
Далада йөри ул.

Йә, атка атланып,
Авылда йөри ул.
Бернидән курыкмый,
Давылда йөри ул.

Абыем шикелле,
Эштә дә йөри ул.
Әбием шикелле,
Өйдә дә йөри ул.

Нәкъ циркач шикелле,
Стенада йөри ул.
Безнең белән сыйныфта,
Кинода йөри ул.

Кесәгә салгачтын,
Кесәдә йөри ул.
Нәкъ песи шикелле,
Өстәлдә йөри ул.
Самолёт шикелле,
Өстә дә йөри ул.

Космонавт шикелле,
Җиһанда йөри ул.
Читлеккә йозаклап
Куйсаң да йөри ул.

Водолаз шикелле,
Суда да йөри ул:
Суга чулт итә дә,
Чума да йөри ул.

Йоклаусыз йөрер ул,
Туктаусыз йөрер ул!
Үз эшен белер ул,
Арыдым дип тормас,
... ул тиктормас.

Роберт Миңнуллин.

?! **1.** Шигырьдә сүз гел йөрүче турында бара. Ул үзе кешегә охшаган да, охшамаган да. Кешегә кайсы ягы белән охшаган? Кайсы ягы белән охшамаган?

2. Шигырьнең эчтәлеген бер генә җөмлә белән әйтә аласызмы?

АЙБАШ.

Дөньяда иң тәмле ризык нәрсә?

Әгәр бу хакта Галәү бабайдан сорасагыз, ул, ике дә уйламыйча:

— Көлгә күмеп пешергән бәрәңге,— дияр.

Учак көлендә кызарып, күмерләнеп пешкән кайнар бәрәңгене колхоз атларын сакларга килгән малайлар да үлеп ярата. Тәме, туклыклылыгы турында әйткән дә юк, әле аның пешеп чыкканын көтеп, төнге шәмәхә күккә карап яту ни ләззәт!

Менә берзаман бәрәңгеләр, «пештек, өлгердек» дигәндәй, кайнар көлне пуф-ф-ф итеп, астан өреп җибәрәләр. Көл өстендә нәни шадралар гына уелып кала. Дымлы җир, төнге чәчәкләр, җиләкле печән исенә аралашып, авыз суларыңны китерерлек хуш ис — парлы бәрәңге исе бөтен болынга тарала. Инде актарып алдыңмы, суынганчы түзәрмен димә...

?! **1.** Хикәянең бу өзеген мөмкин кадәр тулырак итеп сөйләгез. Онытсагыз, тагын укып чыгыгыз. «Ни турында?» соравына җавап тапсагыз, әсәрне өлешләргә бүлгән буласыз. Җавабыгызны кыскартып әйтсәгез, өзекнең исемен табарсыз.

2. Болында бәрәңге пешереп ашау турында автор бик матур итеп яза. Шул урынны кабат укыгыз һәм, китабыгызны ябып, хәтерегездә калганны сөйләгез.

Хикәяне дәвам итик.

Башка чакларда мондый күңелле табында иптәш малайларыннан бер дә калышмый торган Инсаф кына бәрәңгегә үрелеп тә карамый. Балтасы суга төшкәндәй, башын иеп, бер читтә утыра. Башында һаман бер уй, бер кайгы: аның өч ел буе назлап-иркәләп үстергән тае югалды. Шул кыбырсыкны эзләп, атна-ун көн эчендә айкамаган урман-кыры, әйләнмәгән болын-тугае калмады малайның. Инде тәмам төшләренә керә башлады.

?! Беренче өзек шатлык, бәхет турында иде. «Икенче өзек ни турында?» дип, үз-үзегезгә сорау бирегез дә исем уйлап табыгыз.

Хикәяне дәвам итик.

Тик менә бүген...

Галәү бабай Инсафның хәлен яхшы аңлый.

— Кайгырма, улым, хафаланма ул тикле... Кайта, кайтмый хәле юк! Кеше генә түгел, хайван да туган җирен оныта алмый. Моннан күп еллар элек булган хәл бүгенгедәй хәтеремдә. Тыңлагыз, чыпчыклар, гыйбрәтле хәл. Син дә тыңла, Инсаф улым.

Кайсы ел икәне төгәл хәтеремдә юк, ашлыклар бик уңган иде. Әтинең шатлыгы эченә сыймады. Ашлыкны сугып алу белән, ашарга да юньләп калдырмыйча, шәһәргә илтеп сатты да түгәрәк кенә бер бия алып кайтты... Ике ел да тулмады, яңадан атсыз калдык. Казна бурычлары өчен алып чыгып киттеләр. Колыны бик кызганыч булды. Шешәдән сөт имезеп үстердем. Тора-бара, миңа шулкадәр ияләшеп китте — иптәшләрем белән җиләккә барсам да, Якты күлгә кармак салырга төшсәм дә, артымнан калмый иде. Тәки карап үстердем шул колынны. Өч елдан көр генә тай булып җитте. Синең кара айгырга тартымрак иде, Инсаф улым. Маңгаенда яңа туган айга охшаган кашкасы да бар иде. Шуңа карап, исемен дә Айбаш дип куштык.

Бер килгән кешегә килә бит ул, каһәр. Тәки игелеген күреп булмады.

Инсаф түземсезлек белән сорап куйды:

— Айбашны да алып чыктылармыни, бабай?

— Юк, тайны алып чыкмадылар чыгуын,— диде Галәү бабай.— Сатарга туры килде аны. Күршеләрдән ут чыгып, йорт-җиребез янды. Дүрт бала белән урамда калгач, әтинең башка чарасы булмады. Тайны бер Себер сәүдәгәренә сатып җибәрде. Айбашымны муеныннан кочып, үкси-үкси елаганым хәтеремдә. Хайван сизми дип уйламагыз сез, сизә ул. Башын җилкәмә салып, бик озак торды. Ә кузгалып киткәч, бер борылып карады да, сау булыгыз дигән кебек, урам яңгыратып кешнәп

җибәрде... Мин атлар артыннан йөгердем. Басу капкасын чыккач, куе арыш арасына кереп яттым да арыганчы еладым...

Ярты еллап вакыт узгач, Себер кешесеннән хат килде. Атның югалуы турында язган.

Шуннан соң ел ярым вакыт узгач, барыбызны да хәйран калдырган бер хәл булды. Әнә тегендә, тау сыртында, әти белән печән чаба идек. Бик эсселәгәч, коенып чыгыйм дип, яр буена төшсәм, ни күзем белән күрим: Идел аръягыннан бирге якка таба бер ат йөзеп килә. Әтине чакырдым... Ат ярга килеп чыккач, исебез китте. Әти бот чабып куйды. «Менә сиңа, агай, ә! Һәй, бичара хайван, бичара хайван!» — ди. Гаҗәпләнмәслек тә түгел шул. Ел ярым буе туган ягын эзләп йөргән бит, мескенем. Сөяк белән тиресе генә калган.

Без кайтканда, Айбашыбыз янган сарай урынында басып тора иде. Янына килдем. Таныды хайванкай. Элеккечә башын җилкәмә салды да, йокыга киткән кебек, бик озак торды. Өйгә кереп, икмәк кисәкләре алып чыктым, ашамады.

Икенче көнне иртән торып чыкканда үлгән иде инде, мескенем.

Галәү бабай озак кына сүзсез торганнан соң, тирән сулап, барлык сөйләгәннәренә йомгак ясаган кебек итеп әйтеп куйды:

— Кадерле ул туган як. Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы.

Габделхәй Сабитов.

?! **1.** Хикәя ахырындагы вакыйганы сөйләгез. Өзеккә исем бирегез.

2. Беренче, икенче һәм өченче өлештәге вакыйгаларны кушып сөйләгез.

3. Галәү бабайның Айбаш турында ни өчен сөйләвен белсәгез, Инсаф белән Галәү бабай арасындагы охшашлыкны табарсыз.

Әсәрләрдә катнашучылар гына түгел, хикәядәге өлешләр дә үзара бәйләнешкә керәләр.

БҮЛӘК.

Март бәйрәмен быел бик тә
Зарыгып көткән идем,
Әниемә бүләк эзләп,
Мин арып беткән идем.

Иң матурын алам диеп,
Кая гына чапмадым,
Чыннан бүләк булырдаен
Тик барыбер тапмадым.

Ярар, әни эштә чакта,
Урыннарны җыярмын,
Тузаннарны җыештыргач,
Савыт-саба юармын.

Гөлләренә су сибәрмен,
Җибәрермен аш куеп.
Эштән кайткач ял итәр бер,
Мендәренә баш куеп.

Җырлый-җырлый эшли торгач,
Узган да киткән вакыт!
Уйларымнан бүлендерде
Әнием, ишек шакып.

Килеп кергәч, кояш кебек
Балкыды әллә нигә.
Мин бүләксез басып торам,
Ни әйтим дип әнигә...

Җәүдәт Дәрзаман.

?! **1.** Шигырьдәге охшаган урыннарны табыгыз.

2. Кыз әнисенә нинди бүләк әзерләгән? Зурмы ул, әллә кечкенәме?

ӘРДӘНӘ.

Вил белән Нил иртүк балык тотарга китмәкчеләр иде.

Ләкин әткәләре:

— Сез башта кичә кискән утыннарны өеп алыгыз әле,— диде.

— Хәзер, була ул, әткәй,— дип, Нил өйдән чыгып та сызды.

Ялгызы гына калган Вил, көрсенеп:

— Нилнең «хәзер» белән «була»лары гел үзе өчен генә: берәр төрле йомыш куштылармы, шылу ягын гына кайгырта,— диде дә утын өяргә кереште.

Әрдәнә тигез, тыгыз һәм матур булып чыкты... Вил үз эшенә үзе сокланып карап торды да, шатлана-шатлана, кармак сабын алып, балыкка китте.

Өйләреннән чыгып сызучылар, сыкрана-сыкрана булса да, бер әйләнеп кайталар алар... Нил дә шулай кайтып керде.

— Әткәй күренгәнче...— дип, ул әрдәнә өстен ишеп төшерде дә яңадан өяргә тотынды. Өеп бетерүгә, утыннар дөбер-шатыр килеп ишелеп төшмәсенме! Нил: «Берәрсе күзәтеп тормагае тагын»,— дигән сыман карангалап, тырыша-тырыша, эшен яңабаштан төгәлләде. Бу минутта аны бирелеп эшләү нәтиҗәсендә генә туа ала торган күңел рәхәтлеге чорнап алды. Нил, маңгай тирләрен сөртә-сөртә, шул рәхәтлегеннән аерыла алмыйча, бүкән өстенә барып утырды.

Әткәсе кайтып керде.

— Булдыгызмы?

— Абый әрдәнәне нинди матур итеп өя белә икән! — дип җавап бирде Нил.

— Ә син үзең кеше эшләгәнгә сокланып карап кына утырдыңмы?

— Мин дә абый кебек өя аламмы икән дип... яңадан өйдем... Өйрәнә-өйрәнә... Матурмы?

— Гаҗәп матур!.. Туктале, буең ничек җитте соң?

— Буй эшләми, кул эшли, дисең ич син үзең, эткәй...

Әткәсенең елмаеп карап торуына тагын да кәефләнә төшеп, Нил балыкка чыгып чапты.

Идрис Туктар.

?! Нил белән Вил охшаганнар да, охшамаганнар да. Кайсы яклары белән охшаганнар, кайсы яклары белән охшамаганнар?

Сезнең кайчан һәм нинди эш эшләгәндә Нил тойган кебек рәхәтлек тойганыгыз бар? Шул турыда исегезгә төшереп языгыз.

ЯФРАКЛАР КОЕЛГАН.

(Өзек.)

Сентябрь булгач сентябрь инде: агачлардан яфраклар коела. Болытлап, яңгырлап тора. Төннәрен салкынча, иртәләрен су буйлары томанга күмелә. Бакча киртәләре, каралты-кура түбәләре яңгыр яумаганда да ничектер дымланып торган кебек күренәләр.

Шулай да ул көнне сентябрь йокысыннан яшь бала кебек көлеп уянды. Уянды да көннең көн буе җылымса кояшы, сарысы, яшеле бергә кушылып торган урманнары белән, авыл өстендә көлеп торды. Ә кичен, җете кызыл шәфәгын күк читенә

җәеп, бертын балкыды да, «бүгенгә шушы шуклыгым җитәр» дигәндәй, кояшын алып, таулар арасына китте.

Фатих Хөсни.

?! **1.** Хикәяне ике тапкыр укыгыз. Китабыгызны ябып, сентябрь сыйфатларын санап чыгыгыз.

2. Хикәядән алынган бу өзектә сентябрь балага бер генә сыйфаты белән охшаган. Баланың сентябрьгә охшаган тагын нинди сыйфатларын таба аласыз?

3. Хикәянең беренче җөмләсен берничә кат укыгыз, дәфтәрегезгә язып куегыз. Аннан соң, иң мөһим сүзләрен генә калдырып, шул җөмләне кыскартып языгыз.

Кушылу.

Бик кызык бәйләнеш ул — кушылу. Ул да — каршылык белән охшашлыкның якын кардәше. Җитмәсә, алар — охшашлык белән игезәкләр дә әле. Охшашлык чәйне сөт янына куя да, икесе дә сыек, шуңа күрә охшаганнар, ди. Башта берсен, аннан соң икенчесен эчәргә куша. Ә кушылу тота да сөтне чәйгә куша. Ике өлешне бергә генә калдыра. Кушылуның тагын бер һөнәре: ул авторның куян, төлке, әтәчләр турында язганын көтеп кенә тора. Шунда ук аларны кеше теле белән сөйләтә башлый.

Йөгәнсез ат үз иркендә, ди мәкаль. Ат ат инде ул. Йөгәнен салса, койманы җимерә, тибенә, таптый, кача... Ләкин сезнең кайчан кешенең атка мәкаль әйткәнен ишеткәнегез бар? Мәкаль, ат турында булса да, таш турында булса да, барыбер кешеләргә карата әйтелә. Шуңа күрә ат, таш үзләре булып калсалар да, без аларны барыбер кешеләр итеп күз алдына китерәбез. Алар кушылганнар, дибез.

Кушу аеруча табышмакларны ярата. Аңа бу дөньяда кешене кәбестә, балык, мич, җил белән кушып уйнаудан да кызыграк уен юк.

Ул — җырларның да, әкиятләрнең дә якын дусты. Ә язучылар, ул булмаса, әсәрләренең күбесен яза алмаган булырлар иде.

Шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр язам дисәң, иң элек каршылык, охшашлык һәм кушу белән дус булырга кирәк.

ФӘН КУШКАНЧА.

Бүген баргач күреп кайттык —
Фермадагы апалар,
Ваклап-ваклап, тавыкларга
Пыяла ашаталар!

Пыяла, чып-чын пыяла,
Тотсаң, кулыңны кисәр!
Үткен-үткен ватыкларны
Йоткач, тавыклар нишләр?!

Йоттылар да, кыр-кыр килеп,
Тик йөриләр җырлашып.
Вәсимә белән без генә
Торабыз аптырашып...

Гөлфәния апа әйтә:
— Фән кушканча ашыйлар,
Кирәк булганга ашыйлар,
Шулай күкәй ясыйлар.

Күкәйне мин дә яратам,
Күкәй бит ул бик тәмле.
Тавык китап укымый ла,
Ничек белә ул фәнне?

...Чәй янында шушы хәлне
Әнигә сөйләгәндә
Төште китте стаканым —
Ватыклары идәндә...

— Әрәм иттең! — диеп, әни
Чүпләп алды савытка.
— Ник әрәм булсын, булмады —
Ашатырбыз тавыкка!

Шәүкәт Галиев.

?! Беренче өлештә төп герой тавык иде. Икенче өлешне укыгач, тавыкның төп герой булмавын белдек. Малайның уңай һәм кире сыйфатларын күрсәтер өчен генә, тавык кирәк булган икән.

Малайның шул ике сыйфатын әйтегез.

СЕБЕРКЕ.

Бер хан чирли башлаган. Гомеренең соңгы көннәре җитәсен белгәч, янына улларын чакырган да, кулларына чыбыклар тоттырып:

— Сындырыгыз,— дигән.

Уллары нечкә чыбыкларны бик тиз сындырып ташлаганнар.

Аннан соң хан шундый ук чыбыклардан бәйләнгән себерке биргән. Себеркене дә сындырырга кушкан.

Уллары тырышканнар, тырышканнар — сындыра алмаганнар.

— Менә күрдегезме инде,— дигән аталары.— Бергә җыелган чыбыкларны сындыра алмадыгыз. Мин үлгәч, дус яшәгез. Бергә булсагыз, сезне бер дошманыгыз да җиңә алмас.

?! Мәсәлдәге катнашучыларны күрсәтегез.

ШАЛКАН ТУРЫНДА.

Яз да килеп җитте. Урамнар җылынды. Пальто киеп йөрүнең кирәге калмады. Җир астыннан япь-яшь үлән калыкты. Аларны күрү үзе бер бәйрәм иде. Ул көнне Павлик балалар бакчасыннан кайтты да әнисенә:

— Әни, тагын бер атнадан безне дачага алып баралар,— диде.

— Бик әйбәт, рәхәтләнеп ял итәрсең,— диде әнисе.

— Ә мин арымадым,— дип җавап бирде Павлик.— Минем ял итәсем килми. Мин анда берәр нәрсә эшләр идем. Әллә миңа көрәк сатып аласыңмы?

— Алырмын,— диде әнисе һәм көрәк алып кайтты.

Икенче көнне Павлик көрәген бакчага алып барды. Аны балаларга күрсәтә-күрсәтә:

— Менә нинди көрәгем бар. Мин, дачага баргач, бакчага яшелчәләр утыртам,— диде.

И с т ә к а л д ы р ы й к. Хикәянең укыган өлешен, кыскартып, менә болай сөйли алабыз: «Павликның эшлисе килә. Ул әнисеннән көрәк алдыра. Бакчага килеп мактана».

Тагын да кыскартсак, «эшләү теләге» дияр идек. Хикәянең бу өлеше теләк турында булганга, аның исемен «Теләк» дип куябыз. Күрдегезме, нинди озын вакыйганы бер генә сүзгә калдырып кыскартып була икән.

Хикәянең дәвамын игътибар белән укыгыз. Калган өлешләрен дә шул рәвешле кыскартып сөйләгез һәм аларга исемнәр уйлап табыгыз.

— Бәләкәй малайның бакчада яшелчәләр үстерүен кайчан күргәнең бар? Син дә берни үстерә алмассың,— дип көлделәр балалар.

— Ник үстермим? Үстерәм,— диде Павлик.

Тавыш купты. Балалар күп. Бар да кычкыралар. Павлик гарьлегеннән еларга җитеште.

— Елама,— диде арада иң кечкенә кыз Нина.— Әйдә, бакчаны бергә үстерик! Мин сиңа ярдәм итәрмен. Без дә-әү бакча үстерербез.

— Үстерербез, ник үстермәскә! — диде Павлик.

Ул тәмам тынычланды. Балалар белән бәхәсләшеп тормады.

Кичен бакчага әбисе килгәч:

— Әби, утыртсам, бакча үсәрме? — дип сорады.

— Үсәр.

— Ә мин ни утыртыйм? Орлыкларым юк бит минем.

— Алып килермен. Иртәгә үк сатып алырмын.

Икенче көнне әбисе аңа кәгазьгә чорналган төргәк бирде. Ә ул төргәктәге орлыкларның кечкенәлеген күрсәң! Мәк орлыгы кадәр генә.

— Ни орлыклары инде болар? — дип сорады Павлик.

— Шалкан орлыклары,— диде әбисе.

— Болар бик кечкенә бит. Үсәрләрме соң?

Әбисе Павликка җирне ничек казырга, ничек итеп түтәл ясарга һәм орлыкларны ничек җиргә чәчәргә өйрәтте.

Павлик орлыкларын балалар бакчасына алып барды.

— Менә нинди шалканнарым бар минем,— дип, төргәген ачып күрсәтте.

— Нишләп шалкан булсын бу? Шалкан зур ул, ә болар вак, мәк хәтле генә,— дип гаҗәпләнделәр балалар.

— Мәк түгел, шалкан орлыклары алар. Шалкан шуларны чәчкәч үсеп чыга,— диде Павлик.

— Ничек үсеп чыга?

— Белмим.

— Үзе белми, үзе өйрәтә,— диделәр балалар һәм китеп бардылар.

?! **1.** Хикәяне кыскартып сөйләгез.

2. Тагын да кыскарта төшеп сөйләгез.

3. Шушы өлешкә бер генә сүз белән исем бирегез.

Бер атна тиз үтте. Балаларны дачага күчерделәр. Килеп җитү белән, Павлик тәрбияче апасыннан:

— Бакча утыртырга мөмкинме, апа, минем орлыкларым бар,— дип сорады.

— Мөмкин,— диде апасы һәм түтәл ясарлык урын күрсәтте.

Павлик җир казый башлады. Аны күреп, балалар җыелды. Җир каты иде. Казуы кыен булса да, Павлик бик тырышты. Башлаган эшен ташламады. Нина, аның арыганлыгын күргәч:

— Бир, әзрәк мин казыйм. Ял ит,— диде.

Нина казый башлады. Балалар карап-карап тордылар да, аларның да казыйсылары килде.

— Без дә бераз казыйк әле,— дип сорадылар.

— Казыгыз,— диде Павлик.

Балалар чиратлашып казыдылар. Төшкә кадәр түтәл әзер иде инде. Павлик тырма белән җирне йомшартты. Орлыкларын чәчә башлады.

— Без дә утыртыйк әле, без дә җир казыдык бит,— дип ялындылар балалар.

— Бер бөртек кенә булса да бир инде.

Павлик берсенә биргән иде, башкалар да сорадылар. Аннан соң һәркайсына берәрне биреп чыкты. Орлык күп иде. Кайберсе хәтта икешәрне утыртты.

Икенче көнне балалар, йокыдан уяну белән, түтәлне карарга йөгереп килделәр. Орлык тишелеп чыкканын күрергә теләделәр. Ләкин җир өсте кап-кара иде.

— Су сипсәң, орлык тиз тишелә,— диде бер кыз.

Балалар тәрбияче апаларыннан су сипкеч сорап алдылар. Суны көн дә сибә башладылар.

Берничә көн үтте, ә үсемлекләр юк та юк.

— Әллә орлыкларның башларын аста калдырып утырттыкмы? Алар аска таба үсә торганнардыр,—

диделәр балалар һәм су сипми башладылар. Павлик та тагын ике генә көн су сипте дә сипми башлады.

— Юкка көч түктек. Монда шалкан үсми,— диделәр балалар. Түтәлгә Павлик та игътибар итмәс булды. Башкалар белән урманда җиләк җыйды, кырда күбәләкләр куып йөрде...

Ә беркөнне түтәлләре өстендә яшел чирәм күреп алды.

— Безнең шалкан бит бу! — дип кычкырды Павлик. Балалар йөгерешеп килделәр.

Тагын су сибә башладылар. Чирәм, үсә-үсә, эре яфраклы үсемлеккә әйләнде. Ләкин шәһәргә кайтыр вакыт җиткән иде инде.

Балалар дачадан кайтып киттеләр.

?! Укыган өлешне кыскартып сөйләгез. Исем бирегез.

Икенче көнне дачага башка балалар килде. Берсе түтәлне күрде дә:

— Карагыз әле, монда түтәл бар! — дип кычкырды.

Түтәл янына җыелдылар. Бер төпне йолкып карадылар, икенчесен...

— Хәзер үк кире утыртыгыз! Кемдер тырышып үстергән, ә сез йолкыйсыз! — дип орышты аларны Зина.

Балалар үсемлекләрне кире күмделәр.

— Түтәлне койма белән әйләдереп алырга кирәк,— диде Зина.

Балалар карышып тормадылар. Тирә-юньнән чыбык-чабык җыеп, түтәлне киртәләп тә куйдылар.

Җәйнең эссе көннәре иде. Түтәл җире кипте. Шалканның яфраклары шиңә башлады. Зина, моны күреп, аларга кружка белән су сибәргә кереште.

Зинага ияреп башкалар да кастрюль, чәйнек, стакан тотып килделәр. Суны түтәл юешләнгәнче сиптеләр. Аннан соң абзардан иске су сипкеч таптылар һәм көн дә шуның белән сибә башладылар.

Шалкан кабат яшелләнде, бик тиз үсеп китте.

— Кем шалканы булыр бу? Аны кем утыртты икән? — дип уйга калды балалар.

— Монда безгә кадәр яшәгән балалар эше булырга тиеш,— диде Зина.

Китәр алдыннан, шалканны, йолкып, бер кучкә өйделәр.

— Ай-һай мул уңыш! — дип шатландылар. Куч тирәсенә утырып, бар да бу шалканны нишләтергә инде дип уйга калдылар.

?! Укыган өлешне кыскартып сөйләгез. Исем бирегез.

Көз дә озак көттермәде. Павлик, киенеп, урамга чыкты. Аяк астында юка бозлар чытырдый. Агач яфраклары куп коелган.

Ул көнне балалар бакчада рәсемнәр ясап уйнадылар. Тәрбияче апалары аларга билгеләр куйды. Кинәт ишек шакыдылар. Хат ташучы килеп керде. Кулында зур тартма иде.

— Сезгә посылка җибәргәннәр,— диде хат ташучы һәм тартмасын өстәлгә куйды.

Тәрбияче апалары тартманы ачкач аптырады:

— Берни аңламыйм. Ниндидер шалкан салганнар! — диде.

Барысының да шалканны күрәсе килде. Павлик хәтта урындыкка басып карады.

— Туктагыз әле, монда хат та бар икән,— диде тәрбияче.

Менә тәрбияче апалары хатны кычкырып укырга керешә: «Хөрмәтле дуслар! Сез дачадан кайтып

киткәч, шалканыгызга су сиптек. Чүбен утадык. Ә көз җиткәч йолкыдык. Ул бик зур булып, тәмле булып үсте. Без аны бик тәмләп ашадык, сезнең адресны эзләп таптык та шалканыгызны посылка итеп салдык. Сез дә яратып ашагыз».

— Без үстергән шалкан ич бу! — дип шау килде балалар.

Тәрбияче апалары тартманы, күренсен дип, урындыкка куйды. Балалар шалканга карап шаугөр килделәр. Шатлыклары эчләренә сыймады.

?! Бу өзеккә «Шатлык» дип исем бирик. Балалар ни өчен шатланалар?

Кичен бакчага әти-әниләре җыелды. Балалар аларга шалкан чәчүләре, су сибүләре турында сөйләделәр. Башта үсмичә киреләнде, бераздан кинәт тиз-тиз үсеп китте, диделәр. Аннан соң шалканны бүтән балалар үстерүе турында әйттеләр.

Бакчага кем килсә дә, балалар аңа иң элек шалканны күрсәтә торган булдылар. Аны үстерү тарихын кат-кат баштанаяк сөйләделәр.

Шалкан тартма эчендә кыш уртасына кадәр торды. Аннан соң тәрбияче аны балаларга бүлеп бирде. Шалканның тәмен сөйләп тә бетерерлек түгел иде.

— Ә бит аның орлыгы мәк хәтле генә иде. Шул нәни орлыктан әнә нинди дәү шалкан үсеп чыккан,— диде берсе.

— Павлик булмаса, шалкан да булмас иде. Ярый әле, бакчада яшелчә үстерүне ул уйлап чыгарды,— диделәр балалар.

Николай Носов.

?! **1.** Хикәянең соңгы өлешенә дә, кыскарта-кыскарта, исем уйлап табыгыз.

2. Автор шалкан орлыгы белән Павликны янәшә куя да, алар бер-берсенә охшаганнар, кайсы яклары белән охшаганнар, анысын әйтмим, үзегез табыгыз, ди. Бер баладан орлыкның төп сыйфатын әйттерә: «Ә бит аның орлыгы мәк хәтле генә иде. Шул нәни орлыктан әнә нинди дәү шалкан үсеп чыккан». Бу сүзләре белән автор Павликка нинди бәя бирә?

3. Әсәрнең бер өлеше — нәни орлыктан үскән дәү шалкан. Әсәрнең икенче өлеше — Павлик. Алар арасындагы бәйләнешне әйтегез.

4. Павликның иң зур эше шалкан үстерүдә түгел. Нәрсәдә?

ТАҢ АТКАНДА.

Уяна иркен болыннар,
Ачыла гөл керфекләре;
Тирбәнеп, яфрак өстендә
Уйный чык бөртекләре.

Уяна таңы илемнең,
Кырларга сибелә нуры;
Тиң булып безнең елларга
Балкысын гомер юлы.

Сибгат Хәким.

?! **1.** Үз сүзләребез белән әйтсәк, шигырь болай кыскарыр иде: Таң ата. Чәчәкләр ачыла. Алар әле чыклы. Кояш чыга. Автор, таң матур булсын дип, гөлләргә керфекләр куйган... (Дәвам итегез.)

2. Әсәрдә кешегә охшаган предметларны күрсәтегез.

3. Шигырьне ятлагыз.

ТАМЧЫЛАР БИИЛӘР.

Карыйм да мин сокланам:
Бу нинди иртә икән?
Һәрбер түбәдән су тама,
Каян су җитә икән?

Вак шарлар кебек тәгәрәп,
Ак карга төшә тамчы,
Үзенә ясап тагарак,
Бозларны тишә тамчы.

Ник көн дә шулай биидер,
Туктамый һич тә алар?
Мин белдем, белдем: ниндидер
Зур бәйрәм көтә алар.

Тамчылар бии тып та тып,
Тамчылар сикерәләр.
Аларны булмый туктатып,
Алар яз китерәләр.

Зәки Нури.

?! Авторны табыйк. Тамчы тама дип язган булса, безнең авторыбыз яз турында хәбәр әйтүче генә булыр иде. Ләкин ул тамчыларны «бииләр»,«бәйрәм көтәләр», «сикерәләр» ди. Тамчыга кеше сыйфатлары бирә.

Без дә автор булыйк. Шигырьне дәвам итик.

Тамчылар, җиргә төшкәч, ни эшлиләр? Ерганак булып агалар дисәк, автор була алмыйбыз. Ни бар, шуны әйтеп кенә биргән булабыз. Димәк, ерганак булып агучы тамчыларга кеше сыйфаты уйлап табарга кирәк. Уйлап табыгыз.

ЧИСТА СУ.

Алсу кая җыенган?
Су алырга чишмәдән.
Юлын белә,
урынын белә,
ул бер генә төшмәгән.

Көянтә-чиләк асып,
кыз өч адым атлауга,
суга мин дә барам дип
килеп җитә Акбай да.

Ахирәтен озатып,
ияреп бармыймы соң;
кызларның үзен генә
җибәрү ярыймы соң?!

Чишмәне дә тикшереп
чыга Акбай, килгәч тә,
эт телендә үзенчә
бирә әле киңәш тә.
. . . .

Мәхмүт Газизов.

?! Эт Алсуга нинди киңәш бирә?

Герой сыйфатлары.

Дәреслектәге рәсемгә игътибар итик. Рәсемдәге кызны әсәрдә катнашучы герой дип күз алдына китерик. Ул көзге каршында елмаеп тора, ә көзге аны усал итеп күрсәтә. Әсәрдәге геройлар да шулай елмаеп елыйлар.



Герой дигәч, ат кебек көчле, таудай биек, хәтта бүредән дә курыкмый торган батырны күз алдына китерәбез. Ә әсәрдә ул кеп-кечкенә кырмыска, куркак куян, ялкау малай, эшчән кыз да була ала.

Әдәби әсәр **герое** дип, андагы төп катнашучыларга әйтәләр.

Кырмыска да, куян да, хәтта әбинең йомгагы да әсәрдә герой була ала, дидек. Аларның үз сыйфатлары бар. Мәсәлән, кырмыска бик кечкенә, җитез, искиткеч тырыш, хәтта филдән дә көчлерәк, бер-берсе белән тату яшиләр. Әбинең йомгагы түп-түгәрәк, эче тулы уралган җеп, сүтсәң озыная, җыйсаң, кечкенә генә кала. Ләкин, әсәргә килеп керү белән, алар кеше сыйфатлары да алалар. Автор кырмыска турында яза, уйлабрак карасаң, ул тырыш кешеләрне күздә тота икән. Әби йомгагы турында язса, аны кешенең үткән гомеренә охшата. Мәсәлән, Мәҗит Гафури менә нинди кыска, ләкин бик матур шигырь иҗат иткән:

Җыеп караганда, алай бик зур
Төсле түгел күңелем йомгагы.
Сүтеп караганда, чак күренә
Аның бер ягыннан бер ягы.

Автор үзенең гомере белән йомгакны янәшә куйган. Гомер белән йомгакны кушсагыз, минем хисне табарсыз, дигән.

Кушабыз да мондый нәтиҗәгә киләбез:

Өлкән яшьтәге әдип гомеренең бик тиз үтүенә көрсенә (җыелган йомгак). Ләкин үткән гомерен исенә төшерә дә, шатлыклы, үкенечле, хәсрәтле вакыйгаларның очы-кырые юк, дип уфтана (сүтелгән йомгак).

Менә шундый могҗиза: йомгак — шул ук йомгак, ләкин аның сыйфатлары кеше сыйфатларына әйләнәләр.

Персонаж, герой.

Әсәрдә катнашучыларның берише: «Нигә безне һаман башка катнашучылар рәтендә йөртәсез. Без кешеләр бит, казлар, песиләр рәтеннән йөрергә теләмибез»,— диячәкләр. Күңелләрен күрик, моннан соң аларны **персонажлар** дип йөртик.

КОЛЫН.

— Иркен яшел болында
Чабасың да чабасың,
Син яшь кенә бит әле,
Аякларың талмасын!

— Юк, сез алай димәгез,
Көчем арта күп чапсам,
Ничек инде зур үсәрмен,
Көн буена тик ятсам?

Әминә Бикчәнтәева.

?! **1.** Шигырьдә катнашучылар ничәү? Берәүме? Икәүме? Өчәүме?

2. Әсәрдә персонажлар бармы?

3. Шигырьнең беренче өлеше — чаба торган колын. Икенче өлешен табыгыз. Бәлки, ике өлеш арасындагы бәйләнешне дә әйтерсез?

ЧЫПЧЫК.

Аудан кайтып бара идем. Бакча юлына җиткәч, этем кинәт адымын әкренәйтте. Кыргый үрдәк күргәндәй чүгәләде.

Юлга күз салдым. Алдымда башыннан сары йоны да коелмаган чыпчык баласы утыра. Җил каен агачларын бөгә-бөгә исә. Димәк, чыпчык баласы оясыннан егылып төшкән.

Минем эт аңа әкрен генә якынлаша. Ул арада якын үскән агачтан кара түшле карт чыпчык эт алдына таштай атылып төште. Менә ул, йоннарын кабартып, ямьсезләнеп, мескен чырылдап, этнең нәкъ ачык авызындагы тешенә таба ике тапкыр ташланды.

Ул үзе белән баласын каплады... Ләкин чыпчыкның нәни гәүдәсе куркудан дер-дер калтырый башлады, тавышы кыргыйланды, карлыкты. Ул үзен корбан итә иде.

Аңа эт нинди зур куркыныч булып күренергә тиеш. Алай да чыпчык агач башында утыра алмады. Куркуыннан да көчлерәк көч аны биек ботактан аска ыргылырга мәҗбүр итте.

Минем Трезор туктап калды. Артка чигенә башлады. Чыпчык батырлыгына эт тә сокланды булса кирәк.

Мин этне үз яныма чакырып алырга ашыктым. Батырлыгына хәйран калып, чыпчыкка карата тирән хөрмәт белән китеп бардым.

Көлмәгез. Мин, чыннан да, бәп-бәләкәй кошчыкның батырлыгына, мәхәббәтенең олылыгына бик-бик ихтирамлы идем.

Иван Тургенев.

?! **1.** Төп катнашучылар кайсы?

а) Эт белән аучымы?

ә) Эт белән чыпчыкмы?

б) Аучы, эт, чыпчыкмы?

в) Чыпчык белән аның баласымы?

2. Чыпчыкта үлемне җиңәрлек көч бар. Нинди көч ул?

3. Хикәядә катнашучыларны ачыкладык. Ләкин анда, күренмәсә дә, тагын бер катнашучы — ана персонажы бар. Аңа автор бәясен әйтегез.

КАЗ БЕЛӘН ТОРНА.

Буа өстендә Каз йөзеп йөри. Үзе белән үзе сөйләшә-сөйләшә йөзә.

— Гаҗәп тә кош инде үзем. Җиргә басып та йөрим. Суда да йөзәм, һавада да оча алам. Дөньяда андый кошны табып кара әле. Мин бит кошлар патшасы! — ди.

Каз сүзләрен Торна ишетеп торган икән. Торна Казга әйтә:

— Ахмак та кош син, Каз! Йә, чуртан кебек йөзә аласыңмы? Болан кебек йөгерә, лачын кебек оча аласыңмы? Бар нәрсәне әз-мәз белгәнче, бер нәрсәне бик яхшы белүгә ни җитә,— ди.

Константин Ушинский.

?! **1.** Каз хаклымы, Торнамы?
2. Казның начар һәм яхшы якларын әйтегез.

АЛМАЛАР.

«Алма агачыннан ерак төшми»,— диләр зурлар. Төшмәс инде. Әнә Таһирларның алмагачлы йортлары авылның теге-е-е очында, ә алмалары минем кесәмдә. Таһирның иң кадерле алмалары бит алар. Ул аларны иң кадерле кешемә дип саклап тота.

Урлашу яхшы гадәт түгел дә бит... Ә соң мактану яхшы гадәтмени? Мине шефка алган булды. Янәсе,

ул мине «ике»ләләр сазлыгыннан тартып чыгаруны үз өстенә ала. «Беренче «биш»ле алуыңның икенче көнендә үк мин сиңа бер әйбер бүләк итәм»,— ди. Ә мин аның нәрсә бүләк итәчәген алдан ук белеп торам. Космик корабль макеты бүләк итмәкче була миңа. Кирәге бар иде миңа синең космик корабләң.

Әгәр Таһир менә шуларны әйтеп мактанмаган булса, мин дә аның иң яраткан алмаларына тимәгән булыр идем. Иртән бакчага чыккач елап җибәрсен әле Таһирың.

Онытып торам икән: мин бүген «биш»ле алдым бит әле.

?! **1.** Хикәянең бу өзегендә ике персонаж катнаша. Аларның кайсында сыйфатлар күбрәк булса, бу өзекнең герое шул була. Өзекне укып, кем турында күбрәк беләбез?

2. Таһир — мактанчык малай. Шуңа күрә Габбас аңа җәза бирә. Шуны исбат итә аласызмы?

Бүген көн нәкъ мин уйлаганча башланып китте. Таһир сыйныф бүлмәсенә иң соңгы кеше булып керде. Култыгында газетага төрелгән әйбер бар иде. Чырае сытылган, кәефе кырылган иде аның.

Звонок булды. Таһир такта янына чыкты. Төргәкне укытучы өстәленә куйды.

Мин елмаюымны сиздермәскә тырышып, аска карап утырам.

?! Габбас нигә эчтән генә булса да елмая? Ә нигә елмаюын сиздермәскә тырыша?

Таһир авыр итеп бер сулап куйды да, минем гаҗәпләнүемә каршы, ялварулы тавыш белән:

— Гафу ит син мине, Габбас,— дип башлап китте.— Кичә син беренче «биш»леңне алдың. Мин сиңа бүләк бирергә вәгъдә иткән идем.

Таһирның тавышы калтыранып чыга.

— Ләкин мин сиңа үзем теләгән әйберне бүләк итә алмыйм бит. Хәтереңдәме, мин бервакыт сиңа бакчабыздагы алмаларны күрсәтеп йөргән идем, иң кадерле кешегә генә бирергә саклап торган идем мин аларны. Бүгенге көндә сиңа шуларны бүләк итәрмен, дип уйлаган идем. Ләкин алар үткән төндә каядыр юк булганнар.

Мин кинәт кулларымны кесәмнән тартып чыгардым. Бармак битләремне нәрсәдер пешереп, яндырып алгандай булды.

?! Икенче өзектә Таһир турында тагын ни белдек? Габбас турында ни белдек?

— Коелмадылармы икән дип эзләп тә карадым,— дип дәвам итте Таһир,— юк, берсе дә табылмады. Ләкин мин үз вәгъдәмне ничек булса да үтәргә тиешмен. Шуңа күрә бүген сиңа менә шушы корабльне бүләк итәм. Гел «биш»ләргә генә укы, Габбас.

Таһир башын аска иеп тынып калды. Кинәт бөтен сыйныф гөр-р килеп кул чабарга тотынды. «Молодец, Таһир! Молодец, Габбас!» дигән тавышлар ишетелде. Мин ирексездән урынымнан сикереп тордым да такта янына йөгереп чыктым. Үземне үзем белештермичә, алмаларны өстәлгә тезеп куйдым да космик корабльне, алып, күкрәгемә кыстым.

Бөтен сыйныф кинәт борып куйган радиоалгыч кебек тынып калды. Күзләремнән ике бөртек яшь тәгәрәде. Кызышудан бөтен тәнем тирләп чыкты. Бармак очларына кадәр кызарган кулымны Таһирга суздым.

— Га-фу ит, Та-һир! Әгәр, әгәр син теләсәң, мин бүгеннән соң синең иң якын...

Нәкъ шул вакытта коридорда, дәрескә-ә дигәндәй, шат аваз белән кыңгырау шылтырады.

Гәрәй Рәхим.

Әсәрдәге үрнәк алырлык геройга **уңай герой**, ә гыйбрәт алырлык геройга **кире герой** диләр.

?! **1.** Габбас космик корабль кирәк түгел дигән иде бит. Хәзер нигә корабльне кыйммәтле бүләк итеп кабул итте?

2. Таһир белән Габбаска бәя бирегез. Алар уңай героймы, кире героймы?

ГОРУР КАЕНБИКӘ.

Аланда япа-ялгыз
Үскән бер Каенбикә,
Ботагы — аккош муены,
Яфрагы — яшел көлтә.

Кояш аны һәр иртәдә
Нур белән коендырган.
Җир-ана үз күкрәгеннән
Су биргән, туендырган.

Җилләр чәчен тарап торган,
Яңгырлар битен юган.
Җем-җем иткән чык сулары
Аңарга алка булган.

Каенбикә горурланып
Әйтә икән җилләргә:
«Миннән гүзәл һичкем юк, дип
Таратыгыз илләргә.

Берүземә — бер кояш бит,
Берүземә — бер алан.
Табигатьтән матурлыкны
Теләгән кадәр алам».

...Язын агач утыртканнар
Бу аланга кешеләр.
Агачларның бөтенесе
Каенбикә төслеләр.

Бар да гүзәл, бар да сылу,
Аерма юк аларда.
Яфракларда чыклар уйный,
Кояш чыккан чакларда.

Барсына бер кояш җиткән,
Һәммәсенә — бер алан.
Горур Каенбикә шунда
Тәмам югалып калган.

Мактанырга теләсә дә,
Юк бертөрле чара, ди,
Каенбикә бу гадәтен
Инде онытып бара, ди.

Фәнис Яруллин.

?! **1.** Шигырьне үз сүзләрегез белән сөйләгез.

2. Әсәрне ике өлешкә бүлегез.

3. Әгәр дә икенче өлешенә «Акылга утыру» дип исем бирсәк, баштагы өлешенә нинди исем бирер идегез?

4. Каенбикә укучы балага кайсы яклары белән охшаган? Кайсы яклары белән охшамаган? Каенбикәнең кире һәм уңай якларын әйтегез.

БАКА, ТЫЧКАН, ЧАБАТА.

Беркөнне атасы малаена унбиш тиен акча бирә.

— Бар, кибеттән шырпы белән тоз алып кайт,— ди.

Малай чыгып китә. Юлда аңа бер Тычкан очрый.

— Әй малай, миңа биш тиен акча бир әле,— ди.

— Шырпы белән тоз аласы акчам гына бар шул минем,— ди малай.

— Бир инде, зинһар, мин дә берәр кирәгеңә ярармын,— дип ялвара Тычкан.

Малай бераз уйлап тора да бирә моңа акчаны. Бара торгач, каршына, сикерә-сикерә, Бака килеп чыга.

— Әй малай, бир миңа биш тиен акча, кирәгеңә ярармын,— ди.

?! Малай бакага башта ни дип җавап бирә?

Ә тагын бераз киткәч, моңа Чабата очрый. Ул да биш тиен акча сорый. Малай Чабатага да соңгы биш тиенен бирә.

?! **1.** Әкиятнең укып чыккан өлешенә исем бирегез.

2. Катнашучыларны икегә генә калдырыгыз.

Әкиятне дәвам итик.

Бермәлне артына борылып караса, Тычкан, Бака, Чабата моның артыннан киләләр. Куып җитәләр дә әйтәләр моңа:

— Син бик әйбәт малай икәнсең, сине юмартлыгың өчен буш итмәбез. Бер патша бар, аның бик чибәр кызы бар. Ул кыз бер дә көлми икән. Патша әйткән, көлдерә алган кешегә кызымны бирәм, дигән. Без ул кызны сиңа алып бирәбез,— диләр.

Тычкан белән Бака җигеләләр Чабатага. Малайны утырталар да алып китәләр патша сараена. Малай кулында чыбыркы. И чаптыралар болар, и чаптыралар!..

Чаптыра торгач барып җитәләр патша сараена. Сарай баскычында кызы белән патша үзе басып тора икән. Патша кызы Чабатага җигелгән Тычкан белән Бакага карый да чыдый алмый көләргә тотына. Эче катып көлә... Патша әйтә:

— Әһе, көлдең, хәзер үзеңне шул егеткә бирәбез,— ди.

Патша шулай дигәч, кыз да риза була.

Икенче көнне туй ясыйлар. Туйны бик шәп итеп уздыралар. Малай кызны үз өенә алып китәргә тиеш була инде. Җигәләр бик шәп атлар, арбаларга төйиләр бик күп маллар...

Тычкан, Бака, Чабата әйтәләр егеткә:

— Патша арбасына утырма, үземнеке бар дип әйт,— диләр.

— Безнең өй дә кыек бит әле, кунаклар да күп булыр,— дип борчыла егет.

— Анысы синең эшең түгел, кайгырма,— диләр.

Малайны патша арбасына утыртмакчы булалар, ләкин күпме кыстасалар да утырмый. Кыз белән икәве Чабатага утыралар. Кучер итеп алалар бер Чикерткәне. Кузгалып китү белән, Бака белән Тычкан бик яхшы айгыр булалар, Чабаталары тарантаска, ә Чикерткә чибәр генә егеткә әйләнә. Патшаның да, аның якыннарының да исләре китә бу хәлгә.

Берзаман кайтып җитәләр. Атлары зур бер сарай алдына туктый. Капка төбендә егетнең әтисе белән әнисе көтеп торалар икән. Шуннан болар тагы кырык көн, кырык төн туй итәләр.

?! **1.** Ике өлешне ялгап сөйләгез.

2. Әкиятнең икенче өлешенә дә исем бирегез.

3. Әсәрнең төп геройлары икәү. Табыгыз.

4. Кыскартып, тагын да кыскартыбрак әйтсәгез, әкиятнең ни өчен ике өлешкә бүленүен белә аласыз. Кыскартыгыз.

БИИ БЕЛМӘГӘН АЮ.

Сыза гына сандугачкай
Скрипка кылларын!..
— Әйт шуны! — дип куйды Аю,
Онытып бар моң-зарын.

Биеп киткән иде лап-лап,
Атлады тик өч кенә:
Абынып үз аягына
Ауды түмгәк өстенә.

— Сандугачын әйтер идем,
Бигрәк,— диде,— булмаган:
Нинди матур биегәндә,
Көйне бозды, уңмаган!

Хәкимҗан Халиков.

?! **1.** Шигырь аю турында да, сандугач турында да түгел. Кешеләр турында. Нинди кешеләр турында?

2. Аю үзенә нинди бәя бирә?

3. Аюга автор нинди бәя бирә?

4. Ә сез нинди бәя бирер идегез?

УЛЫМ — АКЫЛ ИЯСЕ.

Бер агай базарга барырга чыккан. Базар күреп кайтсын дип, улын да иярткән. Бара-бара, агайның бер аягы аксый башлаган. Өйдән ялгыш ике төрле ботинка киеп чыккан икән. Берсенең үкчәсе биек, икенчесенеке тәбәнәк. Бара-бара, бер аягы авырта башлаган. Улына әйткән:

— Бүген, ни өчендер, минем уң аягым сул аяктан кыскарак,— дигән.

Улы әтисенең аягына караган да:

— Әти, син ике төрле ботинка кигәнсең бит,— дигән.

Әтисе, бу сүзләрне ишеткәч, шатлыгыннан улын кочаклап үпкән.

— Бер карау белән, сәбәбен белдең. Нинди акыл иясе үсеп килә минем гаиләдә дә. Бик зур галим булырсың, улым,— дигән.

Улы, башка ботинкалар алып килү өчен, өйләренә кайтып киткән.

Чоланга кергәч, идәндә ике төрле ботинка ятканын күргән. Берсенең үкчәсе биек, икенчесенеке тәбәнәк икән. Икесен дә әтисенә алып килгән дә:

— Нишләмәк кирәк, ботинкаларның болары да ике төрле: берсе биек үкчәле, икенчесе тәбәнәк үкчәле,— дигән.

Әтисе авыр сулап куйган. Улы алып килгән ботинкаларны кигән дә, аксый-туксый, юлын дәвам иткән.

?! Агайның һәм улының мәзәктә ачылган уртак сыйфатын әйтегез.

ГАЙНИ.

Киткәннәрме соң майлап?
Урамнар бүген тайгак.
Булмаса да этүче,
Егыла һәрбер үтүче.
Мәктәптән кайта Гайни,
Аның аягы таймый.
Итекләре дагалы —
Аның шул шәп чак әле.

Күрә Гайни: бер чатта
Бер карт егылып ята.
Йөгереп бара, торгыза,
Тагын шактый юл уза.
Барган саен отыры
Күбрәк очрый карт-коры.
Гайни күк ныклы терәк
Бик күп кешегә кирәк.
Кычкыра шулчак Гайни:
— Минем аягым таймый.
Ябышыгыз кулларга,
Егылмассыз юлларда! —
Арыганнар, талганнар,
Егылганнар, ауганнар —
Бар да аңа тотына,
Зур бәладән котыла.
Командирдай иң алдан
Әй басып килә Гайни!
Уң ягында ун бабай,
Сул ягында ун әби.

Фәнис Яруллин.

?! Гайни сыйфатларын әйтегез.

Фәнис абыегызның бик матур шигырен дәвам итеп карыйкмы? Язма эшегезне болай башлагыз:

Бу күренешне бабайлар, әбиләр, абыйлар, апалар, малайлар, кызлар тәрәзәдән карап торалар икән. Аларның барысына да бер үк уй килә:

— Гайнигә әнә күпме кеше ябышып бара. Бик кызыктыр ул, Гайнигә тотынып, тауга менү,— диләр. Барысы да берьюлы, тиз-тиз киенеп, йөгерә-чаба, урамга чыгалар. Әхмәтҗан бабай чаба, аның артыннан Нәсыйха әби, алар артыннан Габдулла абзый, тагын егерме бабай, утыз әби. Ә бала-чаганың исәбе юк. Менә алар Гайниләр төркемен куып җиттеләр. Бар да бер-берсенә тотындылар һәм, шатланышып, тауга менеп җиттеләр.

Менүен менделәр, ләкин... (Дәвам итегез. Авыл халкының өйләренә кайтасы бар бит. Шуннан соң ни була?)

КОЙМАКНЫ КЕМ ПЕШЕРДЕ?

Коймакны пешерә башлау белән, мич алдында сүз көрәштерү китте. Иң элек таба белән табагач тавышландылар.

— Мин булмасам, коймаклар пешмәсләр иде, син алар белән үзең дә мичтә калыр идең. Мин бит сине мичтән тартып чыгаручы! — диде табагач һәм табаның читеннән тешләп алды.

— Җибәр мине! — дип шалтырады таба. Бодай камыры, артык кабарып китеп, мискинең читенә ташып чыкты.

— Миннән башка сез һичкайчан да коймак пешерә алмас идегез,— диде ул, таба белән табагачка карап.

— Ә сине кем камырга әйләндерә? — диде салкын су, тамчыларын чәчрәтеп.

— Ә кабартучы кем? Мин булмасам, син бит кабара алмыйсың! — дип, үз сүзен әйтте йомырка. Сары май йомыркага каршы төште:

— Юкны сөйләмә, туганкай, мин аны беркайчан да табага ябыштырмыйм,— диде, чаж-чож итеп.

— Син кем аркасында чыжлыйсың? — дип кычкырдылар аңа шарт-шорт итеп яткан утыннар һәм үзләрен санга санамаганга ачуланып, коймакларның өстен көйдереп алдылар...

— Гафу итегез, сез кайда янганыгызны беләсезме? — дип сорады утыннардан мич һәм, көчен күрсәтергә теләгәндәй, морҗасыннан, бөркеп-бөркеп, төтен чыгарды.

Кучкарда бер кап шырпы бар иде. Ул да телгә килде:

— Һи, мин булмасам, нишләр идегез икән сез! — диде ул мичтәге утыннарга.

Сүзгә кашык та катнашырга җыенган иде. Ләкин ул үзенең көндәше — кечкенә чүмеч барлыкны хәтерләде һәм эченнән генә: «Мин булмасам, коймакны мискидән табага чүмеч белән алып

салып була ич»,— дип уйлап алды да бер сүз дә әйтмәде.

Тоз да икеләнде: «Тозсыз коймак булмый, әлбәттә. Шулай булса да масаймыйм әле. Мин бит судан башка эри алмыйм»,— дигән фикергә килде һәм бәхәстән читтә калды.

?! Бәхәскә катнашучыларның уңай һәм кире якларын әйтегез.

Хикәяне дәвам итик.

Мичтә, дөрли-дөрли, утын янды, табада май сызгырды, табагач белән таба һаман бер-берсенә бәрелеп торды. Шулвакыт:

— Монда иң зур абыегыз бар әле, сез аны оныттыгыз,— дип, мич алдына килеп басты таза беләкле хезмәт.— Бодайны, чәчеп үстереп, он итүче, чуенны коеп — таба, тимерне эретеп, табагач ясаучы кем? Ул — мин!

?! Хезмәт тагын ниләр әйтә?

Хезмәт аларның һәрберсенә берьюлы карап алды. Аннары берәмләп аңлатырга тотынды. Элек табагачка әйтте:

— Син, табаны читеннән мин эләктереп торам дип, гел мактанасың. Әгәр мин сине тотмасам, син табаны үзең генә эләктерә алыр идеңме? Юк!

Табагач тавышлануыннан туктады.

?! Хикәяне дәвам итегез. Хезмәт башкаларга нинди сүзләр әйтер?

Инде коймак пешерү тәмам булды. Утыннар янып, май эреп бетте. Коймаклар, җыелышып, өстәлгә таба юл тоттылар. Табагач, үзенең күптәнге сабына таянып, стена буена барып сөялде, чуен таба киң һәм тигез йөзе белән сәкегә капланып ятты.

Хезмәт коймакларны ашарга утырды.

Гариф Галиев.

?! Хикәяне ике өлешкә ничек бүләр идегез? Бүлеп карагыз әле.

Үзегезне хезмәт итеп күз алдына китерегез.

Менә сез бодай үстердегез: чәчтегез, урдыгыз, уңышыгызны тегермәндә тарттырдыгыз, ди. Аны он иттегез, мискигә он, чүпрә, йомырка, сөт салдыгыз да камыр бастыгыз. Аннары уйнарга чыгып киттегез, ди. Һәм эшегезне оныттыгыз... Үзебез уйлап тапкан хикәяне дәвам итегез.

?! **1.** Шул чакта табагач белән таба нәрсә турында сөйләшер, аларга бүтәннәр ничек кушылыр?

2. Хикәядә «коймакны мин генә пешерәм» дип мактанучылар күп. Ләкин коймак юк. Хәзер берсе дә дәшми. Сез — хезмәт. Сез аларга ни дисез?

ЭШ КУШЫП БУЛМЫЙ.

— Савыт-сабаны ю! — дисәң,
— Юдым! — ди Гәүһәр.—
Юдым инде, киптерергә
Куйдым,— ди Гәүһәр.

— Келәм... — диеп авыз ачсаң —
Кагып өлгерткән.
Кушарга эш тә калмаган,
Өйдә эш беткән!

— Кибеткә бар, алайса! — дим.
— Кайттым инде,— ди.
— Бер конфет ал! — дим.
— Икене каптым инде! — ди.

Шәүкәт Галиев.

?! **1.** Гәүһәрнең ике сыйфатын әйтегез.

2. Шигырь исемендә автор шаянлыгын табыгыз.

3. Шул ук исемне калдырып, шигырь вакыйгасының капма-каршысын үзегез языгыз.

АКСАК КАЧЫР.

Өч бертуган юлга чыккан.

— Әй егетләр! Ишәгемне югалттым, күрмәдегезме? — дип сораган бер кеше.

— Күрмәдек шул,— диганнәр егетләр һәм юлларын дәвам иткәннәр.

— Ишәк югалтмаган, качыр[1] югалткан,— дигән туганнарның өлкәне.

— Аксак качыр булган. Сул аягы авырткан,— дип өстәгән уртанчысы.

— Җитмәсә, уң күзе сукыр булган,— дип тәмамлаган кече туган.

Аларның шулай сөйләшүләрен әлеге кеше арттан ишетеп бара икән.

— Туктагыз! — дип кычкырган качыр хуҗасы.— Дөрес әйтәсез. Ишәк түгел — качыр. Ә сез аның качыр булуын каян беләсез? Кайсы якка китте ул?

— Күрмәдек дип әйттек бит инде! — дип җавап биргәннәр туганнар.

— Күрмәгәч, качырның аксак, сукыр булуын ничек белдегез? Сез аны күрү генә түгел, урлагансыз да. Йә, әйтегез, кайда яшердегез? Хәзер үк бирегез.

— Алмаган хайванны ничек бирик, ди, без сиңа? — дигәннәр туганнар.

Шулай, бәхәсләшә-бәхәсләшә, бер авыл эченә кергәннәр. Авылда туп-туры казый янына барганнар.

Казый туганнардан:

— Менә бу кеше сезне караклар дип гаепли. Сез аның качырын урладыгызмы, юкмы? — дип сораган.

---

[1] Качыр — аттан тәбәнәк, ишәктән зуррак хайван.

— Юк, безгә бер качыр да очрамады,— дигәннәр туганнар.

— Алдыйлар! Күрмәгәч, алар качырның сукыр, аксак булуын каян белгәннәр?! — дип кычкырган гаепләүче.

Казый аны бүлдергән.

— Дөрестән дә, сез аның качыр булуын ничек белдегез соң? — дип сораган.

— Әгәр ул ишәк булса, аның аяк эзләре җиргә бертигез баткан булыр иде. Ә без күргән эзләрдә арт аяклар тирәнрәк баткан. Качыр гына шулай йөри,— дип аңлаткан өлкән туган.— Без аның качыр булуын эзләреннән белдек.

— Ярый, шулай да булсын, ди. Ә аның сукырлыгын ничек белдегез?

— Без бит басу кырын аркылы чыга идек. Юлның ике ягында безнең җилкәгә җитәрлек биек бодай үсә. Ул иртәнге чык белән капланган. Сул яктагы бодайда чык юк иде. Ә уң яктагысындагы чык кояшта нур чәчеп тора иде. Шулай булгач, качыр сул якка ава-түнә барган дигән сүз. Сул аягы авырткан дип шуңа әйтәбез,— дип җавап биргән уртанчы туган.

Казый уртанчы туган дәлиле белән дә килеште.

— Ә малның сукыр булуын, җитмәсә, нәкъ уң күзе күрмәвен ничек белдегез? — дип сораган.

— Хуҗа туйганчы ашаткан булса, качырның сукыр булуын берничек тә белә алмас идек. Ләкин хайван ач булган. Юлда бодай башагын кимереп

барган. Бодайның сул ягы гына кыркылган, чөнки качыр уң күзе белән башак күрмәгән,— дип аңлаткан кече туган.

Казый, туганнарның акыллы җавапларын тыңлаганнан соң, өчесен дә гаепсез дип тапкан. Ә мал хуҗасына:

— Мин бу егетләрнең гаепсез булуына ышандым. Әгәр син дә алар кебек игътибарлы булсаң, качырың югалмас иде. Бар, эзләвеңне дәвам ит,— дигән.

Качыр хуҗасы, авыз эченнән кемнедер ачулана-ачулана, аксак, ач, уң күзе күрми торган качырын эзләргә чыгып киткән.

?! **1.** Өч туганның уртак сыйфатын әйтегез.

2. Качыр хуҗасының төп сыйфатын әйтегез.

3. Менә хәзер хикәяне ике каршы якка бүлү җиңел. Бүлегез.

СӘҮДӘГӘР ҺӘМ ПОШИ.

Бер сәүдәгәр яшәгән. Бик оста сатучы булган ул. Теләсә кемгә теләсә нәрсә сата алган. Мәсәлән, ипи пешерүчегә ипи сатып җибәргән. Сукырны, синә, һичшиксез, телевизор кирәк, дип ышандырган. Ә ялкау малайга көрәк саткан.

Авылдашлары аңа:

— Бик оста сәүдәгәр син. Теләсә кемгә теләсә ни сата аласың. Ә менә Пошига противогаз сата



алыр идеңме? — дип сораганнар. Сәүдәгәрнең сер бирәсе килмәгән. Озын-озак уйлап тормаган. Шул көнне үк төньякка карап юл тоткан. Куе кара урман эченә кергән. Анда фәкать пошилар гына яшиләр икән.

Бераз бару белән, бер Поши очраган.

— Хәерле иртә, Поши! Сиңа ни җитмәгәнен беләсеңме? — дип сораган ул Пошидан.

— Юк,— дип җавап биргән Поши.

— Ә менә мин беләм. Сиңа противогаз җитми,— дигән сәүдәгәр.

— Нишлим мин ул нәрсә белән? Мондагыдай чиста һава беркая да юк бит,— дигән Поши.

— Бу заманда берәү дә противогазсыз йөрми,— дип җавап биргән сәүдәгәр.

— Рәхмәт, ләкин миңа противогаз кирәкми,— дигән Поши.

— Бик, бик ялгышасың. Ялгышуыңны тиздән үзең дә күрерсең,— дигән сәүдәгәр һәм урманның нәкъ урта бер җирендә фабрика төзи башлаган.

— Акылдан шаштыңмы әллә? Анда пошилар гына яши бит,— дигәннәр аңа дуслары.

— Акылдан шашмадым,— дигән сәүдәгәр.— Пошиларга противогаз сатарга телим.

Фабрика төзелеп беткән. Эшли башлаган. Морҗасы бөтен урманны төтен, агулы газ белән тутырган.

Тиздән әлеге Поши үзе чабып килгән.

— Чыннан да, миңа противогаз кирәк булган икән,— дигән.

— Әйттем бит мин сиңа кирәк булачак,— дип, сәүдәгәр противогазын саткан.— Бик әйбәт, сыйфатлы противогаз,— дип мактап та куйган.

— Тагын бармы? Башка пошиларга да кирәк булачак бит алар,— дигән Поши.

— Бәхетле икәнсез. Миндә алар меңләгән,— дигән сәүдәгәр.

— Бер килгәч, белеп китим әле: син ул фабрикаңда ни ясыйсың соң? — дип сораган Поши.

— Ни ясыйм? Противогазлар ясыйм,— дигән оста сәүдәгәр.

Франц Холер.

?! **1.** Әсәрне укып чыктыгыз. Кайсы вакыйгаларны истә калдырдыгыз? Китапны ябып, үзегезгә үзегез сөйләгез.

2. Әсәрнең төп вакыйгасы мондый: сәүдәгәр пошиларга яхшылык эшли. Нинди яхшылык эшли? Ләкин сәүдәгәр пошиларга начарлык та эшли. Нинди начарлык эшли?

3. Сәүдәгәрнең уңай һәм кире ягын әйтегез. Пошиның төп сыйфатын әйтегез. Сезгә бу ике катнашучының кайсысы күбрәк ошый?

Сәүдәгәрнең уңай ягы: ул акыллы. Өстәвенә эш кешесе дә. Тиз арада әнә күпме эш башкарырга өлгергән бит. Сәүдәгәрнең үзегезгә охшамаган ягын әйтегез.

ТЫЛСЫМЛЫ КАЗАН.

Яз башында бер крестьян, җир сөрергә дип, кырга киткән. Сөрә торгач, бервакыт, нәрсәгәдер эләгеп, сукасының төрәне[1] сынган.

— Менә бәла! — дигән абзый, борчылып.— Монда беркайчан да таш та, тамыр да, агач төбе дә булганы юк иде. Төрәнем нилектән сынды икән?

Аптырап, шул җирне казырга тотынган. Чокырдан зур казан килеп чыккан. Абзый башта ачуыннан казанны ватып атмакчы булган. Ләкин

[1] Төрән — суканың туфракны кисеп бара торган өлеше.

уйлап-уйлап торган да ватмаган. Әйдә, балчыктан гына булса да, яңгыр суы салырга ярар әле дип, өенә алып кайткан.

Өендә табышын чистарта башлаган. Эшен бетереп килгәндә генә, пычагы казан эченә төшеп киткән. Пычагын чыгарган, ләкин казан төбендә шундый ук тагын бер пычак ятканын күреп алган.

Әллә бу казан тылсымлы микән дип, бакыр акча төшереп караган. Акчасын алу белән, казан төбендә шундый ук бакыр акча барлыкка килгән. Тагын бер тәңкә төшереп караган — бу юлы да казан төбенә шундый ук тәңкә тәгәрәп төшкән.

Абзый эшен дәвам иткән. Көне буе, казанына акча төшереп, аннан өстәмә акча алган.

Абзыйның бу эшен балалары карап торган. Шуңа күрә икенче көнне тылсымлы казан турында бөтен авыл белгән.

Төштән соң моның өенә күршесе кергән.

— Синең җирең минеке белән ызандаш. Димәк, казан да уртак булырга тиеш. Син аны уртак ызаннан казып чыгаргансың,— дигән.

Бәхәс купкан. Бәхәсне хәл итү өчен, казыйга киткәннәр.

Абзый казыйга казанны үз җиреннән табуын сөйләгән.

— Казанның тылсымлы булуы дөресме? — дип сораган казый.

— Тылсымлы! Тылсымлы! — дип раслаган хөкем залында утыручы авыл халкы.

— Табышыңны күрсәт. Тылсымын үз күзебез белән күреп белик,— дигән казый.

Абзый казанны, китереп, өстәлгә куйган. Казый алтын акчасын аңа төшереп, кире алган. Казан төбенә караса — шундый ук алтын акча ятканын күргән.

— Дөрес сөйләгәнсез. Казан, чыннан да, гади казан түгел икән. Хакыйкатьне табу җиңел булмас. Алай да тырышып карарбыз,— дигән казый.

Өч сәгать уйлаганнан соң, ул абзыйдан:

— Әгәр казан күршеңә тиеш дисәм, хаклы буламмы? — дип сораган.

— Дөрес хөкем булмас, диячәкмен, казый әфәнде,— дигән абзый.

Абзыйның күршесенә дә казый шундый ук сорау биргән:

— Ә хәзер син әйт: әгәр казанны сиңа тиеш түгел дисәм, хаклы буламмы? — дип сораган.

— Дөрес хөкем булмас, диярмен, казый әфәнде,— дип җавап биргән күрше.

— Хаклы хөкем чыгаруның кыенлыгын күрдегезме инде,— дигән казый.— Бәхетегез, минем янга килгәнсез. Мондый чуалчык төенне миндәй акыллы, гадел казый гына сүтә ала. Гадел хөкем мондый: берегезне дә рәнҗетмәс өчен, казанны мин үземдә калдырырга карар кылдым. Барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз. Моннан соң талашып йөрмәгез.

Күршеләрнең казый хәтле казый белән бәхәскә керергә кыюлыклары җитмәгән. Казыйны сүгә-сүгә, башларын иеп, өйләренә кайтып киткәннәр.

Ә казый, бүлмәсендә үзе генә калгач, ишеген барып бикләгән. Ашыгуы белән, тәрәзәдән очып кергән умарта кортларын күрми дә калган.

Умарта кортлары бүлмәдә очып йөргәннәр-йөргәннәр дә ял итәргә казан эченә кергәннәр.

Казый башын казан авызына якын китерүе булган, битен умарта кортлары сарып алган. Күзләренә, яңакларына, борын һәм колакларына үткен укларын батыра башлаганнар.

Кычкырса да, селтәнсә дә файдасы тимәгән. Казаннан бертуктаусыз яңадан-яңа корт чыгып чаккан.

Казый үз әтисе дә танымас хәлгә килгән. Бите кабарып, шешеп чыккан, үзе шалканга, ә колаклары зур ләгәннәргә охшап калган.

Шеш казыйның күзләрен каплаган. Урамга чыгу өчен, ишек эзләгәндә, йөгереп килгән килеш, ишек дип, казанга килеп бәрелгән. Балчык казан челпәрәмә килеп ватылган. Кортлар тәрәзәдән очып чыкканнар.

Казый иртәгесен генә аңына килгән. Янында басып торучы зур кара күзлекле табиблар күргән. Алар казыйны ел буе дәвалаганнар. Дәвалаган өчен, казыйның бөтен акчасы киткән. Ләкин барыбер терелеп җитмәгән. Корт чаккан бер күзе кылый булып калган.

?! Казан табучы крестьян — хезмәте белән көн күрүче гап-гади кеше. Күршесе — комсыз кеше. Әсәрдә казыйның ике сыйфаты бар. Шул сыйфатлары турында сөйләгез.

ЯЛКАУ ПАТША ҺӘМ ҮРМӘКҮЧ ТУРЫНДА.

Бик күптән бер ялкау патша яшәгән. Түшәгеннән кузгалмыйча гына, тамагын туйдырган.Тешен чистарткач, газета укыштырган. Шулай, конфет суырып, газета укып, көннәр буе яткан да яткан. Хәер, кайчак йоклап та алган.

Кичләрен аңа гармунчы, барабанчы һәм курайчы, килеп, төрле көйләр уйнаганнар. Алар киткәч, патша, сөт белән прәннек ашап, йокыга тала торган булган.

Патша хатыны нишләргә дә белмәгән. Баш вәзирне чакыртып, аңа елый-елый зарланган:

— Көне буе урын өстендә ята. Халык бу хәлгә бер дә риза түгел. Патшаны күргәнебез дә юк. «Яшәсен патша! Ура, патша!» дип кычкырырга тилмереп яшибез, диләр. Урыныңнан тор, дип ялынам. Колагына да элми. Ята да ята,— дигән.

— Еламагыз, галиҗәнап,— дигән баш вәзир һәм эшләпәсен киеп, өенә кайтып киткән. Көне буе патшаны ничек аягына бастыру турында баш ваткан.

Баш вәзир бакчасында бер үрмәкүч яшәгән. Исеме Гораций булган. Бу көнне дә ул, гадәтенчә,

үзенең оясында ял иткән. Патша хатынының бауга кер элүен, баш вәзирнең әрле-бирле йөреп, баш түбәсен кашып алуын күзәткән.

— Нигә һаман башыңны кашыйсың? — дип сораган вәзирдән хатыны Матильда.

— Баш түбәсен кашу уйларга ярдәм итә. Патшаны ничек урыныннан кузгату турында уйлыйм,— дип җавап биргән ире.

Гораций баш вәзир сүзләрен тыңлап торган. «Бәлки, мин ярдәм итә алырмын. Эшләпәсе эченә керсәм, баш түбәсен кашыр да кашыр. Күбрәк кашыган саен, күбрәк уйлар. Күбрәк уйлаган саен, башына матур фикер килер»,— дип уйлаган үрмәкүч. Шулай иткән дә.

Эшләпә нәкъ пәрәвез оясы астында икән. Үрмәкүч оясыннан җепкә ябышып төшкән дә эшләпәнең бер почмагына поскан.

Баш вәзир чәй эчкән, эшләпәсен киеп, патша сараена киткән.

Шулчак Гораций моның баш түбәсен кытыклаган.

— Ай, кытык килә! — диюен сизми дә калган вәзир һәм баш түбәсен кашып алган. Кашып җибәрүе булган — башына менә дигән фикернең килеп төшүе булган.

— Таптым! Уйлап таптым. Хәзер ни эшләргә беләм,— дигән баш вәзир.

Гораций эшләпә эченнән чыккан.

— Миңа син ярдәм иттең. Синнән дә акыллы кем бар икән?! Син кычыттыру белән, башны

кашыдым. Кашу белән, патшаны урыныннан торгызу өчен, чара уйлап таптым. Бар да шатланыр хәзер. Патша хатыны да, халык та,— дигән үрмәкүчкә баш вәзир.

Сарайга ул арт ишектән кергән. Фикерен патша хатынына әйткән. Аннары, барабанчыны очратып, аңа да планын сөйләп биргән. Барабанчы планны курайчы белән гармунчыга җиткергән. Вәзир башына килгән фикер аларга да ошаган. Бар да баш вәзир билгеләгән вакытка патша ятагына җыелганнар.

Патша сөенгән. Менә монда, менә монда утырыгыз дип, караваты читеннән урын күрсәткән. Уйнаучыларны тыңларга хатынын да чакырган.

Бераздан бүлмә барабан, гармун, курай тавышларына күмелгән. Барабанчы таяклары белән барабанын җан көченә кыйнаган, гармунчы белән курайчы булдыра алганча кычкыртып уйнаганнар.

— Бигрәк акыртасыз. Тынычрак, ягымлырак итеп уйнагыз,— дигән патша.

— Юк, юк, бик матур уйныйлар. Шулай уйнасыннар,— дигән хатыны.

Музыкантлар тагын да куәтлерәк уйный башлаганнар.

— Бик матур уйныйсыз,— дип, аларны патша хатыны мактап торган.

— Шулкадәр ягымлы, тәэсирле яңгырый,— дип кушылган аңа баш вәзир.

— Шушы булдымы ягымлы, тәэсирле көй?! Әллә мин акылдан шашаммы? — дип борчылган патша һәм оркестрга, сарай капкасы янына чыгып, шунда уйнарга кушкан.

Музыкантлар капка янына чыгып басканнар. Ләкин уйнаган булып кыланганнар гына. Тавыш чыгармаганнар.

— Нигә көйләре ишетелми? — дип сораган патша.

— Менә дигән көй. Гомердә шундый матур итеп уйнаучыларны ишеткәнем юк иде,— дип мактаган патша хатыны.

— Шундый оста уйныйлар,— дип кабатлаган баш вәзир.

Патша ни уйларга да белмәгән. Урыныннан торып, тәрәзәдән караган. Капка төбендәге уенчыларның тырышып-тырышып уйнауларын үз күзе белән күргән. Уйныйлар, ләкин ни өчен мин берни ишетмим дип аптыраган патша.

Бу хәлне ачыкларга кирәк булыр, дип уйлаган һәм кунакка барганда гына кия торган таҗын китерергә кушкан.

— Тузанланып, каралып беткән инде ул. Күп еллар киштәдән төшкәне юк бит,— дигән баш вәзир.

— Булса ни! Тузанны аны өреп төшерергә була. Мин хәзер үк урамга чыгам,— дигән патша.

Менә ул, таҗын, алтын белән чигелгән ябынчасын киеп, урамга чыккан.

Патшаны күрү белән, музыкантлар, уйнаган булып, капкадан чыгып киткәннәр. Көйләрен ишетмәмме дип, патша артларыннан ияргән.

Халык патшаны урамда күреп шатланган.

— Хәерле иртә, галиҗәнап,— дип каршы алган. Кулын кысып күрешкән. Ә берсе хәтта туңдырма да бүләк иткән.

Зур мәйданга җиткәч, музыкантлар чынлап торып уйнарга керешкәннәр. Патша бу очрашудан бик канәгать булып калган. Китап кибетенә кереп, кызыклы хикәяләр сатып алган. Күмер ташучы аны үзенең арбасына утыртып йөрткән.

Сарай капкасы янында патшаны хатыны белән баш вәзире каршы алган.

— Бик күңелле булды. Моннан соң көннәр буе түшәктә ятмыйм. Тәхетемә менеп утырам да халыкны ничек эшләргә өйрәтәм. Арыгач, урамда йөреп керәм. Хәзер мин яхшы патша булачакмын,— дигән.

Патша хатыны шатлыгыннан баш вәзирне үбеп алган.

— Рәхмәт сезгә. Планыгыз, чыннан да, уңышлы булып чыкты,— дигән.

— Гораций эше ул. Минем бакчада яши торган үрмәкүчне, бәлки, беләсездер дә әле. Миңа ул ярдәм итте. Эшләпә эченә керде дә баш түбәсен кытыклады. Башка шунда ук матур фикер килеп төште. Уңышлы план — шул фикер нәтиҗәсе,— дигән баш вәзир.

— Кара син аны! Бик акыллы үрмәкүч икән! — дигән патша хатыны һәм үрмәкүчне кичке ашка кунак итеп чакырырга кушкан.

Баш вәзир чыгып китү белән, патша хатыны үрмәкүч өчен алтын пәрәвез оясы бәйләргә утырган.

Ханс Кристиан Андерсен.

?! **1.** Әкиятне әкият итә торган могҗизаларны табыгыз.

2. Патшаның бер сыйфаты күренеп тора: ул ялкау. Ләкин аның уңай сыйфаты да бар. Уңай сыйфатын табыгыз.

3. Үрмәкүч сыйфатын әйтегез.

4. Баш вәзир сыйфатын әйтегез.

5. Патша хатынының бик матур ике сыйфатын әйтегез.

БАКЧАЧЫЛАР.

Лагерьга килеп урнаштык. Икенче көнне вожатый Витя:

— Безнең яшелчә бакчабыз булачак,— дип белдерде.

Җыелып, эш тәртибе турында сөйләштек. Җирне икешәр кешегә бүлеп бирәбез. Шулай итсәк, кайсы бригаданың ничек эшләве күренеп торачак. Артта калганнарга ярдәм итик, дип килештек.

Без Мишка белән бер бригадага язылдык. Монда килгәнче үк, бергә булырга карар кылган идек. Кирәкләр дә уртак. Балык тоту өчен колгалар

да, кармаклар да... Балыкны да бергә тотарга ниятләдек.

— Әйдәгез, кызыл байрак ясыйк. Җирен кем тизрәк казып бетерә, «Иң тырыш бригадага» дип язылган байрак шуңа бирелә,— диде вожатый Витя.

Барыбыз да бу тәкъдим белән килештек. Аннары байрак иң әйбәт утыртучыга, аннан соң иң әйбәт чүп утаучы бригадага күчәчәк, соңыннан иң күп уңыш алучыга бирелә, дип сүз куештык.

— Кызыл байрак өчен көрәшик. Иң башта алыйк та кулдан ычкындырмыйк,— диде Мишка.

Безгә елгага якын уникенче бүлем җир эләкте.

— Иң начар җир безнеке! Уртасында чокыр, җитмәсә, агач төбе кукраеп утыра,— дип кычкырды Мишка.

— Тишек дигәнегез ат тоягы эзе генә. Ә төпләр башкалар җирендә дә бар,— диде Витя. Ләкин Мишка башкалар җире белән кызыксынмады:

— Аны казып чыгарасы бар бит,— дип үҗәтләнде.

— Казырсыз. Булдыра алмасагыз, ярдәм итәрбез,— диде вожатый.

— Безгә ярдәм кирәкми. Үзебез дә казый алабыз,— дип үпкәләде Мишка.

Бар да эшкә керештеләр. Без дә казый башладык.

Мишка ике-өч көрәк җир алып ташлый да башкалар эшен карап килә.

— Эшлә, әрле-бирле чапма, артта калабыз бит,— дим.

— Курыкма. Мин бер кызып китсәмме...— диде Мишка һәм кызу-кызу казый башлады. Кызу-кызу казый да көрәген ташлап әйләнеп килә. Казый башлый да әйләнеп килә...

Ул көнне без эшне әллә ни майтара алмадык. Төштән соң көрәкләргә тотынган идек, Витя эшкә җибәрмәде.

— Узам дип, беренче көнне күп эшләсәгез, башка көннәрдә эшли алмаячаксыз,— диде.

Икенче көнне без барыннан да алда эшкә чыктык. Бераздан Мишка, Витядан рулетка алып, казылган җирне үлчәргә керәште. Бераз казый да үлчи, казый да үлчи. Үлчәгән саен, аз эшләгәнбез дип сукрана.

— Аз булмыйча, син эшләмисең бит. Үлчәп кенә йөрисең,— дим.

Менә ул рулеткасын ташлады да казырга керәште. Ләкин бераздан көрәге агач тамырына эләкте. Тамырны тарткалады-йолыккалады, бөтен җирне бозып бетерде. Хәтта күрше җиргә чыгып тарткалады.

— Ташла, тамырга ябышмагансыңдыр бит,—дим.

— Очы булырга тиеш бит инде аның!

— Нигә кирәк ул сиңа?

— Юк инде. Мин бер эшкә тотынсам, ахырына җитмичә туктамыйм,— диде Мишка һәм тагын тамыр тартырга тотынды. Ачуым килде. Тоттым да, көрәк

белән бәреп, тамырны өзеп ташладым. Мишка рулеткасын алып үлчәргә кереште:

— Күрдеңме! Алты метрдан артык. Өзмәгән булсаң, егерме метрга җиткән булыр иде,— диде.

— Синең болай эшләвеңне белгән булсам, бригадага башка берәүне сайлаган булыр идем.

— Бар соң, үзең генә эшлә. Мин кушканга эшлисеңме әллә?.. — ди.

— Күпме казыгач, ничек китим, дим. Синең аркада кызыл байракның бер очын да күрмәячәкбез.

— Нигә алмаска, әнә кара, Ваня белән Сенялар бездән дә азрак казыганнар.

Шулай диде дә Мишка Ванялар җиренә китте.

— Бигрәк ялкау икәнсез. Сезне буксирга алырга туры килмәгәе,— дип, алардан көләргә тотынды.

— Үзеңне буксирга алырга туры килмәгәе,— дип, аны үз җирләреннән куып җибәрделәр.

— Кешедән көлгән буласың тагын, үзең күпме казыдың соң? Нигә генә бәйләндем синең белән! — дип ачуландым.

— Бер дә борчылма. Мин бер хәйлә уйлап таптым. Байрак безнеке булыр.

— Акылдан язгансыңдыр син. Ике көнлек эшне синең белән дүрт көндә дә тәмамлап булмаячак. Күп сөйләмә, казы. Җир үзе казылмый ул.

Мишка көрәгенә ябышкан гына иде, Витя төшке ашка чакырды.

Төштән соң, җыйнаулашып, кызыл флаг ясадык. Берәүләр таягын юндылар, башка берәүләр

чүпрәген тектеләр. Таякны алтын төскә буядык. Ә чүпрәгенә Витя «Иң тырыш бригадага» дип язып куйды.

— Әйдә, каргалар куркытырга карачкы ясыйк,— диде Мишка. Колга табып, аңа аркылы таяк бәйләдек. Иске капчыктан күлмәк тегеп кидердек. Колга очына балчык чүлмәк урнаштырдык. Мишка чүлмәккә күмер белән авыз, борын, күзләр ясап куйгач, карачкыбыз карга түгел, хәтта олы кешеләрне куркытырлык булып чыкты. Балалар карачкыдан көлгән арада, Мишка мине читкәрәк алып китте дә:

— Мин менә нәрсә уйлап таптым. Әйдә, җирне төнлә кеше күрмәгәндә казыйк. Беразын гына калдырырбыз да иртән эшне беренче булып тәмамларбыз,— диде.

— Эшләсәң бер хәл иде. Эшләмисең бит син, җыен юк-бар нәрсә белән шөгыльләнәсең! — дим.

— Әйбәт эшләрмен. Менә күрерсең!

Кичен башкалар йокларга яткач, без юри күзне йомып яттык. Йокы баса башлаган иде инде, Мишка җилкәдән селкеп уятты:

— Тор, байрактан коры калабыз.

Шыпырт кына тордык. Кирәкләрне алып кузгалдык. Ай якты. Җиребезгә килеп җиттек.

— Безнеке менә монысы. Әнә агач төбе, күрәсеңме? — диде Мишка.

Эшкә тотындык. Мишка да тырышып казыды. Күп эшләдек. Агач төбенә җиттек. Аның як-ягын тирән итеп казыдык. Тарттык, тарттык — җирдән

куптара алмадык. Тамырларын көрәк белән өзәргә кирәк булды. Ат кебек арысак арыдык, төпне сөйрәп чыгардык. Ул урынны тигезләдек. Төпне елгага сөйрәп ярга җиткәч, суга төртеп төшердек. Тамырларын җәеп агып киткәнен шактый озак карап тордык.

Иртән барыннан да соң уяндык. Бөтен тән сызлый. Куллар авырта, аяклар авырта, арка авырта.

Торып юындык, бераз тәннәрне язып алдык. Аш алдыннан Мишка:

— Кызыл байракның колагын да күрмәячәксез, ул безгә булачак,— дип, башкалар алдында мактанырга тотынды.

Тамак ялгаганнан соң, бар да үз җирләренә ашыкты. Без ашыкмый гына кузгалдык. Килеп җиттек. Бар да казына, без бүлемнәрне әйләнеп йөрибез.

— Кызыл байракның барыбер колагын да күрмәячәксез,— дип мактануын дәвам итте Мишка.

— Комачаулап йөргәнче, үз җирегезне казысагыз яхшырак булыр иде,— диделәр балалар.

Мишка, бер җиргә күрсәтеп:

— Ә бу кем бүлеме? Иң аз казылган җир. Хуҗалары хыр-хыр килеп йоклап яталардыр әле,— диде.

Карыйм — уникенче бүлем.

— Безнең җир бит бу! — дим.

— Булмас, без төнлә күп казыдык,— ди Мишка.— Бәлки, берәрсе юри номерын алыштыргандыр.

— Юк, безнең җир. Бу якта әнә унберенче, икенче якта унөченче бүлемнәр.— Күрәбез: агач

төбе үз урынында кукраеп утыра! Икебез дә тәмам каушадык.

— Бу җир безнеке булса, агач төбе нигә монда утыра? Без аны төнлә алып аттык бит! — дим.

— Дөрес. Төн эчендә төп үсеп чыга алмый бит инде! — дип, Мишка да гаҗәпләнде.

Ул арада Ваняның кычкырганын ишеттек:

— Карагыз әле нинди могҗиза! Кичә монда төп утыра иде, бүген юк. Кая киткән ул төп!

Бар да могҗиза карарга җыелдылар. Мишка белән без дә килдек.

Чыннан да, кичә монда аз гына казылган иде. Бүген казылып бетә язган дип, без дә гаҗәпләнәбез.

— Кара әле, Мишка, төнлә без кеше җирен казыганбыз бит. Мондагы төпне без казып алдык! — дим.

— Кит әле! Ишәк дисәң дә ишәк үзебез. Ни эшләргә соң? Хәзер алар, җирләрен безгә биреп, безнекен үзләренә алырга тиешләр. Без алар өчен бушлай эшләдекме әллә? — ди Мишка.

— Дәшмә! Бездән бөтен лагерь баласы көләчәк,— дим.

— Нишлик соң?

— Казыйбыз. Менә ни эшлибез.

Көрәкләргә ябышкан идек — бармый гына эшебез. Куллар авырта, аяклар авырта, арка бөгелми.

Бераздан Ваня белән Сенька җирләрен казып бетерделәр. Аларга кызыл байрак бирделәр.

Байракны җирләренең уртасына кадап куйдылар. Балалар, аларны котлап, кул чаптылар.

Кыен булса да, эшне дәвам иттек. Ваня белән Сенька безнең янга килделәр. Карап-карап тордылар да:

— Күрдеңме, ничек эшлиләр?! Әллә буксирга алыйкмы? Иң аз казучылар болар бит! — дип көлделәр.

Безне, чыннан да, буксирга алдылар. Агач төбен казып алырга да ярдәм иттеләр. Хәтта шуннан соң да ярышта без иң соңгы урынны алдык.

— Әйдәгез, иң арттагы бригада җиренә карачкы куйыйк,— диделәр балалар. Башкалар бу тәкъдимне шатланып кабул иттеләр һәм безнең җиргә карачкы утырттылар. Безнең үпкәләгәнне күргәч:

— Чәчүдә, чүп утауда алдынгы урын алырга ярдәм итәр,— дип юаттылар.

Без Мишка белән, карачкыдан котылыр өчен, бар көчкә тырыштык. Ләкин максатка ирешә алмадык. Карачкы безнең җирдә җәй буе басып торды. Чәчүдә дә иң артта калдык, чөнки Мишка чөгендерне кишер орлыгы чәчкән түтәлгә утырткан. Чүп үләне утауда да артта идек, чөнки Мишка чүп үләне урынына петрушканы йолкып чыккан. Ул җиргә редиска орлыгы чәчәргә туры килде.

Мишкадан әллә ничә тапкыр аерылырга теләдем. Ләкин уйлап-уйлап карадым да, кыен чакта юньле бала дустын ташлыймы, дип тыелып калдым. Аның белән көзгә чаклы интектем.

Алай да көз көне кызыл байракны безгә бирделәр. Без үстергән помидор белән кабак барысыннан да уңышлырак булып чыкты.

— Дөрес түгел бу,— дип бәхәсләштеләр балалар.— Артта калып килделәр-килделәр дә мә сиңа — иң яхшы уңыш! Алай була алмый ул!

— Беренче урынны алар бик хаклы яуладылар,— дип, безне яклады вожатый.— Артта калсалар да, алар җирләрен яхшы эшкәрттеләр. Зур уңыш алу өчен тырыштылар.

— Аларның җирләре безнекеннән яхшырак. Без дә бик тырыштык. Ә уңыш барыбер бәләкәй булды. Ул карачкыны нигә безгә бирәсез? Үзләрендә калсын. Җәй буе торды бит, тагын алар җирендә торсын,— дип зарланды Ваня.

— Бик әйбәт. Карачкыны кабат үзебезгә бирегез,— диде Мишка. Аның сүзләреннән бар да көлделәр.

— Ул карачкы булмаса, без мондый уңыш ала алмаган булыр идек,— дип дәвам итте Мишка.

— Нишләп? — дип гаҗәпләнделәр балалар.

— Безнең бакчага, карачкыдан куркып, каргалар төшмәде. Башкалар җиренә төштеләр. Шуңа күрә аларда уңыш аз булды.

— Нигә алдың ул карачкыны? Нигә кирәк ул безгә? — дидем мин Мишкага.

— Әйдә соң, илтик тә елгага атыйк,— диде Мишка.

Тоттык та елгага аттык. Ул түбән таба кулларын як-якка җәеп акты. Без аңа бераз карап тордык та таш яудыра башладык.

Безне шул ук көнне, байрак янына бастырып, фотога төшерделәр. Берәрегезгә безнең фото кирәк булса, рәхим итегез, хатка салып җибәрербез.

Николай Носов.

?! **1.** Вакыйгаларда төп катнашучыларның нинди дә булса сыйфаты ачылырга тиеш. Шундый вакыйгаларны табыгыз. Мәсәлән, җир бүлү вакыйгасында Мишка бер сәбәпсез үзләренә тигән өлештән гаепләр таба башлый. Кызыл байрак ясау вакыйгасында да ул, беренче урынны алабыз, дип шапырына... (Дәвам итегез.)

2. Мишканың кире сыйфатларын санап чыгыгыз.

3. Уңай сыйфаты булса, анысын да әйтегез.

4. Башыннан үткәнне сөйләүче (лирик герой) нинди малай?

ИКЕ АГАЧ.

Борын-борын заманда бер карт яшәгән. Аның улы белән кызы булган. Карт, сатар өчен, улы белән көне-төне бамбуктан кәрзин үргән. Ә кызы аларга аш пешергән, бушаганда, әтисе белән абыйсына булышкан.

Ул заманда әле, кием кияр өчен, мамык, төннәрен яктылык бирү өчен, май булмаган. Кешеләр кием урынына киек тиресе ябына торган булганнар.

Куышларын агач кайрысы яндырып яктыртканнар. Кичләрен өшегәннәр, ә төннәрен караңгыда күзләре авырткан.

Беркөнне малай әтисеннән:

— Их, төнлә ай да кояш кебек яктыртса ничек яхшы булыр иде. Айны кояштай якты итеп буламы? — дип сораган.

Әтиләре бераз уйлап торган да:

— Моннан бик еракта биек тау бар, дип сөйлиләр. Аны «Күк баскычы» дип йөртәләр икән. Шул тауда ап-ак чәчле, күк кашлы, җиргә тиярлек озын сакаллы бер карт яши икән. Ай шул тау өстенә килеп җиткәч, теге карт айга менеп китә икән. Ай белән сөйләшеп, серләшеп төшә икән. Бер менгәндә, айдан кояш кебек яктырт әле, кешеләр төнлә туңмаслар иде, аларның күзләре дә сукыраймас иде дип сораса, ай, мөгаен, тыңламый калмас иде,— дигән.

— Без ул картны эзләп табачакбыз. Айга безнең теләкне әйт, дип үтенәчәкбез,— дигәннәр балалар.

— Ул тауга менү бик кыен. Андагы карның калынлыгы гына да берничә дистә колач булыр,— дигән аталары.

— Кешеләр туңмасын, күзләре сукыраймасын өчен, без барлык авырлыкларны да үтәргә әзер,— дигәннәр балалар.

Таң ату белән, картның улы юлга чыккан. Тирән елгалар кичкән, биек таулар аша үткән. Аякларын яралап бетергән. Ләкин үрмәләп менсә дә

туктамаган. Шулай тугыз ай барганнан соң, ниһаять, «Күк баскычы»на менеп җиткән. Тау түбәсендә ак чәчле карт озын сакалын тарап утыра икән. Малай аның каршына килеп баскан да:

— Бабай, айга әйт әле: төннәрен кояш кебек яктырта алмас микән,— дип үтенгән.

Карт җавап бирмәгән. Сакалын таравын дәвам иткән.

— Коткара күр, бабай, безне. Кешеләр төннәрен эшлиләр, шуңа туңалар, сукыраялар,— дип ялынган.

Карт, башын күтәреп, малайга караган. Малай тәне туңудан зәңгәрләнә башлаган. Аягында көч-хәл белән генә басып тора. Карт аны кызганган:

— Бераз көт,— дигән.

Ай тау очына килеп җитүгә, карт тиз генә боз баскычтан үрмәләп менгән дә айга сикергән. Бераздан төшкән. Чал сакалын селки-селки, башын чайкап:

— Ай әйтә: «Кызганычка каршы, мин кояш кебек яктырта алмыйм шул. Һәр төнне калкырга да вакытым юк. Миңа ара-тирә диңгездә коенырга кирәк. Әгәр, коенып, битемдәге тапларны юмасам, кешеләргә тагын да караңгырак булачак»,— ди. Шуңа күрә ай һәр төнне яктырта алмый,— дигән.

Малай өметен өзеп елый башлаган. Аның кайнар күз яшьләре, тауга тамып, карны ереткәннәр. Картның да күңеле тулган.

— Менә болай, балакай, ай сезгә ярдәм итә алмый. Җирдә үзегезгә ни дә булса уйлап табарга кирәк,— дигән.

— Бабакай, без ни эшли алабыз соң? — дип сораган малай.

— Менә мондый юл бар,— диган аксакал.— Кеше агачка әйләнергә тиеш. Агач аңа май бүләк итәчәк. Ә май кешеләргә яктылык бирәчәк. Тагын бер агач булдыра алсагыз, анда мамык үсәчәк. Ә мамык кешеләргә кием бирәчәк. Шуннан соң кешеләр төннәрен туңмаслар да, сукыраймаслар да.

— Кешеләргә файда китерә торган булса, мин үзем агачка әйләнер идем,— дигән малай.

Аксакал малайның ихлас күңелдән әйтүен күргән. Тарагы белән сакалын тарап алган. Сакалыннан тавык йомыркасы хәтле энҗе тәгәрәп төшкән.

— Йот шуны, агачка әйләнерсең,— дигән аксакал.

Малай икеләнеп тормаган. Энҗене йотып җибәргән һәм мул яфраклы, күп ботаклы агачка әйләнгән. Күз ачып йомганчы, агач чәчәк аткан. Ул арада чәчәкләр коелып, агач күп санлы майлы җимешләргә капланган.

— Хәзер сине «майлы тунг агачы» дип йөртәчәкләр,— дигән аксакал.

Йомшак җил исеп алган. Агач шатлыгыннан кычкырып көлеп җибәргән.

Әтисе белән сеңлесе малайны озак көткәннәр. Малай әйләнеп кайтмагач, күңелләре хәсрәт белән тулган.

— Тауга мин дә менәм. Чал сакаллы картка үтенечебезне әйтәм,— дигән картның кызы.

Таң атуга, кыз да юлга чыккан. Ул да, абыйсы эзеннән интегеп бара-бара, аксакал карт янына менеп җиткән. Тау карты сакалын тарап утыра икән. Кыз аның каршына килеп баскан да:

— Бабай, айга, менеп, безнең үтенечне җиткерсәнә. Ул да кояш кебек якты янсын иде. Төн саен калыксын иде. Без барыбыз да туңабыз, караңгыда эшләп сукыраябыз,— дип ялварган.

Аксакал кызның салкыннан зәңгәр төскә керүен, яралы аягында көч-хәл белән генә басып торуын күргән. Аны бик кызганган.

— Сиңа кадәр менгән малай үтенечен айга җиткергән идем. Ай болай дип җавап бирде: «Мин кояш кебек яктырта алмыйм. Төн саен күккә дә менә алмыйм. Диңгездә коенып, битемдәге тапларны юасым бар»,— диде.

— Безгә нишләргә соң хәзер? — дип сораган кыз.

— Бер генә юл бар. Монда менгән малай, төнлә яктырту өчен, май бирә торган агачка әйләнде. Мамык бирә торган агач та булса, кешеләр мамыктан кием тегеп киярләр иде,— дигән аксакал.

Кыз май агачын кочаклаган да:

— Исәнме, абыем?! Син кешеләргә яктылык бирә торган агачка әйләнгәнсең икән,— дигән. Аннан соң, аксакалга карап:— Минем дә кешеләргә игелек эшлисем килә. Ярдәм ит, бабай,— дип ялынган.

Аксакал кызның ихлас күңелдән ялваруын күреп алган. Сакалыннан энҗе шары тәгәрәтеп төшергән дә кунагына биргән.

— Йотып җибәрсәң, шәфкатьле кыз, синең дә теләгең тормышка ашар,— дигән.

Кыз да, абыйсы кебек, энҗене йотып җибәрүгә булган, шунда ук ул басып торган урында агач үсеп чыккан. Агач күз ачып йомганчы чәчәк аткан һәм мамык белән капланган.

— Моннан соң, кызым, сине «мамык» дип йөртәчәкләр,— дигән аксакал.

Йомшак җил исеп куйган. Агач шатлыктан кычкырып көлеп җибәргән.

Әтиләре балаларын көткән дә көткән. Ләкин балалары кайтмаганнар.

— Аксакалга, менеп, үтенечне әйтим әле. Кояш кебек яктыртсын, төнлә калкысын дип, айга әйтсен әле,— дигән. Таң атуга, ул да балалары эзеннән карлы тауны эзләп киткән. Тауга менеп җиткән. Тау картының сакал тарап утыруын күргән. Каршына басып, үтенечен әйткән:— Ай төн саен калыксын, кояш кебек якты булсын,— дигән.

— Ай үтенечеңне үти алмый. Монда, шул ук йомышны үтәргә дип, бер малай белән бер кыз бала менгәннәр иде инде. Алар әнә агачка әйләнделәр. Алар кешеләргә май һәм мамык бүләк итәчәкләр,— дип аңлаткан акыл иясе аксакал.

— Минем дә агач буласым килә,— дип ялынган җир карты.

— Булдыра алмыйм. Энҗе шарларым икәү генә иде. Ләкин, монда менеп, син бик яхшы иткәнсең. Агачлардан орлыкларын җыеп ал да чәч. Синнән

алып, башкалар да чәчсеннәр. Шуннан соң кешеләр туңмаслар. Күзләре дә сукыраймас,— дигән аксакал һәм җир картына кәрзин биргән.

Шулвакыт җил исеп куйган. Агачлар, шатланып, яфракларын шаулатканнар. Кәрзингә ике агачтан да орлыклар коелган. Орлык тулы кәрзин белән, карт аска төшеп киткән. Юл буе орлык чәчкән. Күп тә үтмәгән, тау итәкләрендә май һәм мамык агачлары үсеп чыккан.

Шуннан соң кешеләр, җылы кием киеп, төннәрен яктыда эшләгәннәр. Туңмаганнар. Күзләре дә авыртмаган...

?! **1.** Төп катнашучыларны әйтегез. Аларның уртак сыйфатларын табыгыз.

2. Кабатланган вакыйгаларга уртак исем бирегез.

3. Әкиятне тәмамларга кирәк. Төп геройлар кайда очрашырга мөмкин?

ҖИРӘНЧӘ ЧӘЧӘННЕҢ КИЛЕН ЭЗЛӘВЕ

Борын заманда Җирәнчә дигән бер карт чәчән яшәгән. Аның улы булган. Улы үсеп җиткәч, кәләш алып бирергә булганнар. Улы башлап сүз кузгаткан.

— Атай, вакыт җитте бит инде. Кәләш алып бир,— дигән.

— Яхшы,— дигән атасы Җирәнчә карт,— килен алып бирермен, тик куйган шартларга түз. Әгәр

түзә алсаң, менә дигән килен алып бирермен,— дигән.

Улы уйлап-нитеп тормаган, ризалашкан.

Икенче көнне Җирәнчә карт ат җиккән дә, улын утыртып, күрше авылга киткән. Танышларына кереп, чәй эчкәннәр. Шунда Җирәнчә карт ни эш белән йөрүен әйтеп биргән дә:

— Авылыгызда безгә килен булырлык кызлар бармы? — дип сораган.

— Һай, ничек булмасын, ди. Бик чибәр, уңган кызлар бар,— дип, хуҗа биш-алты кызның өен өйрәткән.

Җирәнчә карт, атын җигеп, улын арбага утырткан. Хуҗа өйрәткән кызлы йортларның берсенә барып туктаган. Туктагач, арбасыннан сикереп төшкән дә чыбыркысы белән улын суктыра башлаган. Шулай суга торгач, өйдән бер кыз йөгереп чыккан:

— Олатай, олатай, нишләп улыңны тукмыйсың? — дип сораган. Җирәнчә карт аңа:

— Әйткәнне тыңлый. Шуңа тукмыйм,— дип, улын яра бирә, ди.

— Бәй, әйткәнне тыңлаган кешене тукмыйлар димени? Тыңлаулы кеше акыллы була бит! — дигән, ди, кыз.

— Әйдә, улым, киттек. Монда эш чыкмады,— дип, Җирәнчә атын борган да танышы өйрәткән икенче өйгә барган. Капка төбенә барып туктагач, тотынган, ди, тагын малаен сыдырырга. Сыдырып

торганда, бу өйнең дә кызы аптырап килеп чыккан, ди. Баягыча сораган, ди. Җирәнчә баягы җавапны биргән, ди.

Кыз шунда:

— Аһ, олатай, тыңлаулы кешене нигә изалатасың инде? Бик әйбәт, сүз тыңлагач,— дигән, ди.

Җирәнчә карт арбасына менеп утырган да:

— Ярар, улым, киттек. Монда да безнең өлеш юк. Табарбыз әле,— дип, сөйләнә-сөйләнә, өченче капкага киткән, ди. Килеп туктагач та, улын тагын тукмый бу. И тукмый, и тукмый... Йортның кызы тәрәзәне ачкан да:

— Олатай, нишләп улыңны тукмыйсың? — дигән. Җирәнчә карт аңа да:

— Әйткәнне тыңлый бит! Шуңа тукмыйм,— дип җавап биргән.

Кыз кычкырып көлгән:

— Ныграк тукма, олатай! Егет булып беткән, нишләп кеше әйткәнне генә эшли ул, үзе белеп эшләми? — дигән дә тәрәзәне шарт итеп ябып куйган, ди. Җирәнчә карт улына елмаеп күз кыскан да:

— Әһә, күрдеңме, улым? Болай булгач, эш пеште. Менә шушы инде сиңа дип эзләгән килен,— дип, шул кызны улына кәләш итеп алып биргән, ди.

?! **1.** Әкиятне ике генә өлешкә калдыру өчен, охшаш вакыйгаларны кушып сөйләргә кирәк. Шулай итегез.

2. Картның улын яклаучы кызлар да дөрес сөйлиләр. Ни өчен карт өченче кызны сайлаган?

3. Картның әкияттәге бик матур сыйфатын әйтегез.

ИКМӘК ЯҢГЫРЫ.

Элек заманда бер ярлы гына киекче (аучы) булган, ди. Моның бала-чагасы бер дә булмаган. Ирле-хатынлы гына яшәгәннәр, ди, болар. Бу киекче балыкка да, ауга да йөри икән. Ә хатыны, ире нәрсә алып кайтса да, күршеләренә йөгерә икән: «Ирем балык тотып кайтты, таба кирәк», яисә «Ирем куян атып кайтты, пешерергә савыт кирәк»,— дип, өйдәге хәлләрне түкми-чәчми сөйләп чыга икән. Ире, моңа бик эче пошып: «Ничек итеп моны акылга утыртырга?» — дип уйлап йөри икән, ди.

Берзаманны урамда йөри торгач, күмеп куйган акчага-малга тап булган бу. Малны чыбык-чабык белән күмгән дә ничек алып кайтырга дип исәпли башлаган. Исәпли торгач, хатынын алдарга хәйлә тапкан. Башта куян атып алган. Куянын тотып, күл янына киткән. Күлдән ятьмәсен чыгарып, балыкларын алган да куянны, ятьмәсенә тыгып, суга батырган. Балыкларны юл буендагы агач ботакларына элеп калдырган. Өйгә кайткач, хатынына әйткән:

— Син икмәк пешер, мин иртүк киеккә чыгармын,— дигән.

Иртән торып ашап-эчкәч, хатыны күрмәгәндә генә, куенына икмәк тутырган да киеккә дип киткән бу урманга. Урманга баргач, куенына яшергән икмәкнең кайсын юл буена, кайсын агач ботакларына куйган да борылып кайткан.

— Нигә бик тиз кайттың? — дип сораган хатыны.

— Сине алырга кайттым, тубал ал да, урманга утынга барабыз. Әле киеккә тозак корып кайттым,— дигән.

— Тубал нәрсәгә соң? — дигән хатыны.

— Урманда гөмбә дә җыярбыз,— дигән ире. Шуннан болар арбага утыралар да китәләр урманга. Бара торгач, хатын юлда да, агач ботагында да икмәкләр күрә һәм әйтә:

— Кара, кара, бу икмәкләр каян килгән икән? — ди.

— Әй, син белмәдеңмени: төнлә икмәк болыты килгән иде, яңгыр белән икмәк яугандыр,— ди ире.

Ярар, тагын киттеләр, ди, болар. Бара торгач, балык тезгән каенга җитәләр. Каенга җитүгә, әлеге киекче, атын туктатып, мылтыгын ала.

— Нишләп туктаттың? — дип сорый хатыны.

— Әнә теге каенда балыклар тезелгәннәр ич, шуларны атып алам,— ди ире.

Шуннан мылтыгын төзәгән дә, шалт иттереп, балыкларны атып төшергән. Аннары барысын, җыеп, сумкасына салган.

Тагын китәләр, ди, болар. Күл янына җиткәч, ятьмәсен судан чыгарып караса, бер куян ята. Куянны да алып салалар. Хатыны сөенә инде: балык та булды, куян да булды бит. Хәзер ире әйтә:

— Әйдә, утын төйибез инде,— ди. Ире бара да теге чыбык-чабык белән каплап куйган акчаларны капчыкка тутыра. Капчыкны арбага салып, өстенә утын төйиләр дә кайтып китәләр. Авылга кергәч, бер бай йорты яныннан узып баралар икән, йорттан бер кәҗә бик каты кычкыра, ди. Хатыны иреннән:

— Кәҗә нәрсә дип кычкыра икән? — дип сорый.

— Нишләп кәҗә булсын, бай абзыйны шайтан камчы белән кыйный, шуңа чыдый алмыйча акыра,— дигән ире.

Өйгә кайтып кергәч, хатын күршеләренә таба алырга йөгерә.

— Ни куырасың табада? — дип сорый күршеләре.

— Менә ирем агач ботагыннан балык тотып алды, ятьмәгә куян кергән, шуларны кыздырырга кирәк,— дигән хатын.— Әле без күп мал да таптык,— дип, соңгы серне дә ачып салган.

Шулай итеп, бу хатын бөтенесен сөйләп биргән. Сүз йөри бит инде. Авыл буенча йөри торгач, хатын сөйләгән сүзләр әлеге байга да барып җиткән. Бай моны чакырткан да:

— Син, киеккә йөргәндә, мал тапкансың икән, нишләп миңа әйтмәдең аны? — дигән.

— Ни сөйлисең? Бернинди мал да тапмадым,— дигән киекче.

— Хатының күршеләреңә әйткән, ә күршеләрең миңа әйттеләр,— дигән бай.

— Алай булса, хатынның үзеннән сорагыз,— дигән киекче. Шуннан соң хатынны чакырта бай.

— Акча, мал таптык дип сөйләгәнсең икән, таптыгызмы? — дип сорый.

— Таптык,— ди хатын.

— Кайчан таптык, ник алдыйсың? — ди киекче.

— Ник, фәлән көнне утынга барганда таптык ич,— ди хатыны.

— Кайчан? — дип, ире тагын кайтарып сорый икән.

— Оныттыңмыни: ятьмәгә куян эләккән көнне, каен ботагыннан балыклар атып алган көнне таптык ич,— ди хатыны.

Шуннан киекче әйтә байга:

— Ятьмәгә куян кергәнне кайда күргәнең бар? — ди.— Балыкның агач ботагында утырганын кем күргән? Акылдан язган хатынга ышанасыңмы?

— Акылдан язганмы? Без мал табып кайтып килгәндә, бай абзый, сине шайтан камчы белән яра иде бит, ә син акыра идең. Без менә шул көнне акча таптык та инде,— ди хатыны.

Шуннан хатынны чыгарып җибәрә дә әйтә:

— Чын егет икәнсең. Малны табуын да тапкансың, юллый да белгәнсең, хатыныңны да акылга утырткансың,— ди.

?! **1.** Киекче хатынының ике сыйфатын әйтегез.
2. Киекче һәм бай сыйфатларын әйтегез.

БАТЫР КӨЧЕКЛӘР.

Ике көчек яшәгән. Менә алар ишегалдына чыкканнар. Башларын күтәреп карасалар — күктә якты урак! Ни булыр бу, диләр көчекләр. Бераздан якты урак түгәрәкләнә башлаган. Көчекләр куркып калганнар.

— Әйдә, өрик,— дигән берсе.

Өрергә тотынганнар дуслар. Ә ай түп-түгәрәк булып һаман югарырак күтәрелгән...

Михаил Петровтан.

Хикәяне дәвам итегез. Беренче көчек, айның якты шарга әйләнүен күргәч, ни дигән? Икенче көчек ни дигән? (Җавап эзләгәндә, хикәянең исеменә игътибар итегез.)

Персонаж сүзе.
Автор сүзе.

Автор бала турында язса, әсәрдәге бала бала кебек уйный, бала кебек сөйләшә, юкка гына үкереп елый башлый. Автор аны юатса да, барыбер үзенекен итә: елый да елый. Автор кайчак әсәренә ялганчы персонажны да кертә. Һәм ул булып сөйли, алдый башлый. (Дәвам итегез. Төлке турында язса, төлке нишли? Куян персонаж булса, ул нишли?)

Автор үзе уйлап чыгарган персонажларына карап елмая, ә безгә: монысыннан үрнәк алыгыз, ә монысын гыйбрәт өчен язам, ди. Ачуы килгәндә, юньсез персонажларына җәза бирә. Автор сүзе персонаж сүзеннән менә шулай аерыла.

ЧЫДАСЫН ТИК УЛ ГЫНА.

Кояш байый, кич җитә.
Безнең гаилә ял итә.
Әти чумган гәзиткә,
Әни юа тәлинкә...
Кырын ятып, Айрат та
Гитарасын «сайрата».
Кыллары чыңлап тора,
Гитара зыңлап тора!
Чыдасын тик кыл гына.
Чыдасын тик кул гына...
...Көн-төн дими, кич-иртә...
Көне эш белән үтә —
Минем әни бик эшчән!
Кулы бушамый эштән.
Әле кибеткә китә,
Әбиләргә сөт илтә...
Сыер сава,
Көтү куа,
Идән юа,
Кер уа,
Суын китереп куя...

Мин әнине уйлап ятам.
Уйлап-уйлап шаккатам:
Әнигә эш мул гына...
Чыдасын тик ул гына!

Афзал Нигъмәтуллин.

?! Бала әнисен кызгана. Башкаларны ни өчен тәнкыйтьли?

ӘНИЛӘРЕ ӨЙДӘ ЮКТА.

Мәрьям — күптән инде апа кеше. Хәзер ул биш яшьтә.

Ә Рөстәм — аның энесе. Әтисе сугышка киткән вакытта, ул бөтенләй булмаган... Менә хәзер Рөстәм үсте инде. Аның белмәгәне юк. Утыргычка менә. Утыргычтан өстәлгә менә. Карап тормасаң, егылып та төшә. Һии-и... аның белгәннәрен санап бетерерлек түгел... Ул гөл чүлмәгендәге туфракны идәнгә сибә. Өстәлдәге кашыкны ала да ишек төбенә илтеп ташлый. Ишек төбендә яткан галошны ала да өстәлгә китереп куя.

Мәрьям белән Рөстәм әниләре алдында да шаяралар. Әниләре тагын да катырак ачулана: «әтиегезгә язармын» дип куркыта.

— Сүз тыңламаганыгызны белсә, яныгызга кайтасы да килмәс. Бүләк тә алып кайтмас үзегезгә,— ди. Әниләре шулай дигәч, Мәрьям белән Рөстәм акыллы гына уйный башлыйлар да, әзрәк

уйнагач, тагын онытып җибәрәләр, әниләре тагын да катырак ачулана.

— Әтиегез генә кайтсын, әйтмәсәмме мин сезне!

Ә Мәрьям белән Рөстәм әтиләрен бик сагынып көтәләр. Аны тизрәк үз күзләре белән күрәселәре килә.

Беркөнне Мәрьям белән Рөстәм өйдә икәү генә калдылар. Рөстәм тик кенә тормады. Ботинкасын ишек төбеннән алып, кровать өстенә китереп куйды. Идәнгә тоз түкте. Аннан соң, утыргыч куеп, өстәлгә менде дә, одеколон шешәсен алып, көзгегә суга башлады. Шак, шак суга... Одеколон шешәсен идәнгә төшереп тә җибәрде. Шешә ватылды. Менә Рөстәм елый башлады.

?! **1.** Хикәянең укыган өлешен бик кыска итеп сөйләгез. Аңа исем бирегез.

2. Катнашучыларны санап чыгыгыз.

3. Төп катнашучыларны әйтегез.

4. Рөстәмне автор: «Аның белмәгәне юк»,— дип мактый. Шул урынны кабат укып чыгыгыз. Рөстәм ниләр белә? Автор безгә шул сүзләре белән нәрсә әйтергә тели? Рөстәм кебек күп белегез, диме? Рөстәм кебек күп белмәгез, диме? Әллә башкача әйтәме?

Хикәяне дәвам итик.

Мәрьям нишләргә дә белми. Аның үзенең дә елыйсы килә. Апа кеше булгач ачулана башлады.

— Елама, тискәре малай. Менә хәзер әни кайтып керсә нишләрбез? Менә тагы, әти кайткач, этигә әйтер әле: «Әнә Рөстәм одеколонны ватты»,— дияр.

Шулай дигәч, Рөстәм елаудан туктады.

Алар шулай сөйләшеп торганда, өйгә бер зур кеше килде дә керде. Өстенә гимнастёрка кигән, башында фуражка, кулына чемодан тоткан.

— Синең исемең ничек? — ди.

— Мәрьям. Ул — Рөстәм.

Теге кеше әйтте:

— Мине таныйсызмы?

— Юк.

— Ә мин сезнең әтиегез. Менә сугыштан кайттым инде.

Мәрьям ул кешегә ышанырга да, ышанмаска да белми. Ә Рөстәм, «әттә, әттә» дип, әтисенең алдына менеп тә утырды.

— Фуу, фу,— диде әтисе,— сез әллә мин кайтуга бизәнеп тордыгызмы? Одеколонга манчылгансыз...

Рөстәм әйтә:

— Әттә, син мине, адукалун ватты әйтеп, әннәгә әйтмә.

— Нигә, улым? Бернәрсәне дә әннәгә әйтмәскә ярамый бит.

— Ул әттәгә әйтәм әйтте...

Ул арада әниләре дә кайтып керде. Әй шатландылар бар да, әй шатландылар! Әниләре Мәрьям



белән Рөстәмгә ачуланырга да онытты. Әтиләренә дә әйтмәде. Болай булгач, әтиләре хәзер аларга чемодандагы бүләкләрен, күчтәнәчләрен чыгарып бирә инде. Мәрьям белән Рөстәм үзләре дә моннан соң болай шаярмаслар. Әниләре әйткәнне дә, әбиләре әйткәнне дә тыңлап кына торырлар.

Мирсәй Әмир.

?! **1.** Хикәянең икенче өлешен дә кыскарта-кыскарта сөйләгез.

2. Хикәянең ике өлешен, бергә кушып, тулысынча сөйләгез.

3. Хикәянең иң матур урыны — Рөстәмнең «Әттә, син мине, адукалун ватты әйтеп, әннәгә әйтмә... Ул әттәгә әйтәм әйтте» сүзләрендә. Рөстәм ни өчен шулай ди?

4. Хикәянең беренче өлешенә, «Әниләре өйдә юкта» дип, исем бирик. Икенче өлешенә исемне үзегез уйлап табыгыз.

5. Рөстәм нинди малай? Яхшымы, начармы?

ПЕСИ ҺӘМ ЧЫПЧЫК.

— И син, Чыпчык, нәнием,
Кайда соң синең өең?

— Хөрмәтле Песи агай,
Минем йортым юк бугай...

— Әйдә минем йортыма —
Рәхим ит курортыма!

— Хөрмәтле Мәче агай,
Миңа килешмәс алай:
Сез бит мине ашарсыз!

— Ах, сез, Чыпчык,
начарсыз!

Афзал Нигъмәтуллин.

?! **1.** Песи чыпчыкны чыннан да ярата мы?

2. Чыпчыкка песи «начарсыз!» ди. Хөрмәт белән эндәшә, тәрбияле. Һәм ул үзенең хаклы булуына шикләнми. Ул нигә хаклы?

3. Песинең чыпчыкны «начарсыз!» дип гаепләве белән автор килешәме?

МАКТАНЧЫКЛАР.

Шомбай әйткән: «Минем әти —
Иң көчлесе дөньяда!
Йөз кило күтәрә ала,
Тиң булырлык юк аңа!»
Шукбай әйткән: «Минем әти...
Мең килоны эһ! тә итми
Күтәреп тора озак».
Шомбай әйткән: «Минем әти,
Тукта, сөйләмичә тор...
Иң озын кеше дөньяда:
Буе нәкъ ике метр!»
Шукбай әйткән: «Минем әти...
Акылың-исең китәр,
Илле метрлы, карасаң —
Бүрегең төшеп китәр».
Шомбай әйткән: «Ис тә китми,
Бер дә бүрегем төшми.
Мин мактанмыйм, минем әти
Тренер булып эшли!»

Шукбай әйткән: «Әтиемнең
Эш урыны — урамда.
Мин дә мактанмыйм, әтием —
Төзелештә — кранда...»

Илдар Юзеев.

?! **1.** «Мин мактанмыйм»,— ди Шомбай. Автор аның белән килешәме?

2. Шукбай да Шомбай кебек мактанамы? Автор да аныңча уйлыймы?

Әдәби әсәрләрдә геройларның бәясе белән автор бәясе аерыла.

Герой хисе.
Әйтемнәр һәм мәкальләрдәге хис.

Хис ул — ярату, хәсрәтләнү, шатлану, үпкәләү, үкенү һ. б.

- Йөрәксездән ерак кач.
- Күңелең киң булса, тар җиргә дә сыясың.
- Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге.
- Күңеле тарның, өе тар.
- Оялмаган кеше өчен оятлының йөзе кызарыр.

Шагыйрьләр «яратам», «хәсрәтләнәм», «шатланам», «үпкәлим» дип язмаска тырышалар. Ничек итеп ратуларын, хәсрәтләнүләрен, үпкәләүләрен

күрсәтеп бирәләр? Шунысы бик әһәмиятле: башкалар язганны берәү дә кабатламый. Мәсәлән, безнең борынгы бабайлар, «мин шатланам» дип әйтмәс өчен, күп санлы әйтемнәр уйлап тапканнар:

- Авыз колакка җитте.
- Аяклар җиргә тими.
- Баш түбәгә тиярдәй булды.

Гаҗәпләнү хисен күрсәтү өчен дә, әллә никадәр әйтем иҗат иткәннәр:

- Ике күзем дүрт булды.
- Колаклар үрә торды.
- Аяз көнне яшен суккандай булды.

Иң күп әйтемнәрен хәсрәткә багышлаганнар:

- Йөрәккә таш булып утырды.
- Ут йотып йөрде.
- Киң урамнар тарайды.
- Күңелгә таракан керде.

Җырлаганда, ярату хисен болай сурәтләгәннәр:

Тәрәзәләргә үрелдең,
Гөлләреңә күмелдең;
Гөл чәчәге арасыннан
Сандугач күк күрендең.

Гөлләреңне еш утыртма,
Яфрагы сирәк булыр;
Кайгың булса да елама,
Күзләрең кирәк булыр.

КОШТАЙ.

Күптән, бик күптән бер бабай белән бер әби яшәгән. Икесе дә миһербанлы, яхшы күңелле кешеләр булганнар.

Кышның салкын бер кичендә бабай урманга утынга киткән.

Утынын турап бәйләгән. Җилкәсенә салган. Таудан төшә генә башлаган икән, кызганыч тавыш ишеткән. Тавыш килгән якка киткән. Бераз баргач, капканга кысылган торна күргән. Торна канатларын җилпи-җилпи, ыңгыраша-ыңгыраша ярдәм сорый икән.

— И-һи-һи, мескенкәй, харап була язгансың бит. Хәзер коткарам, бераз гына түз,— дигән бабай һәм торна аякларын капканнан ычкындырган. Тозактан котылгач, канатларын кагынган да торна очып киткән. Үзе оча, үзе, шатлана-шатлана, нидер каңгылдый, ди.

?! Өзекне үз сүзләрегез белән сөйләгез. Аннан соң кыскартып сөйләгез. Исем бирегез.

Бабай өенә кайткан. Әби белән бергәләп, чәй эчәргә утырганнар. Шулчак кемдер ишек каккан.

— Төн уртасында кем булырга мөмкин бу? — дип сукранган бабай. Ишеген ачып җибәрсә, каршында ап-ак карга күмелгән бик матур кыз басып торганын күргән.

— Адаштым. Бик куәтле буран. Юл күренми,— дигән кыз.

— Кер, кызым, кер,— дип чакырган әби.— Без кунакларны яратабыз.

— Урамда бик салкын, туңгансыңдыр. Кер, әйдә, мич каршына утыр. Җылынырсың,— дип өстәгән бабай.

Кунак кыз өйгә кергән, мич каршына утырган.

— Исемең ничек, кызым? — дип сораган әби.

— Минем исемем — Коштай, әби.

— Бигрәк матур исем икән — Коштай,— дип мактаган әби.

Ягымлы кыз хуҗаларга ошаган.

?! Бу өзеккә дә бер яисә ике генә сүзле исем уйлап табыгыз.

Икенче көнне, китәргә җыенгач, әби белән бабай:

— Безнең балабыз юк. Ялгыз яшибез. Монда бөтенләйгә калмассыңмы, кызым?.. — дип ялынганнар.

Кыз да ятим бала икән. Әби белән бабай янында калырга бик шатланып риза булган.

— Изгелегегез өчен үзегезгә матур келәм тукып бирермен. Тик бер генә шартым бар: келәм тукыганда, ул бүлмәгә керә күрмәгез,— дигән.

Кунак кыз, бүлмәсенә бикләнеп, келәм тукый башлаган. Өч көн тукыганнан соң, әби белән бабайга төрелгән тукыма чыгарып биргән.

— Минем мондый матурлыкны гомеремдә дә күргәнем юк! — дип шатланган әби.

Бабай кызга карап алган да борчылган.

— Бик йончыган кебек күренәсең, кызым,— дигән.

Ул арада келәмнәр сатып алучы кеше — Ким килеп кергән. Әби кулындагы йомшак гүзәл тукыманы күргәч, аның күзе дүрт булган.

— Ай-яй кызыгыз оста икән! — дигән. Әбигә берничә алтын тәңкә биргән. Әби белән бабайның алтын акчаны күргәннәре дә булмаган. Алтын тәңкәләр кояш кебек ялтырыйлар, тимердән дә авырлар икән. Әби белән бабай кунак кызга рәхмәт әйтеп туя алмаганнар.

— Бик зур рәхмәт сиңа, кызым Коштай. Мондый акчалар белән кешечә яши башлаячакбыз хәзер,— дигәннәр.

?! Әкиятнең алдагы өзекләрен дә кушып сөйләгез.

Яз җиткән. Карлар эрегән. Кояш җылыта башлаган. Коштай авыл балалары белән дуслашып өлгергән. Балаларга Коштай белән уйнау кызык, күңелле булган. Алар бергәләп уйнаганнар, көлгәннәр. Ләкин беркөнне келәмнәр сатып алучы Ким тагын килеп чыккан. Ул бу юлы да шундый ук келәм сораган.

— Сорама да, кызыбыз, келәм тукып, бик арый,— дигән бабай. Ләкин Ким аның учына алтын тәңкәләрне көчләп салган.

— Акча тагын да күбрәк бирермен. Ләкин хәзер сатмасаң, бүтән берне дә алмаячакмын,— дип куркыткан.

— Башка зур хәсрәт килде. Инде ни эшләрбез?! — дип хафаланган әби белән бабай. Ләкин аларны Коштай тыңлап торган икән.

— Борчылмагыз. Тагын берне тукып бирермен! Тик монысы соңгысы булыр. Үтенеп сорыйм, зинһар өчен, мин эшләгәндә, бүлмәгә керә күрмәгез,— дип, тагын бер тапкыр кисәткән.

Коштай бүлмә ишеген япкан да икенче келәмен тукырга керешкән. Туку машинасы көн эшләгән, төн эшләгән. Өч көн үткәч, Ким тагын кергән.

— Йә, миңа дигән келәм өлгердеме? Күрсәтегез! Кая ул?

Ким тавышына әби белән бабай сискәнеп киткәннәр.

— Күрсәтергә ярамый! Бүлмәсенә кермәскә кушты! — дигәннәр.

— Кушмаса кушмас! — Ким бүлмә ишеген көч белән ачып җибәргән. Бүлмәгә караган да хәйран калган: анда кыз урынында торна утырганын күргән. «Торна, тор-рна!» — дип кычкырып җибәргән Ким.

Чыннан да, туку машинасы янында торна утырган була. Торна, канатларын җәеп, борыны белән канат астындагы йомшак каурыйларын, мамыкларын йолкып, шул каурый-йоннардан келәм тукый икән.

Икенче көнне әби белән бабай әлеге бүлмәне ачып карасалар, бүлмә тып-тын. Анда беркем дә юк. Туку станогында күзнең явын алырлык келәм ята. Тирә-юньдә торна мамыклары чәчелгән...

Кичкә таба урамда балалар әби белән бабайга:

— Әби, бабай, чыгыгыз тизрәк, монда килегез! — дип кычкырганнар.

Әби белән бабай чыгып күккә карасалар — торна! Бабай коткарган торна! Каңгылдый, өй өстендә әйләнеп оча. Каурыйсыз канатларын җилпеп, көчхәл белән оча...

— Коштай, безнең Коштай! — дип елап җибәргән әби.

Әби белән бабай торнаның кунак кыз Коштайга әйләнүен хәзер генә аңлаганнар. Үзләрендә калдыра алмаулары өчен үкенеп бетә алмаганнар.

— Коштай, торна! Китмә, китмә!

Ләкин торна соңгы тапкыр кычкырган да кояш баткан якка очып югалган. Әби белән бабай, күзләре талганчы, торна артыннан карап калганнар.

?! **1.** Өченче өлешкә дә исем уйлап табыгыз.

2. Бабай белән әби ни өчен хәсрәтләнәләр?

3. Моннан соң келәм сата алмабыз дип хәсрәтләнәләрме? Кызларын югалткангамы? Әллә башка сәбәп бармы?

ШИФАЛЫ ДАРУ.

Беркөн шулай иртән, дәрескә керергә звонок булгач, укытучыбыз Зифа апаны көтәбез. Ә ул керми дә керми. Аның бер дә болай соңга калганы юк иде. Бераздан дежур укытучы абый керде дә:

— Сезгә хәзер уку булмый. Зифа апагыз авырый,— диде.

Төштән соң килергә булып, өйләребезгә кайтып киттек. Зифа апа икенче көнне дә килә алмады. Тагын таралыштык. Мин дә өйгә кайттым. Күңелсез. Эч пошырып, мич астында чикерткә чырылдый. Ичмасам, әни тизрәк кайтсын иде.

Бераздан әни дә кайтты.

— Кызым Гөлсинә, Зифа апагызга салкын тигән, ята икән,— ди. Зифа апаны кызганып куйдым: ятып ук авыргач, каты авырыйдыр инде. Янына барасым килеп китте.

— Мин дә шуны әйтмәкче идем әле, кызым,— ди әни.— Алайса, мин аңа бик шәп дарулар җибәрим әле,— ди.

Киендем. Әни Зифа апага дип әзерләнгән төргәкне миңа сузды:

— Банкадагысы — бал. Кәгазьгә төргәне — мәтрүшкә үләне. Шуны, кайнатып, бал белән эчсә савыгыр апагыз.

Киттем. Юлда уйланып кына барганда, «Гөлсинә!» дигән тавышка борылып карасам — ян урамнан Дилбәр килеп чыкты.

— Син кая киттең? — ди Дилбәр миңа.

— Зифа апага дарулар илтәм,— дим.

— Мин дә шунда бара идем әле, лимон белән әче как илтәм,— ди Дилбәр.

Инде икәүләп киттек. Барып кердек Зифа апаларга. Ул безне тавышыбыздан ук танып алды.

— Гөлсинә, Дилбәр, сезме? — ди.

Зифа апа безне үзе янына чакырып китерде. Икебезне дә, күкрәгенә кысып, аркабыздан сөйде.

Без аңа әниләребез җибәргән даруларны бирдек.

— Ай-яй шәп дарулар китергәнсез икән,— ди Зифа апа,— икегезгә дә бик рәхмәт инде. Бу даруларны эчкәч, бер дә авырмаслык булып сәламәтләнермен инде,— ди.

Салкын каты тигәндер, ахры, үзенә. Ютәлләп алды, маңгаена тир бөртекләре бәреп чыкты.

Мин:

— Апа, икенче салкын тидермәгез инде, шәлегезне авызыгызны капларлык итеп бәйләгез,— дим.

— Ярар, Гөлсинә, шулай итәрмен,— ди Зифа апа, үзе елмая. Чыннан да, шәлне шулай бәйләгәндә, салкын тими. Зифа апа үзе дә безнең шәлебезне, мәктәптән кайтырга чыкканда, шулай бәйләп куя.

Без килгәнгә, Зифа апа бик шатланды, кәефе дә яхшыра төште кебек.

Бераз сөйләшеп утыргач кайтырга чыктык. Камил очрады. Ул да безнең сыйныфта укый. Ул

кулына, ашъяулыкка төреп, чүлмәк тоткан. Чүлмәгеннән җылы бөркелеп тора.

— Нәрсә алып киләсең, Камил? — дибез тегеңә.

— Зифа апага тавык шулпасы,— ди.

...Өч көн узгач, Зифа апа, сәламәтләнеп, мәктәпкә килде. Безгә тагын күңелле көннәр башланды.

Сезнеңчә, кайсыбызның даруы шифалырак булды икән?

Шәукәт Ногманов.

?! **1.** Беренче эпизодка, «Зифа апаның авыруы» дип, икенчесенә, «Зифа апаны дәвалау» дип, исем бирәбез. Ә соңгысына исемне үзегез уйлап табыгыз.

2. Зифа апаны терелткән иң шифалы дару кайсы булды — балмы, мәтрүшкә үләнеме, лимон белән әче какмы, тавык шулпасымы? Кайсысы?

Соңгы сорауга җавап таба алсагыз, әсәрдәге авторны тапкан буласыз. Авторны тапсагыз, хикәянең эчтәлеген табасыз.

ҖИДЕ КАРГА.

Бер патшаның җиде улы була.

— Кызым туса, аңа бөтен патшалыгымны бирер идем. Ә улларым үз бәхетләрен үзләре дә эзләп табачаклар,— дия торган булган патша.

Уллары әтиләренең бу сүзен ишетәләр. Әтиләренең көтеп алган кызы тугач, «Безгә барыбер

монда көн булмаячак, яхшы чакта китеп котылыйк»,— диләр дә бәхет эзләргә чыгып китәләр.

?! Патша уллары борчылалармы, үпкәлиләрме, ачуланалармы, рәнҗиләрме, үч итәләрме? Ни өчен китәләр?

Өч көн, өч төн баралар. Кара урман уртасында бәләкәй генә бер өй күрәләр. Анда ялгыз бер әби тора икән. Җиде туган шул бәләкәй өйдә яши башлый.

Вакыт үтә. Патша кызы, үсә-үсә, ун яшькә җитә. Көннәрнең берендә шкафтан җиде күлмәк таба.

— Болар кемнәрнеке? — дип сорый.

— Синең җиде абыең бар иде. Ләкин, әтиең патшалыкны сиңа вәгъдә иткәч, алар бәхет эзләп чыгып киттеләр,— ди әнисе.

Кыз туганнарын кызгана. Бераздан, җиде күлмәкне алып, абыйларын эзләргә чыгып китә.

Адаша-адаша, өч көн, өч төн йөргәннән соң, әлеге өйгә килеп чыга. Өйдә әби ялгызы гына икән.

— Минем җиде абыемны күрмәдеңме, әби? — дип сорый кыз.

— Күрдем. Алар ауга киттеләр. Ә торуын монда торалар,— ди әби.

Агалары кайтып керү белән, үз күлмәкләрен танылар. Бу чибәр кыз безнең сеңлебез икән дип, бик шатланалар.

Ишегалларында җиде роза чәчәге үсә икән. Шуны сеңелләренә бүләк итәргә дип, егетләр

урамга чыга. Ләкин, чәчәкләрне кисү белән, җидесе җиде каргага әйләнә.

Сеңелләре хәсрәткә бата. Карчыктан: «Абыйларымны коткару чарасы бармы?» — дип сорый.

— Барын бар, ләкин бик тә кыен чара. Агаларыңны коткарыйм дисәң, сиңа җиде ел буена бер генә сүз дә әйтмәскә кирәк булачак,— ди.

Кыз, агаларын коткару өчен, җиде ел түгел, гомере буе дәшмәскә дә риза.

Менә ул биек агач ботагына менеп утыра да алты ел буена сөйләшми. Агалары аның тамагын туйдырып торалар.

Бермәлне патша ауга чыга. Урманда йөри торгач адаша. Шунда агач башындагы кызын күреп ала.

— Нигә имән башына мендең? — дип сорый патша. Кыз җавап бирми. Кызны әтисе сарайга алып кайта. Ләкин кызы анда да сөйләшми. Шул көннән башлап, бакчага җиде карга ияләшә. Алар тәрәзә төбендәге алмагачка куналар да нидер сөйләшәләр. Тагын очып куналар, тагын карга телендә сөйләшәләр...

Патша барлык акыл ияләрен чакырта. Каргаларның ни турында сөйләшүен белергә куша. Ләкин, бик белергә тырышсалар да, берсе дә булдыра алмый.

Каргалар телен белүчегә патша ярты патшалыгын бирергә вәгъдә итә.

Көтә торгач, ниһаять, тел белүче табыла. Сарайга бер кеше керә дә:

— Каргаларның ни сөйләшүен әйтәм, ләкин аның өчен миңа кызыңны бирерсең. Риза булмасаң әйтмим,— ди.

«Телсез кызга шушы егеттән башка кем өйләнсен»,— дип уйлый патша һәм егет шартына риза була.

Дәрвиш патшаны бакчага чыгара да болай ди:

— Җиде карга — патша уллары. Аларны аталары өеннән куып чыгарган булган. Патша кызы агаларын эзләргә чыгып киткән. Эзләп тапкан, ләкин патша

уллары шунда ук каргага әйләнгәннәр. Агаларын коткару өчен, кыз телсез калырга риза булган. Кыз җиде ел буена сөйләшми. Тиздән җиденче елы тула. Шуннан соң кыз да телгә килер, агалары да өйләренә кайтырлар. Ә хәзер каргалар аптырашта. Сеңел янында калыйкмы, кабат урманга әйләнеп кайтыйкмы, дип сөйләшәләр. Китсәләр, сеңелләре аларны мәңге эзләп таба алмаячак бит.

Каргаларның үз уллары булуын белгәч:

— Мин аларның кайтуын ел да көттем. Әгәр кайтсалар, миннән дә бәхетле кеше булмас иде! — дип кычкырып җибәргән патша.

Әйтеп бетерүе булган, кызының сөйләшми башлавына нәкъ җиде ел тулган. Каргалар шунда ук чибәр егетләр булып патша каршына килеп басканнар. Кыз кабат сөйләшә башлаган.

Шатлыктан патшаның башы күккә тигән. Елап ук җибәргән. Улларыннан, мине, зинһар, гафу итә күрегез, дип ялварган. Ә уллары сеңелләренә һәм каргалар телен белгән дәрвишкә рәхмәт әйткәннәр. Патша кызы дәрвишкә кияүгә чыккан. Ә дәрвиш патшалыкның яртысыннан баш тарткан. Патшаның уллары да өйләнгәннәр. Туйга урмандагы ялгыз карчыкны да чакырганнар. Карчык шунда яшәп калган. Әгәр дә үлмәгән булсалар, хәзер дә бәхетле тормыш итәләрдер әле.

?! Бу әкиятнең эче тулы хис. Төп геройларның хисе үзгәреп тора. Кызның хисе ничек үзгәрә?

МИНЕМ СӨЙГӘН КИТАБЫМ.

Мине укып күр, дисең.
Миндә күпме сер, дисең.
Күбрәк өйрән, бел, дисең,
Хикмәтләрен дөньяның,
Минем сөйгән китабым!

Тик тормаучы сабый да,
Сабыр, уйчан абый да
Сине укып карый да
Оныта йокыларын,
Минем сөйгән китабым.

Бик таушалган булсаң да,
Тетелсәң дә, тузсаң да —
Син кадерле, син якын,
Минем сөйгән китабым.

Син — юлдашым янымда,
Син — юлдашым ялымда.
Син — остазым, илһамым,
Минем сөйгән китабым.

Мәхмүт Хөсәен.

?! **1.** Катнашучыларны әйтегез.

2. Шигырьдә автор катнашкан урыннарны күрсәтегез.

3. Автор «Минем сөйгән китабым» дип кабатлый. Китабын ул ни өчен сөя? Китап матур булгангамы? Рәсемле булгангамы?

ПИ-БИ-БИ-БИП...

(Өзек.)

Их!
Авыл кырын тутырып, бодай үсә,
Дулкынлатып аны, җил исә,
Ташлап шагыйрьлегем җил иркенә,
Калыйм мәллә монда югыйсә?
Гайшә кызы килә, казлар куып,
Артта кала аксак бәбкәсе,
Бөглеп алган чакта бәбкәсен ул,
Шалтырап китә талир тәңкәсе...
Миңлениса чыккан, утын кисә.
Толымнарын селкеп, җил исә,
Ташлап шагыйрьлегем җил иркенә,
Калыйм мәллә монда югыйсә?

Һади Такташ.

?! Баштагы дүрт юлда авылның табигате матур иде. Ә шигырьнең ахырында автор нинди матурлык турында сөйли?

КАРТАЙДЫМ ШУЛ.

(Өзек.)

Авыл —
Һаман шулай катык ашый,
Һаман шулай —
Күлләрендә йөзә балыклар;
Дөнья җимреп, әле дә җырлап йөри
Әтәч хатыны биби тавыклар...

Әнә кәкре аяклы ябь-яшь бала
Тәпи йөреп чыга урамга,
Кулындагы нечкә чыбык белән
Казлар куган була урамда...
Бәбкәләрен саклап, ак ана каз
Аңа таба килә, җилкенә,
Күп тә үтми, аунап җир өстендә,
Кала усал казның иркенә...
Их!
Минем дә бар иде шуның кебек
Күмер ашап үскән чакларым,
Тик кайтсам да хәзер монда тагын —
Яшьлек эзләремне тапмадым...

Һади Такташ.

?! **1.** Бу әсәрне «Пи-би-би-бип...» шигыренең дәвамы дип уйлыйк. Һади Такташ, күп еллар үткәч, туган авылы Сыркыдыга тагын әйләнеп кайткан дип фараз итик. Бу юлы автор тормышының кайсы чорын сагына?

2. Кечкенә баланы каз талавы шатлану өчен сәбәп була алмый бит. Һади Такташ ни өчен шул күренешкә карап соклана?

Бу әкият Франция илендә язылган. Аның авторы — Элионор Фарджон. Элионор иҗат иткән әсәрләрне бөтен дөнья балалары яратып укый. Әкиятне мин дә оныгыма укыган идем. Шатланды. «Нинди бәхетле кыз!» — диде. Үсә төшкәч, әкиятне үзе укыды. Бу юлы озак дәшми торды. Борчыл-

ды. Күзеннән тып-тып күз яшьләре тамды. «Нинди бәхетсез кыз!» — диде.

Әсәрне сез дә игътибар белән укып чыгыгыз. Шатланырсызмы, борчылырсызмы? Менә ул әкият.

ТУТЫЙ КОШЧЫКЛАР.

Урам чатында мәктәп. Аның уң як почмагында чегән хатыны Дайна утыра. Дайна алдында читлек. Читлегенә ике тутый кош ябылган. Мәктәпнең сул ягында Сьюзан исемле кыз ботинка баулары сата. Ул үзенә тугыз яшь тулгандыр дип уйлый. Ләкин яшен төгаен генә әйтә алмый. Дайна яшенә килгәндә, ул аны күптән оныткан. Шулхәтле күп яшьне истә калдыралар димени!

Дәресләре тәмамлангач, кечкенә малайлар һәм кызлар мәктәп капкасыннан чабып чыгалар. Чыр-чу тавышын ишетү белән, Сьюзан көндезге ашын исенә төшерә һәм май яккан ипиен ашый башлый. Ашаганда, кызларның чәчләренә үргән матур тасмаларына кызыгып карый. Малайларның чыдамлы аяк киемнәренә күз төшерә. Күбесенең ботинка баулары әллә ничә җирдән өзелеп төйнәлгән була. Ботинка бавы өзелә инде ул. Ләкин шнурны аларга әниләре кибеттән алып кайта шул. Малайлар бауга дип бирелгән акчаларына конфет йә шар алалар.

Балалар тутый кошчыклар янына киләләр. Чегән хатынына бер пенс акчаларын сузып: «Рөхсәт итсәгез, миңа бәхет тартып чыгарсын әле»,— диләр.

Тутый кошлар шундый гүзәлләр! Яшел чирәм төсендәге шома яшел түшләре дисеңме, койрыкларындагы озын зәңгәр канатларымы — бар да күзеңнең явын алырлык матурлар! Ләкин аларның тагын бер матур сыйфатлары бар — тутый кошлар балаларга бәхетне бик арзан бәягә — ботинка бавы бәясенә генә бүләк итәләр. Башка берәр җирдән нибары бер пенска бәхет алып кара әле!

Бала читлек янына килгәч, чегән карчыгы Дайна: «Читлеккә бармагыңны тык, бәбкәм»,— ди. Бала кушканны үтәү белән, кошларның берсе аның бармагына сикереп менә. Шуннан соң хуҗасы кошына букча суза. Ә ул букчаның эче тулы бәхет! Бәхетләр яшел, алсу, сары, аксыл-шәмәхә кәгазьгә төрелгәннәр. Гүзәл кошчык ыргак томшыгы белән шул бәхетләрнең берсен сөйрәп чыгара.

Балалар өлешләренә тигән кәгазьне укып шатланалар.

— Бәхетең нинди, Марион?

— Мин корольгә кияүгә чыгам. Минем бәхетем аксыл-шәмәхә. Ә синеке нинди, Сирил?

— Минеке яшел. Мине сәяхәтләр көтә. Ә синеке нинди төстә, Хелен?

— Минеке сары,— ди Хелен.— Мин җиде бала үстерәм икән! Ә сине нинди бәхет көтә, Хью?

— Мин, ни эшләсәм дә, уңышка ирешәчәкмен. Миңа зәңгәр эләкте,— ди Хью. Аннан соң алар, куыша-узыша, өйләренә кайтып китәләр.

Сьюзан балалар сөйләшүен тын да алмый тыңлап тора. Шундый бәхетең булса иде! Бәхетле булыр өчен, бер генә пенс акча тапсаң иде! Ләкин Сьюзанга андый акча каян килсен?!

?! **1.** Сьюзан белән укучылар арасындагы аерманы әйтегез.

2. Укыган өлешне кыскартып сөйләгез.

Көннәрнең берендә чегән карчыгы йокымсырап китә. Нәкъ менә шул вакытта искиткеч шатлыклы вакыйга була. Читлек ишеге ачык калган икән. Ачык ишектән тутый кошларның берсе очып чыккан. Кошны уяу Сьюзан күреп ала. Тутый кошның юлдан йөгереп-атлап китүен дә, ябык песинең аңа таба сикерергә әзерләнүен дә күрә. Сьюзанның йөрәге сикереп-сикереп тибә башлый һәм, күз ачып йомганчы, кызны аякка бастыра. «Пр-ресс!»— дип кычкыра Сьюзан һәм, юл аша гына атлап, песидән алдарак сикерергә өлгерә.

Сьюзан тутый кошка бармагын суза. Кошчык, гадәтләнгәнчә, аның бармак очына очып куна.

Җәйнең шундый матур көнендә бармагыңа тутый кош кунудан да күңеллерәк тагын ни булырга мөмкин? Сьюзанның үз гомерендә иң шатлыклы вакыйга шул булды. Ләкин бәхет әле һаман дәвам итә икән. Читлеккә керү белән, кошчык томшыгын кәрзингә сузды һәм бәхет кәгазе тартып чыгарды. Кәгазен ул үзен коткаручыга сузды. Кыз мондый шатлык буласын башына да китермәгән иде. Менә ул тутый кошны читлегенә япты. Аннан соң бәхет төрелгән алсу кәгазен тотып, үз урынына барып утырды.

Шул көннән соң шактый вакыт үтте. Марион, Сирил һәм Хью мәктәпне тәмамладылар. Алар тутый кошчык биргән бәхетләрен күптән югалттылар инде. Хәтта оныттылар да. Марион даруханәдә эшләүчегә кияүгә чыкты. Сирил конторда кузгалмыйча утыра.

Хелен әле һаман кияүгә чыкмады. Ә Хью беркайда да эшләми.

Сьюзан исә үз бәхетен гомере буе саклады. Көндезләрен аны кесәсендә йөртте. Төннәрен мендәр астына яшерде. Алсу төстәге кәгазьдәниләр язылганын Сьюзан һаман белми, чөнки ул хәреф танымый. Кызның искиткеч ягымлы алсу бәхете иде ул кәгазь. Бәхетен ул сатып алмады бит. Ул бәхет Сьюзанга бүләк булып килде.

Элионор Фарджон.

?! **1.** Әкиятнең икенче яртысын үз сүзләрегез белән сөйләгез. Бу бүлектәге Сьюзан белән укучы балалар арасындагы аерманы әйтегез.

2. Әкиятнең эчтәлеген тулысынча сөйләгез.

3. Сьюзанның хикәя башындагы хисләре нык үзгәрә. Ничек үзгәрә?

ЕЛАДЫ.

Еламый Айнур беркайчан:
Бәрелсә дә, сугылса да,
Кыйналса да, йөгергәндә
Абынып егылса да.
Дәрестә шаян булуын,
Ахры, истә тоттылар:
Дусты Булаттан аерып,
Кыз белән утырттылар.
Бар сыйныф алдында Айнур
Елады, яшь тамызып.

Айнур елый, барсы көлә,
Табалардыр ни кызык?
Мин эчтән генә еладым,
Көләлмәдем кушылып,
Янда Камилә булмагач,
Нидер калды буш булып...

Илдар Юзеев.

?! **1.** Айнур нигә елый?

2. «Мин» дип сөйләүче малай нигә елый?

3. Хәзер шигырьне ике өлешкә бүлә аласыз. Әсәрне икегә бүлү өчен, нинди сорау бирергә кирәк? Шул сорауны бирегез дә бүлегез.

ҖӘЙНЕ ОЗАТКАНДА.

Җәй җыена ерак юлга,
Җәй җыена китәргә.
Җәйнең әйләнеп кайтканын
Тагын күпме көтәргә?!

Әллә җәйне озатканга,
Чык кына чәчәк, үлән.
Озатабыз җәйне менә
Үз чәчәкләре белән.

Роберт Миңнуллин.

?! **1.** Катнашучыларны әйтегез.

2. Шигырьдә төп катнашучылар икәү: берсе — китүче җәй. Икенчесен табыгыз.

3. Чәчәк белән үләнгә чык төшкән, ди автор. Ни өчен алай ди?

4. Җәйне ни өчен үз чәчәкләре белән озаталар?

5. Җәй кеше белән кушылган. Шуны исбат итегез.

ЧЫРШЫ.

Урманда матур гына бер Чыршы үсеп утырган. Үскән җире бик ямьле булган. Көне буе кояш нурлары өзелмәгән. Күрше-тирәдә олырак иптәшләре — чыршы һәм наратлар үскән. Аларга карап, Чыршыкайның да тизрәк зур үсәсе килгән.

— Ах, мин дә башка агачлар кебек зур булсам иде. Минем ботакларыма да кошлар оя ясар иде. Җил өрү белән, мин дә, башка чыршылар төсле, дәрәҗәмне саклап кына, башымны селкер идем,— ди икән Чыршыкай, көрсенеп.

Ике кыш үтеп өченчесенә кергәндә, Чыршыкай шактый үскән. Ләкин ул һаман тагын да зуррак булырга хыялланган.

— Их! Тизрәк үсәсе иде дә зур карт агач буласы иде,— дип зарланган.

Көз җитүгә, урманга утын кисүчеләр килеп, иң эре чыршыларны кискәннәр. Матур эре чыршылар, шатыр-шотыр килеп, җиргә ауган саен, безнең кечкенә Чыршы куркуыннан калтыранган. Киселгән чыршыларны ботакларыннан чистартканнар. Аннан

соң арбаларга салып, урманнан каядыр алып киткәннәр. Кая? Ни өчен алып киткәннәр?

Яз көне, карлыгачлар, ләкләкләр очып кайткач, Чыршыкай алардан:

— Теге агачларны кая алып киттеләр икән, белмисезме? — дип сораган.

Карлыгачлар берни дә белмиләр икән, ләкин Ләкләк бервакыт уйлап-уйлап торган да, башын селкеп:

— Әйе, күрдем бугай! Мисыр ягыннан очып килгәндә, диңгездә бик матур мачталы яңа ясалган корабль күрдем; аннан чыршы, нарат исләре килә иде. Ул башын шулкадәр югары күтәреп бара — исең китәр! — дигән.

— Их, тизрәк үсәргә дә диңгезгә чыгарга иде! Ә ул диңгез нинди соң? — дип сораган Чыршыкай. Ләкин Ләкләк җавап бирмәгән — очып киткән.

Кояш нурлары Чыршыкайга:

— Яшьлегеңә куан! Таза буең белән яшь көчең барлыкка шатлан! — дип, киңәшләр биргәннәр.

Яшь Чыршыны җил дә иркәләгән, чык та аңа тамчыларын бөркегән, ләкин яшь Чыршы боларның кадерен белмәгән.

Урманнан китәргә ашкынып торучы безнең Чыршыкайга караганда да яшьрәк һәм буе да кечерәк берничә чыршыны Яңа ел җитәр алдыннан гына кисеп алганнар. Киселгән чыршылар барысы да зифа буйлылар, аларны, ботакларын әрчеп, кискәләп тормастан, арбага төяп, урманнан алып киткәннәр.

— Кая алып киттеләр инде? — дип аптыраган Чыршыкай.— Алар миннән зур түгел бит; хәтта берсе миннән кечкенәрәк тә әле. Ни өчен аларның да ботакларын тазартмадылар?

— Ә без беләбез, без беләбез,— дип чыркылдаганнар чыпчыклар.— Без чыршыларны кая алып китүләрен беләбез! Алар үзләре дә уйламаган кадер-хөрмәт күрәчәкләр! Без тәрәзәләрдән күрдек! Аларны, җылы бүлмәнең уртасына утыртып, иң матур әйберләр: алтынланган алмалар, баллы прәннекләр, төрле уенчыклар һәм йөзләрчә шәм белән бизиләр!

— Белмәссең, бу кадер-хөрмәтне, бәлки, мин дә күрермен әле! Их, Яңа ел тизрәк җитсен иде! Мин дә матур уенчыклар белән бизәлеп утырсам иде! — дигән Чыршыкай.

— Миңа карап куан! — ди икән Һава.

— Миңа карап шатлан! Иректә яшәгән яшь гомерең өчен шатлан! — ди икән Кояш нуры.

Ләкин Чыршы куанмаган, үскән дә үскән.

— Бу яшь Чыршы нинди матур! — дип сокланганнар башка агачлар.

Яңа ел алдыннан иң башта аны кискәннәр. Авырту һәм зәгыйфьләнүдән аның хәтта киләчәк бәхете турында уйларлык та хәле калмаган. Хәзер аңа урманнан аерылып киту кызганыч булган: моннан соң инде ул үзенең сөекле дусларын — чыршыларны, наратларны, чәчәкләрне, хәтта урман кошларын да — һичбер вакытта да

күрә алмаячагын белгән. Аерылышу бик ямансу икән шул.

Чыршы үзен йорт алдындагы башка агачлар арасында күргәч кенә аңына килгән һәм кемнеңдер:

— Нинди шәп Чыршы! — дигәнен ишеткән.

Бәйрәмчә киенгән ике хезмәтче, килеп, аны зур залга кертеп куйганнар... Менә Чыршыкайны бизи башлаганнар. Ботакларына төрле төсләрдәге кәгазьдән кисеп эшләнгән уенчыклар асканнар; алтынланган алмалар белән чикләвекләр агачның үзеннән үсеп чыкканнар диярсең; яшел энәләр арасында курчаклар тирбәлә башлаганнар. Ботакларына кызыл, зәңгәр, ак шәмнәр беркеткәннәр, ә иң югары очында алтын кәгазьдән эшләнгән зур уенчык балкыган.

— Их! — дип көрсенеп куйган Чыршы,— тизрәк кич җитсен иде! Шәмнәр балкысын иде! Бәлки, мине урман агачлары да күрергә килерләр. Чыпчыклар, очып килеп, тәрәзәләрдән карамаслар микән? Кышын-җәен менә шулай матур булып, шушы мичкә эчендә үсеп утырсам, нинди бәхетле булыр идем.

Шәмнәрне кабызыр вакыт та җиткән. Ишектән залга балалар атылып кергәннәр. Алар артыннан, мәһабәт кенә атлап, олылар килгәне күренгән. Шатлык, чыр-чу купкан. Балалар Чыршы тирәсендә әйләнеп биегәннәр. Нәниләр андагы уенчыкларны өзгәләп ала башлаганнар.

— Болар ни эшлиләр соң? Шулай ярамый бит инде! — дип пошынган Чыршы.

Тора-бара, шәмнәрне сүндергәннәр. Балаларга Чыршыдагы уенчыкларны алырга рөхсәт иткәннәр. Балалар Чыршыга ташланганнар! Чыршының ботаклары сынган.

— Әкият! Әкият сөйләгез! — дип, балалар кыска буйлы юан гына бер кешене агач янына сөйрәп китергәннәр.

Ул Чыршы астына ук кереп утырган да әкиятен сөйләргә керешкән.

Тавыш, чыр-чу. Чыршы гына тавышсыз-тынсыз басып уйланган: «Ник, минем кирәгем беттемени? Мин хәзер боларга әллә бар, әллә юк бит...»

Иртә белән аның янына хезмәтчеләр килгән.

«Хәзер яңадан бизи башларлар»,— дип өметләнгән Чыршы. Ләкин алар Чыршыны бүлмәдән өстерәп чыгарганнар да, чардакка менгереп, көн яктысы бер дә төшми торган караңгы почмакка ташлаганнар.

— Мин монда ни эшләрмен? Ни ишетә алырмын? — дип хәсрәтләнгән Чыршы.

Көн артыннан көн, төн артыннан төн узган, чардакка беркем дә менмәгән.

Берзаман, «пип!» дип чыелдап, ике тычкан килеп чыккан.

Тычканнар кызыксына да беләләр икән.

— Син каян килдең? Ниләр беләсең? — дип сораганнар.— Дөньядагы иң-иң матур урыннар

турында сөйлә әле. Шүрлекләре тулы көнбагыш, түшәмнәренә итләр асылган базларда булганың бармы?

— Андый урынны белмим, мин кояш яктысында кошлар сайрап торган урманны беләм,— дигән Чыршы.

Аннары Чыршы тычканнарга үзенең яшьлеге турында сөйләгән. Тычканнар шаккатканнар:

— Күп күргәнсең. Бик бәхетле булгансың икән,— дигәннәр.

Чыршы үзенең сүзләреннән үзе уйга калган:

— Минме? Әйе, чынлап та, ул вакытта мин рәхәт яшәгәнмен! — дигән.

Аннары Чыршы Яңа ел алды көнен, үзен ничек шәмнәр, уенчыклар белән бизәүләрен сөйләгән.

— Ах, син нинди бәхетле булгансың, карт Чыршы! — дип сокланганнар тычканнар.

— Мин бер дә карт түгел,— дигән Чыршы.— Мине урманнан быел кыш кына китерделәр! Мин үсә генә башладым әле.

— Бик кызыклы итеп сөйлисең! — дигәннәр тычканнар һәм, Чыршының сөйләгәнен тыңлар өчен, икенче көнне үзләре белән тагын дүрт кечкенә тычкан ияртеп килгәннәр.

Чыршы икенче көнне дә сөйләгән. Сөйләгән саен, үзенең урманда үскән вакытын сагынган. «Чыннан да, рәхәт чаклар булган бит»,— дип уфтанган.

— Син бары шул бер вакыйганы гына беләсеңме? — дип сораганнар тычканнар.

— Бары шуны гына беләм! — дигән Чыршы.

— Димәк, син тозлаган майлары, майлы шәмнәр яки азык-төлек тулган базларны белмисең? — дип, кабат сораганнар тычканнар.— Алайса, сөйләгән кадәре өчен рәхмәт! — дип таралышканнар

Ялгыз калгач, Чыршы, тагын кайгыга төшеп: «Ә бит ул җитез тычканнар хикәяләремне тыңлап утырганда нинди рәхәт иде! Хәзер алар да юк. Бәхетле вакытымны тагын күрми калдым, моннан соң кулдан ычкындырмам»,— дип, үзенә сүз биргән Чыршы.

Беркөнне иртә белән кешеләр, килеп, чардакны җыештыра башлаганнар. Тартмаларны урыннарыннан күчергәннәр. Чыршыны урамга сөйрәп чыгарганнар да чүплек өеменә ташлаганнар.

Яңа елда чыр-чу килеп биегән балаларның берсе, Чыршы янына килеп, очындагы уенчыкны өзеп алган да:

— Карагыз әле, бу алама карт Чыршыда нәрсә калган! — дип, бәләкәй итекләре белән Чыршының ботаклары өстенә менеп баскан. Ботаклар шытырдап куйганнар.

Чыршы шул вакытта бакчадагы матур ачык төстәге чәчәкләргә, агачларның саф яшел яфракларына, җемелдәп үскән үләнгә караган да:

— Бар да үтте, бар да бетте! Ичмасам, мөмкинлек бар чакта тормышымның рәхәтен күреп кала алмадым,— дип үкенгән.

Шуннан соң урам себеруче карт Чыршыны вак кисәкләргә тураклап ташлаган һәм берәмләп казан астына ыргыткан... Шулай итеп, Чыршы, янып, көлгә әйләнгән.

Дөньяда һәрнәрсәнең дә ахыры була бит!

Ханс Кристиан Андерсен.

?! **1.** Әкияттә ике зур вакыйга бар. Беренче вакыйга — чыршының урманда яшәве, икенчесе Яңа ел чыршысына әйләнеп яшәве турында. Беренче вакыйгада чыршы туган җиренең һәм яшьлегенең кадерен белми. Гел урманыннан китү турында хыяллана. Чыршының икенче вакыйгадагы хисләрен сөйләгез.

2. Автор, ни турында язса да, барыбер кешеләрне күз алдында тота, дигән идек. Чыршыны кеше итеп күз алдына китерсәк, урман — кешенең туган иле, дия алабызмы? Әкият нинди кешеләр язмышы турында?

Мөстәкыйль эш.

ПАТША КЫЗЫ ҺӘМ ЯРЛЫ УЛЫ.

?! Әкияттәге вакыйгаларны капма-каршысына әйләндерегез.

Әкияттә. Бер патша яшәгән. Аның, күрсәң, шунда ук һуштан язарлык чибәр, эшчән кызы булган.

Без уйлап тапкан капма-каршысы. Бер ярлы яшәгән. Аның бик ямьсез, ялкау улы булган.

Әкияттә. Кызны сорап, күрше-тирәдәге патша уллары җыелалар.

Капма-каршысын уйлап табыгыз.

Әкияттә. Кыз егетләрнең барысыннан да баш тарта.

Капма-каршысы ничек була?

Әкияттә. Кыз ярыш оештыра. Чапкан боланны кайсыгыз куып җитә алса, шул егеткә кияүгә чыгам, ди.

Капма-каршысын уйлап табыгыз.

Әкияттә. Боланны хәерче егет уза һәм, патша кызын алып, соңыннан патша була.

Кампа-каршысы ничек була?

ЭТ ҮЗЕНӘ НИЧЕК ДУС ЭЗЛӘГӘН?

Бик күптән Эт урманда яшәгән. Ялгызы гына көн күрү туйдырган. Дус тапмакчы булган.

Урманда Куянны очраткан да:

— Әйдә, дус булып, бергә яшик,— дигән.

— Әйдә,— дигән Куян. Кич җиткәч, кунар урын эзләп тапканнар. Йокларга ятканнар. Төнлә яннарыннан Тычкан үтеп киткән. Эт сикереп торган да бөтен урманны яңгыратып өреп җибәргән. Тавышка Куян куркып уянган. Колакларын калтырата-калтырата:

— Нигә өрәсең? Бүре ишетсә нишләрбез! — дигән.

«Юньле дус була алмый. Бүредән дә курка. Бүре, мөгаен, берәүдән дә курыкмый торгандыр»,— дип уйлаган Эт.

Таң аткач, Эт Куян белән хушлашкан. Бүрене эзләргә киткән. Эт аны тирән чокырда очраткан:

— Әйдә, Бүре, дус булыйк,— дигән.

— Риза. Бергә-бергә яшәү күңеллерәк булыр,— дигән Бүре.

Кич җиткәч, бергә йокларга ятканнар. Төнлә яннарына Бака сикереп килгән. Ят тавыш ишетүгә, Эт, мин сиңа әйтим, тотынган өрергә! Бүре куркып уянган:

— Акылдан шаштыңмы әллә? Аю ишетеп килсә, икебезне дә ерткалап ташлаячак бит! — дип ачуланган.

«Бүре дә куркак икән. Миңа Аю белән дуслашырга кирәк»,— дип уйлаган Эт. Аюны эзләп тапкан да:

— Баһадир Аю, әйдә, дуслашыйк. Бергә-бергә яшәү күңеллерәк булыр,— дигән.

— Дуслашыйк соң, әйдә, минем өндә яшәрбез,— дигән аю.

Төнлә өнгә тузбаш Елан шуышып кергән...

?! Әкиятне дәвам итегез.

1. Эт нишләгән? Аю аңа ни дигән?

2. Аннан соң эт ни уйлаган? Кемне эзләп киткән?

3. Әкиятне ничек тәмамлар идегез?

ПАТША УЛЫ БАКА, ЯКИ ТИМЕР ЙӨРӘКЛЕ ГЕНРИХ.

Бик-бик күптән, бу дөньяда могҗизалар туып торган чакта, бер патша яшәгән. Уллары булмаса да, кызлары берсеннән-берсе чибәррәк икән. Ә кечесеннән хәтта кояш та күзен ала алмаган.

Патша йорты кара урманга якын икән. Урмандагы карт юкә агачы төбендә кое бар икән. Җәйнең эссе көннәрендә патшаның төпчек кызы, шул кое янына утырып, саф һава суларга яраткан. Ә ялгызына күңелсез булмасын өчен, алтын шарын да үзе белән йөрткән. Шарын чөеп җибәрә икән дә тотып ала икән, чөя икән дә тота икән. Кызның иң яраткан уены шул булган.

Бәла аяк астында бит ул. Шарга җан кергән диярсең, кыз кулыннан ычкынып, бер генә сикергән дә, коега төшкән дә киткән. Ә кое шундый тирән, хәтта төбе дә күренми икән.

Мескен кыз кычкырып елый башлаган. Елаган да елаган.

Кинәт кемдер:

— Нигә елыйсың, патша кызы? Кем рәнҗетте сине болай? — дип сораган.

Кыз елаудан туктаган. Як-ягына караган — берәү дә юк. Акай күзле Бака гына карап торуын күргән.

— Ичмасам, син кызган, бакылдык Бака. Алтын шарым коега төшеп китте. Шуңа елыйм,— дигән кыз.

— Шул гынамы? — дигән Бака.— Тапкансың еларга сәбәп. Хәзер алып чыгам уенчыгыңны.Тик бер шартым бар: алдан ук әйтеп куй. Яхшылыгым өчен нинди бүләк бирерсең?

— И Бакакаем, җаның ни тели, шуны ал. Теләсәң, иң-иң асыл киемнәремне бүләк итәм. Асыл ташлар, энҗеләр бирәм. Алмаз кашлы йөзек кирәксә, аларын да алдыңа чыгарып салам. Хәтта алтын таҗымны да салып бирәм.Кызганмыйм. Рәхәтләнеп, башыңа киеп йөр, тик шарымны гына алып чык! — дип кычкырган кыз.

— Миңа синең асыл киемнәрең дә, кыйммәтле ташларың да, хәтта алтын таҗың да кирәкми. Теләгем бер генә — син миңа мәхәббәтеңне бүләк ит. Мине якын дустың, иптәшең ит. Минсез уйнама. Минсез өстәл артына ашарга утырма. Мин синең

алтын тәлинкәңнән алтын кашыгың белән ашар идем. Алтын касәңнән эчәр идем. Ә төнлә ефәк мендәреңдә йоклат,— дигән Бака.

— Риза, риза! Ни телисең — барын да үтим. Шарымны гына кое төбеннән алып чык! — дигән кыз.

Әйтүен әйткән, ә үзе: «Ахмак Бака, ни лыгырдаганын белми. Дустың ит, имеш. Синең бар эшең — әнә баткаклыкта бакылдап яту»,— дип уйлаган.

«Риза!» сүзен ишетү белән, Бака коега чумган! Кыз «бер, ике, өч» диярргә дә өлгермәгән, алтын шарны кабып килеп тә чыккан.

Патша кызы, яраткан уенчыгын эләктереп, өйләренә чапкан.

— Тукта, кая ашыгасың! Мине дә иярт. Артыңнан җитә алмыйм бит! — дип кычкырган Бака.

Ләкин күпме бакылдамасын, күпме ялвармасын, патша кызы артына әйләнеп тә карамаган. Өйгә кергәч, аның барлыгын да оныткан.

Икенче көнне патша гаиләсе ашарга утырган. Төпчек кыз алтын кашыгын алтын тәлинкәсенә чумдырырга да өлгермәгән, сарай баскычыннан кемнеңдер шап-шоп, чыштыр-чыштыр сикерә-сикерә менүе ишетелгән. Өскә хәтле менеп җиткәч, ул ишек каккан һәм:

Патша кызы, ач ишегең,
Мин килдем.
Оныттыңмы, син бит миңа
Сүз бирдең? —

дип җырлап җибәргән.

Патша кызы, барып, ишек ачса — Бака утыра. Кыз ишекне шап итеп япкан да тиз генә урынына барып утырган.

— Кем куркытты, кызым? Усал дәү кеше сине алырга килмәгәндер бит? — дип сораган әтисе.

— Юк, әти, дәү түгел, иләмсез тәбәнәк Бака гына,— дип җавап биргән кызы.

— Ул Баканың синдә ни эше бар? — дип сораган патша.

— Кичә коега ялгыш алтын шарымны төшердем. Еладым. Бик нык елагач, шул Бака, кызганып, яныма килде. Шарымны коедан алып чыкты. Шуның өчен мин аңа гомергә дус булырга сүз бирдем. Коедан чыгып, монда килер дип, кем уйлаган?.. — дигән кызы.

Ул арада Бака тагын ишек каккан һәм әлеге җырын җырлаган:

Патша кызы, ач ишегең,
Мин килдем.
Оныттыңмы, син бит миңа
Сүз бирдең?

— Сүзеңне бәйдә тот, этеңне бауда тот. Сүздә тору — зурлык, сүздә тормау — хурлык, кызым. Бар, ачып керт,— дигән патша кызына.

Ишек ачылу белән, Бака, шап-шоп, чыштыр-чыштыр килеп, өстәл янына сикергән һәм:

— Ә хәзер, күтәреп, урындыгыңа утырт,— дигән.

Кемнең иләмсез Баканы үз янына утыртасы килсен! Ләкин патша күтәреп утыртырга кушкан.

Бака шуннан соң кыздан өстәлгә утыртуын һәм алтын тәлинкәсен алдына куюын үтенгән.

Нишләсен кыз, өстәлгә дә утырткан, тәлинкәсен дә алдына куйган. Бака уңга-сулга карамыйча ашаган да ашаган. Кыз кабып та карамаган.

Ашап туйгач, Бака, ял итәм, мендәреңә яткыр, дип боерган.

Кыз кычкырып елап җибәргән. Бака белән бер мендәргә яту түгел, Бакага ул бармагы белән кагылырга да курыккан. Ләкин патшаның ачуы килгән: «Башыңа бәла төшкәндә, ярдәм кулын сузучыны мыскыл итмә!»— дигән.

Патша кызы Бакасын чеметеп кенә тоткан да бүлмәсенә алып кергән. Почмакка утыртып, үзе йокларга яткан.

Ләкин, кара син аны, нинди бәйләнчек Бака икән, патша кызы ятагына сикереп менгән дә:

— Мендәреңә утырт, югыйсә әтиеңә әйтәм,— дигән.

Патша кызының түземлеге беткән. Урыныннан сикереп торган.

— Әле алаймы, әләкләмәкче буласыңмы, кабахәт Бака! Бүтән миңа бәйләнә алмассың,— дип, Бакасын тоткан да бар көченә диварга аткан.

Атуын аткан, ләкин бу эшенә шунда ук үкенгән. Баканы кызганган. Үзенең шәфкатьсезлеге өчен оялган. Дивар ягына карарга кыюлыгы җитмичә, шактый утырган. Бераздан, батырлыгын җыеп, башын күтәрсә, күзенә ышанырга да, ышанмаска да белмәгән — каршында чибәр егет — патша улы басып тора икән. Күзләре шундый шәфкатьле, назлы. Андый назлы иркә күз белән аңа берәүнең дә караганы булмаган.

Патша улы язмышын сөйләп биргән. Аны явыз Убырлы карчык, сихерләп, Бака иткән икән.

— Мине синнән башка берәү дә бу сихердән коткара алмас иде. Син булмасаң, гомерем буе коеда бакылдап яткан булыр идем. Ә иртәгә син миңа кияүгә чыгасың,— дигән.

Чыннан да, икенче көнне иртән патша сарае капкасына сигез ап-ак ат җигелгән тарантас килеп

туктаган. Ат сбруе алтыннан, атлар башында тәвә кошының аллы-гөлле каурыйлары җилферди. Ә тарантас артына патша улының якын дусты Генрих баскан. Иң якын дусты Бакага әверелгәч, Генрих йөрәгендәге кайгы тышка ташып чыгардай зур булган. Шуңа күрә ул йөрәгенә өч тимер кыршау салырга мәҗбүр булган. Хәзер мескен Генрихның шатлыгы эченә сыймаган. Шуңа күрә, кузгалып, бераз юл үтүгә, шарт итеп сынган ниндидер тавыш ишетелгән. Патша улы, борчылып:

— Тарантас ватылдымы әллә? — дип сораган.

— Шулай тоелган гына ул Сезгә. Мин Сезне югалту кайгысыннан йөрәгемне өч тимер кыршау белән кысып куйган идем. Шуларның берсе өзелде,— дип җавап биргән дусты. Юлда нидер тагын шартлап сынган. Патша улы бу юлы да дустыннан: «Ни булды?»— дип сораган.

Ни булганын без яхшы беләбез. Генрих йөрәгендәге тимер кыршаулар шулай шартлап челпәрәмә килгәннәр. Хәсрәтле йөрәкне су мичкәсен кыршаулаган кебек кыршаулап була. Шатлык шатлык инде ул. Аны берничек тә тыеп та, кыршау эченә сыйдырып та булмый.

Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар.

Әкиятнең авторлары — бертуган Гриммнар — күренекле немец галимнәре. Алар — шулай ук бөтен дөньяда яратып укыла торган әкиятләр авторлары да.

Бу әкиятнең эче тулы могҗиза. Монда бака кеше кебек сөйләшә. Баканың кинәт кешечә сөйләшүен ишеткән патша кызы аз гына да гаҗәпләнми... Бака кинәт кешегә әйләнә. Хәсрәте тышка чыкмасын өчен, йөрәкне кыршаулар белән буып куялар.

?! **1.** Әкияттә тормышта булмый торган нинди могҗизалар бар?

2. Ләкин иң зур могҗиза — безнең дә әнә шул хыялый дөнья эчендә яшәп алуыбызда. Без, әкиятне укыгач, баканың кеше булуына да, Убырлы карчык сихеренә дә, патшаның үз кызына ямьсез бака белән йокларга кушуына да ышанабыз. Ышанып кына калмыйбыз, хәтта кызны кызганабыз да. Бездә кызга карата тагын нинди хисләр туа?

3. Кызның әтисенә карата нинди хисләр туа?

4. Бакага һәм аның якын дусты Генрихка карата нинди хисләр туа?

5. Патшаның башка кызлары да бар. Аларның берсенә матур исем бирегез. Патша кызлары чибәр, ә Генрих — менә дигән егет. Әйдәгез, без дә яхшылык эшлик. Патша кызы белән Генрихны өйләнештерик.

Әкиятне дәвам итегез. Яшьләрне күрештерү өчен, шартлар уйлап табыгыз.

Бер вариант: Генрихның шатлыгы эченә сыймый. Атылып чыга да кошлар сайраган урманга оча. Кыз шунда егет шатлыгын күрә һәм, тотып, иясенә тапшыра. Шулай очрашалар.

КАМЫР БАТЫР.

Борын-борын заманда, кәҗә команда, әби-бабай тумас борын, әти белән икәү генә торган чагында бар иде бер карт белән карчык. Аларның балалары юк иде, шуңа кайгылары бик зур иде.

Берзаман болар исәпләделәр, уйладылар да камырдан бер бала сыны ясап куйдылар. Карчык китте сыер саварга, бабай чыгып китте утын ярырга.

Керсәләр, исләре китте, акыллары таралды: камыр сыны малай булып, кәҗә бәтиләре белән чабышып уйнап йөри.

Камыр малай төн үсә, көн үсә, ди, ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә. Бабай ясап бирде, ди, моңа шартаяк. Малай бер таянган иде, ди, шартаяк шарт итеп сынды, ди. Төшеп китте, ди, бабай тимерчегә, ясатты, ди, моңа тимер шартаяк. Малай беркөнне урамга чыга — бер малайның аягын сындырып керә. Икенче көнне чыга — икенче малайның муенын сындырып керә, ди. Шуннан соң авыл халкы, җыелып, бабайга әйтәләр:

— Малаең малай төсле түгел, балаларны имгәтеп бетерә, теләсәң кая куй! — диләр.

?! Бу өзегендә әкиятче замандашларын көлдерерлек ни уйлап тапкан?

Чыгып китә малай дөнья гизәргә. Ай китә, ел китә, бер саплам җир китә. Барып керә бу бер карурманга. Очрый моңа аягын тышаулаган бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп тышауладың бу аягыңны? — ди.

Теге кеше әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди, аягымны ычкындырсам, мин күккә очам, минем арттан кош-корт та очып җитә алмый,— ди. Камыр батыр моны үзе белән ияртеп китә.

Бара торгач, очрый боларга борын тишеген бармагы белән кысып утырган бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай борын тишегеңне кысып утырасың? — ди.

Теге кеше әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди. Югыйсә дөньяда зилзилә куба, бер борын тишегем белән өрдереп тә биш ташлы тегермән әйләндерәм мин,— ди. Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар болар. Очрый боларга эшләпәсен кырын салган ак сакаллы бер бабай.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп эшләпәңне кырын салдың? — ди.

Теге бабай әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди. Мин эшләпәмне туры кисәм, күз ачмаслык буран чыга, басып кисәм, Җир йөзенә ике илле боз ката,— ди. Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Баралар-баралар болар. Очрый боларга ук төзәп торучы тагын бер кеше.

— Нәрсә атасың син болай? — дип сорый моннан Камыр батыр. Ук төзәп торучы әйтә:

— Ә-ә-ә-нә күрәсеңме, теге тауның кабыргасында, моннан алтмыш чакрым җирдә, бер чебен утыра. Шул чебеннең сул күзен атып чыгарам,— ди. Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә.

Тагын китәләр. Беравык баргач, очрый боларга туфрак белән уйнап утырган сакаллы бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай уйныйсың? — ди. Сакаллы кеше әйтә:

— Уң яктан сугам — уң якка тау өям, сул яктан сугам — сул якка тау өям,— ди. Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

?! Бу әзектә охшаш вакыйгалар бар. Аларны, кушып, бергә генә калдырыгыз.

Барып җитәләр болар бер байга, сорыйлар моның кызын. Бай бик кире була, төрле хәйләләр кора.

— Минем кызым — бай кызы, ди, патша кызыннан ким түгел, синдәйләргә тиң түгел, ди. Әйдә, миннән булсын яхшылык, ди, йөгерешчемне узсаң, бирсәм бирермен инде,— ди.

Китәләр йөгерешкә. Аягын тышаулаган егет алтмыш чакрым җирне бер-ике сикерүдә барып җитә дә, бай йөгерешчесе килеп җиткәнче дип, тау өстендә йоклап китә. Байның йөгерешчесе йөгереп мәйданга якынлашып килгәндә, теге һаман йоклаган була әле.

Камыр батыр әйтә:

— Ай-һай, ди, бай йөгерешчесе җиңә бит, ди. Ат әле тегеңәр,— ди.

Алтмыш чакрымнан чебеннең сыңар күзен атып чыгаручы кеше атып җибәрә, йөгерешченең колак яфрагын чеметтереп ала. Йөгерешче уянып китә дә мәйданга бай йөгерешчесеннән алда килеп җитә.

Хәзер бай алай итә, болай итә, боларны, алдап, чуен мунчага яба. Әрдәнә-әрдәнә утын өйдерә,

ут төртә, боларны яндырып үтермәкче була. Болар мунча эчендә пешә башлыйлар. Камыр батыр бабайның эшләпәсен туры кидерә — мунча эчендә күз ачмаслык буран кузгала. Алай да пешә башлыйлар, ди. Камыр батыр бабайның эшләпәсен бастырып кидертә — мунча стенасына ике илле боз ката.

Икенче көнне бай мунча ишеген ачып җибәрсә, ботын чабып шакката: барысы да исән-сау.

Камыр батыр әйтә бу байга:

— Башымны катырма инде, ди. Алыштанмы, салыштанмы? — ди.

— Алыштан да булыр, салыштан да булыр,— ди бай.— Минем сиңа бирә торган кызым юк, көчең җитсә алырсың,— ди.

Китте алыш, китте егып салыш. Шундый алыштылар, шундый салыштылар, тигез җирләр түмгәк булды, түмгәк җирләр тигезләнде. Көн сугыштылар, төн сугыштылар, кич сугыштылар, бик озак сугыштылар. Бер борын тишеге белән өрдереп, биш ташлы тегермән тарттыручы кеше борын тишеген сызгырттырып җибәрә — байның егерме кешесе очып китә. Туфрак белән уйнаучы бер яктан сугып җибәрә — утыз кеше күмелә, икенче яктан сугып җибәрә — кырык кеше күмелә.

Камыр батыр күсәге белән бер селтәнә, әллә нихәтле кеше кырылып бетә.

Бай түзә алмаган, кызын бирергә мәҗбүр булган, ди. Кызны Камыр батырга биргәннән соң, утыз

көн уен итеп, кырык көн туен итеп, аш-суның чиге юк, бәлешләренең төбе юк, мичкә-мичкә бал куйганнар, үзләре чүмеч белән чөмерәләр, миңа сабы белән генә эләкте.

?! Соңгы өзекне мөмкин кадәр кыска итеп сөйләгез. Аңа бик кыска исем бирегез. Кыскартакыскарта, исемне бер генә сүзгә калдырырга тырышыгыз.
Әкиятне тулысынча сөйләгез. Оныткан урыннарын дәреслегегездән карый-карый исегезгә төшерегез.

Йомгаклау сүзе.

«Әсәрдәге могҗиза» бүлегендә китерелгән Габдулла Тукай сүзләрен искә төшерик. Бөек шагыйребез сәнгать әсәрләрен язучыларның сизгер күңелендә җитешкән гөлләргә тиңли. Укучыларга, шул бакчага кереп, матурлык күрергә өйрәнергә тәкъдим итә, киңәшен бирә.

Ә без аның теләген үтәдек. Шундый гүзәл бакча эчендә йөреп, матурлык күрергә өйрәндек. Ул бакчада безнең күңелләргә кызгану, шәфкатьлелек, игелеклелек, миһербанлык хисләре иңде. Усаллыкның һәрвакыт җиңелүен, хаклык, игелекнең тантана итүен күреп шатландык. Күңелләребез әллә никадәр тойгы-кичерешләр белән тулды, баеды. Алдагы сыйныфларда сез мондый гүзәл бакчаларның башкаларына да керерсез. Язучыларның сизгер күңелләреннән матур чәчәк орлыклары җыюны дәвам итәрсез, дип уйлыйм. Ул орлыкларны игелекле эш-гамәлләрегез белән сугарып торсагыз, алар сезнең күңелләрдә дә шаулап чәчәк атарлар.

Сез, хөрмәтле укучылар, чит ил әдипләре иҗат иткән әсәрләр белән дә танышырга тиешсез. Мәгариф өлкәсендәге яңарышлар шуны таләп итә. Шуңа күрә дәреслеккә бөтен дөньяга танылган чит ил әдипләренең әсәрләре дәреслек авторы тарафыннан тәрҗемә ителеп кертелде.

Габдулла Тукай безгә: «Уйларыгызны языгыз да уйны уйга бәйләгез»,— дип, тагын бер матур киңәш биргән.

Бөек шагыйребезнең бу теләген дә үтәдек. Уйны уйга ялгарга өйрәндек: уйның үз кагыйдәләре белән таныша башладык. Башкалар әйткәнне генә кабатламадык. Уйны уйга ялгап иҗат итү үзе бер шатлык булуын да күрдек. Дөнья әдәбияты әсәрләренә дә анализны үзебез ясарга тырыштык. Ә уйлар бакчасының гүзәллеген күрергә өйрәнүне алдагы сыйныфларда дәвам итәчәксез. Хәерле юл сезгә, кадерле укучылар!

ЭЧТӘЛЕК

Беренче ярты елда өйрәнгәннәрне искә төшерик. 3

Кәрлә Мук. *Вильгельм Гауф. Немец язучысы.* . . . 3

Өлешләр арасындагы бәйләнеш. 14

Охшашлык. 14

Кошлар килә. *Гали Хуҗи* 15

Табышмак-шигырь. *Роберт Миңнуллин* 16

Айбаш. *Габделхәй Сабитов* 17

Бүләк. *Җәүдәт Дәрзаман* 22

Әрдәнә. *Идрис Туктар* 23

Яфраклар коелган. *Фатих Хөсни* 25

Кушылу. 26

Фән кушканча. *Шәүкәт Галиев* 27

Себерке. *(Мәсәл.)* 29

Шалкан турында. *Николай Носов. Рус язучысы* . . 29

Таң атканда. *Сибгат Хәким* 38

Тамчылар бииләр. *Зәки Нури* 39

Чиста су. *Мәхмүт Газизов* 40

Герой сыйфатлары. 41

Персонаж, герой. 43

Колын. *Әминә Бикчәнтәева* 43

Чыпчык. *Иван Тургенев. Рус язучысы* 44

Каз белән Торна. *(Мәсәл.) Константин Ушинский. Рус язучысы.* 46
Алмалар. *Гәрәй Рәхим.* 46
Горур Каенбикә. *Фәнис Яруллин* 50
Бака, Тычкан, Чабата. *(Әкият.)* 51
Бии белмәгән Аю. *Хәкимҗан Халиков* 54
Улым — акыл иясе. *(Кытай халык мәзәге.)* 55
Гайни. *Фәнис Яруллин* 56
Коймакны кем пешерде? *Гариф Галиев* 58
Эш кушып булмый. *Шәүкәт Галиев* 62
Аксак качыр. *(Португалия халкы әкияте.)* 62
Сәүдәгәр һәм Поши. *Франц Холер. Швейцария язучысы* 65
Тылсымлы казан. *(Кытай халык әкияте.)* 68
Ялкау патша һәм үрмәкүч турында. *Ханс Кристиан Андерсен. Дания язучысы* 72
Бакчачылар. *(Хикәя.) Николай Носов. Рус язучысы* 77
Ике агач. *(Кытай халык әкияте.)* 86
Җирәнчә чәчәннең килен эзләве. *(Башкорт халык әкияте.)* 93
Икмәк яңгыры. *(Башкорт халык әкияте.)* 96
Батыр кәчекләр. *Михаил Петровтан. Рус язучысы* 100

Персонаж сүзе. Автор сүзе. 100
Чыдасын тик ул гына. *Афзал Нигъмәтуллин* 101
Әниләре өйдә юкта. *Мирсәй Әмир* 102
Песи һәм Чыпчык. *Афзал Нигъмәтуллин* 106
Мактанчыклар. *Илдар Юзеев* 107

Герой хисе.
Әйтемнәр һәм мәкальләрдәге хис. 108

Коштай. *(Әкият.)* 110
Шифалы дару. *Шәүкәт Ногманов* 115
Җиде карга. *(Латыш халык әкияте.)* 117
Минем сөйгән китабым. *Мәхмүт Хөсәен* 122
Пи-би-би-бип... *Һади Такташ* 123
Картайдым шул. *Һади Такташ* 123
Тутый кошчыклар. *(Әкият.) Элионор Фарджон. Француз язучысы* 125
Елады. *Илдар Юзеев* 129
Җәйне озатканда. *Роберт Миңнуллин* 130
Чыршы. *Ханс Кристиан Андерсен. Дания язучысы* 131

Мөстәкыйль эш. 139

Патша кызы һәм ярлы улы. *(Татар халык әкиятеннән.)* 139
Эт ничек үзенә дус эзләгән? *(Молдавия халкы әкиятеннән.)* 140
Патша улы Бака, яки тимер йөрәкле Генрих. *(Әкият.) Бертуган Якоб һәм Вильгельм Гриммнар. Немец язучылары* 141
Камыр батыр. *(Татар халык әкияте.)* 149

Йомгаклау сүзе. 155

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 2 класса
четырёхлетней начальной татарской школы

В двух частях
Вторая часть

Казань. Издательство «Магариф». 2009

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең
2 нче сыйныфы өчен дәреслек

Ике кисәктә
Икенче кисәк

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректоры *Г. Г. Мөхәммәтҗанова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.05.2009.
Форматы $70\times90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Прагматика» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 11,7+форз. 0,29.
Нәшер-хисап табагы 5,85+форз. 0,49. Тиражы 3400 д. Заказ В-652.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http: //www.magarif.com

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978-5-7761-1966-8